Айрат Арсланов
КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2007
УДК 821.512.145-94:792
ББК 84 (2Рос=Тат)-4:85.36
А80

Төзүчесе

РОЗА ЗАҺИДУЛЛИНА

Рәссамы
РУШАН ШӘМСЕТДИНОВ

Айрат Арсланов: истәлекләр / төз. Р.Ә.Заһидуллина. — Казан: Татар. кит. нәшр., 2007. — 239 б., рәс. б-н. — 3000 д. — ISBN 978-5-298-01538-7

Китапта Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Айрат Арсланов турында замандашларының истәлекләре белән бергә үзенең сүз сәнгате турындагы уйланулары, мәшһүр шәхесләргә багышланган язмалар, фоторәсемнәр урын алды.

ISBN 978-5-298-01538-7
© Татарстан китап нәшрияты, 2007
© Заһидуллина Р.Ә., төзү, 2007

# Татарстан Республикасы Президентының рәхмәт хаты

*Хөрмәтле Айрат Гәрәй улы!*

*Халкыбызның милли сәнгатен үстерүдәге, рухи байлыгыбыз, әдәбиятыбыз мирасын сәнгать югарылыгына күтәрүдәге тиңдәшсез иҗади хезмәтегез өчен Сезгә ихлас күңелдән олы рәхмәтемне һәм иң изге теләкләремне җиткерәм.*

*Татарстанда сәнгатьле сүзне башкару осталыгын, нәфис сүз жанрын үстерү, һичшиксез, Сезнең исемегез белән бәйле.*

*Сез иҗат иткән елларда телевидение, радиотасмаларга язылган әдәби җәүһәрләребез татар мәдәниятенең алтын фондына кертелде. Танылган остаз, күпкырлы талант иясе булуыгыз, табигать тарафыннан бирелгән күркәм тавышыгыз һәм искиткеч тырышлыгыгыз, хезмәт сөючәнлегегез Сезне чын мәгънәсендә халык артисты итеп танытты.*

*Татар сәнгатенең иң гүзәл традицияләрен сайлап, аларны халык күңеленә ифрат зур осталык белән җиткерә алу үрнәгең киләчәк буынга гүзәл бер ядкарь итеп калдыруыгыз өчен мең рәхмәт!*

*Игелеккә, матурлыкка өндәүче, тормышка мәхәббәт уятучы күркәм иҗатыгыз, халкыбыз мәдәниятен, сәнгатен, рухи байлыгыбызны пропагандалауга лаеклы өлеш керткәнегез өчен Сезгә олы рәхмәтемне һәм тирән ихтирамымны җиткерәм.*

*Сезгә чын күңелдән озын-озак иҗат ләззәте телим һәм киләчәктә дә өр-яңа ачышларыгыз белән безне тагын да сөендерерсез дип ышанып калам.*

*Татарстан Республикасы Президенты*
*М.Ш.Шәймиев*
*Казан, Кремль*
*17 сентябрь, 2003*

**ХӘСӘН ТУФАН**

# Туган тел

Һәр галимнең, һәр шагыйрьнең сүзе
Җитсен иде һәрбер күңелгә,
Җилләр, сулар тавышы шикелле үк

Үзләренең асыл телендә.

Атом көче, радио заманында
Күрсәм иде шуны мин тагын:
Ярдәмләшеп, телләр бер-берсендә
Тапса фәкать кардәш, туганын.

Бу дөньяның төсен, ямен, зәүкын
Кем аркылы, ничек белдем мин?
Бишектә үк мине өйрәтүчем,
Туган телем бәгърем, син ул, син!

Рәхмәт сиңа, рәхмәт, тәрбиячем,
Һәрнәрсәнең асыл мәгънәсен
Син аңлаттың миңа, туган телем,
Син өйрәттең миңа һәммәсен.

**МАНСУР ХӘСӘНОВ**

## Айрат Арслан _
## халкыбызның илчесе

Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Айрат Гәрәй улы Арсланов — дөньядагы милләтләр арасында мәшһүр урын тоткан татар халкының мәдәниятенә, нәфис сүз сәнгатенә бүләк иткән, сирәк очрый торган олы талантка ия шәхес. Андый талантлар дистә елларга бер генә туа.

Айрат Арсланов — үзенең табигый сәләте, иҗаты белән туган халкыбызның сөйләм сәнгате өлкәсендәге җегәрен, рухи мөмкинлекләрен бөтен тирәнлеге һәм куәте, байлыгы һәм нәфислеге белән татарның йөрәк тибеше, рухи дөньясы, күңеле белән бәйләде, нәфис сүз аркылы халкыбызның уй һәм теләкләрен, шатлык-хәсрәтләрен, тарихи трагедияләрен, киләчәк язмышын, гомумән, аның серләрен сокландыргыч тавышы аша ачып сала белгән, үз җанын халык йөрәгенә сихри җепләр, нечкә кыллар белән тоташтыра, бәйли алган мәшһүр башкаручы артистыбыз.

Аның иҗаттагы талантына шигърият кенә түгел, проза һәм драматургия дә буйсына. Аның башкаруында Кол Гали, Кандалый, Гаяз Исхакый, Тукай, Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Туфан, Пушкин, Гете, Лермонтов, Шиллер, Шевченко, Абай әсәрләрен тыңлаганда уй-хыялларың белән әллә кайларга — илаһи бер дөньяга иңәсең, гасыр чоңгыллары аша ерак тарихка китәсең, милләт язмышы хакында тирән, сагышлы һәм шул ук вакытта өметле дә уйларга чумасың.

Айрат Арсланов — тормышын, иҗатын милләтебезнең мәдәниятен, шигъриятен, әдәбиятын пропагандалауга, телебезне саклап калуга багышлаган шәхес.

Шигърият күгендә — Тукай, җыр дәрьясында — Илһам, моң дөньясында Сәйдәш булган кебек, сүз илендә Айрат Арслан халкыбызның илчесе дип горурланып әйтә алабыз.

**ГОМӘР БӘШИРОВ**

# Тылсымлы сүз остасы

Мәскәүнең мәшһүр Колонналы залында уздырылган бер әдәби-музыкаль кичә истә калган. Кичәнең рәсми өлеше һәйбәт кенә тәмамланганнан соң, концерт башланырга тиеш иде. Бәллүр кандилләр белән зиннәтләнгән данлы зал басынкы гына гүли. Башкаланың төрле почмакларыннан, төрле милләт вәкилләреннән җыелган таләпчән тамашачы сабыр гына көтә. Без дә көтәбез. Әмма дулкынланабыз. Чөнки бу залда, бигрәк тә башкала тамашачысы алдында концерт белән чыгу уен түгел. Без әле бик үк ышанып җитмибез, республикабызны, аның сәнгатен, әдәбиятын, бу өлкәдәге талантларыбызны тиешле югарылыкта итеп, иң күркәм, иң гүзәл якларыннан күрсәтә алырбыз микән?

Шул вакыт сәхнәгә бераз гына елмая төшеп, җиңел адымнар белән зифа, төз, озын буйлы, матур килеш-килбәтле, зәвык белән киенгән чибәр егет — Айрат Арсланов килеп чыкты. Ул ягымлы бәрхет тавышы белән күңелләргә үткәреп берничә сүз әйтүгә, зал кул чабарга тотынды.

Без дә тынычланып, җиңел сулап алдык. Чөнки күптән сыналган инде — Айрат Арсланов бит ул республика сәнгать-әдәбият даирәләренең визит карточкасы сыманрак мәгълүм бер дәрәҗәне күрсәтә, ул катнашкан концерт яки әдәби кичә гадәттә сәнгать бәйрәме төсен алуына без күптән үк инанган идек инде.

Беренче карауга, бигрәк тә җырчылар, драма артистлары белән чагыштырганда, нәфис сүз остасының һөнәре берникадәр гадирәк, беркатлырак булып күренергә мөмкин. Ләкин ул беренче карашка гына шулай. Эстрада артистын, бигрәк тә нәфис сүз остасын сәхнәдә үзенә генә хас, аңа гына очрый торган күптөрле кыенлыклар көтә.

Шулай да Айрат Арслановка җил гомер юлының башында ук уңай яктан исә башлаган дип әйтергә мөмкин. Артистка кирәк булган кадерле сыйфатларның байтагысын табигать аңа үзе үк биргән: ул аңа нык сәламәтлек, килешле буй-сын, ягымлы тавыш бүләк иткән, артистлык талантыннан да мул өлеш чыгарган.

Әмма талант дип аталган ул тылсымлы табигать бүләген берөзлексез үстерергә, гомер буена камилләштерергә, гел яңарта барырга кирәк була бит әле. Айрат Арсланов үз һөнәренең нечкәлекләрен өйрәнә, сәнгатьнең бу тармагында үз сүзен әйтерлек осталыкка ирешү өчен башта театр училищесында укыган, бераз соңрак Мәскәүнең Луначарский исемендәге театр институтын тәмамлаган. Ул берничә ел Татар дәүләт академия театрында Хәлил Әбҗәлилов, Фатыйма Ильская, Габдулла Шамуков кебек мәшһүр сәхнә осталары белән бергә эшләгән.

Эстрада артистын сәхнәдә үзенә генә хас кыенлыклар көтә диелгән иде.

Без сәхнәдә күпсанлы җырчылар белән дә, драма артистлары, нәфис сүз осталары белән дә очрашабыз. Һәркемгә мәгълүм булганча, болар арасында аерма шактый ук зур. Мәсәлән, җырчы гадәттә сәхнәгә ялгыз чыкмый, аның янәшәсендә һәрвакыт ышанычлы таянычы була. Әгәр шулай әйтергә яраса, җырчының иң якын партнеры — музыка. Ул җырын музыкага кушылып башкара. Инде драма артистына килгәндә, ул да сәхнәдә күп вакыт ялгыз гына булмый, башка артистлар белән бергә уйный. Шуның өстенә ул сәхнәгә үзе булып түгел, бәлки пьеса герое киеменә төренеп, гримланып чыга.

Нәфис сүз остасы исә яп-якты залга аның сөйләвен көтеп сәхнәгә текәлгән зур аудитория каршысына тормышта ничек булса, шулай гап-гади киемнән, япа-ялгыз берүзе килеп баса. Бу киеренке минутларда аудиториянең игътибарын җәлеп итү өчен кайберәүләр арзанлы каламбурлар сөйләп остара, бүтәннәре яңа гына чит илдән кайтарткан әкәмәт киемнәрен күрсәтергә ашыга.

Шөкерләр булсын, Айрат Арсланов артистлык маһирлыгын үзен калкурак итеп күрсәтү өчен түгел, бәлки укыла торган әсәрнең эстетик куәтен, андагы фикер пафосын мөмкин кадәр тулырак, тирәнрәк, тәэсирлерәк итеп ачып бирү өчен файдалана. Зур залларны тутырып утырган йөзләгән, күп вакыт хәтта меңләгән тамашачының игътибарын үзенә җәлеп итү, аны тыңлату, аны дулкынландыру өчен күпме көч, үз интонациясен табуга нинди юллар белән ирешә торгандыр, без анысын да белмибез. Артистның шигырь яки проза әсәре укыганда кайбер урыннарда тавышын җиңелчә генә үзгәртеп алуын, кайбер сүзләрне көчле басым белән әйтүен, ара-тирә кыска гына паузалар ясап алуын да сизми калабыз. Осталыкның мондый нечкә якларын артистның художниклык темпераменты үзеннән-үзе эшли. Шигырь дөньясына эчкәрәк кергән саен, артист дәртләнә бара, дулкынлана бара. Үзенең кайнар хисләрен дә өстәп, рухланып, илһамланып сөйләгәнлектән, әсәр җанлана, ул безнең аңыбызга сүзләрдән ясалган тере образлар дөньясы булып килеп керә. Сүзләр тылсымына бирелеп, без шигырьне язганда шагыйрь үзе нинди хисләр кичергән булса, шуларны ук кичерә башлыйбыз. Мәсәлән, Габдулла Тукайның «Шагыйрь» исемле шигырен тыңлаганда, күңелебездән Газраилгә шаян сүзләр әйтәбез. «Пар ат»ны сөйләгәндә, артистның үзен бөтенләй онытып, шагыйрь белән бергә тарантаска утырып Казанга киләбез, аның самими уйлары, хыяллары белән яшәп алабыз, Казанны күрү шатлыгы белән рәхәтләнәбез.

Кыскасы, артист шагыйрьнең рухи дөньясына алып керде, шагыйрь белән араларыбыз тагын да якыная, без аны тирәнрәк аңлый башлыйбыз.

Хәзерге кебек рухи ярлылыкка каршы көрәш барган заманда әдәби образлар дөньясын шулай тирәнтен ачып бируүнең әһәмияте ифрат зур.

Айрат Арслановның халыкта аңа зур ихтирам тудыра торган күркәм сыйфатларыннан тагын берсе, минемчә, аның әдәпле тыйнаклыгы, зәвык белән яши һәм эшли белүе. Сәхнәдә булсын, кешеләр белән аралашуында булсын, ул Шәриф Камал, Салих Сәйдәшев, Хәлил Әбҗәлилов һәм башкалар кебек элекке зыялыларыбызның күркәм традицияләрен дәвам иттерә, әдәбият-сәнгать әһелләренең дәрәҗәсен, аларның абруен тиешле югарылыкта саклый, ялтыравыклы эффектлардан, зәвыксыз кыланулардан һәрвакыт өстен тора. Чын сәнгать дөньясында аның лаеклы вәкиле булып яшәүчедә бу табигый хәл булса кирәк. Театр карарга, концерт тыңларга яки әдәби кичәгә килгән тамашачы моңлы җыр, нәфис сүз ишетеп, гыйбрәтле вакыйгалар күреп үзенең күңел хәзинәсен баету белән бергә пөхтәлек, матурлык, әдәплелек үрнәкләре белән дә очрашса, нур өстенә нур гына була түгелме?!

Россия Федерациясенең һәм Татарстанның халык артисты, тагын шундый байтак кына хөрмәтле исемнәр йөртүче Айрат Арсланов күп еллар дәвамында сәхнә осталары арасында иң хөрмәтлеләрдән, талантлылардан берсе булып танылa. Башкалада булсын, тугандаш республикаларда яисә үзебездә булсын, иң җаваплы тантаналы кичәләр аның катнашында уздырылып килде.

Ышанабыз ки, халыкның сөекле артисты Айрат Арсланов, яше ничәдә булуына карамастан, моннан соң да шулай иң алдынгы сафта барыр, һәрвакыт камиллеккә омтылучы күренекле сәхнә остасы булып яшәвен дәвам иттерер. Без аңа киләчәктә дә зур иҗат шатлыклары теләп калыйк.

*1988*

**ӘМИРХАН ЕНИКИ**

## Сүз турында сүз

Сүз сәнгате күп тармаклы. Шуның бик борынгы аерым бер тармагы — сүзне тыңлаучыга җиткерү сәнгате. Әйтик, ораторлык осталыгы — аңа бик борын заманнардан ук махсус өйрәтә дә булганнар...

Бездә дә бу осталыкка омтылу бик күптәннән яшәп килгән булса кирәк. Мәсәлән, иске мәдрәсәләрдә шәкертләрнең кара-каршы утырып бәхәсләшүләре шундый осталыкның үрнәкләре булмады микән?! Мәгәр хәзер яңа заманда без оста сөйләүчене гадәттә «нәфис сүз остасы» дибез, чөнки ул безгә шигырь сөйли йә әдәби әсәрләрдән өзек укый.

Миңа үз гомеремдә «нәфис сүз осталарының» төрлесен һәм бик шәпләрен тыңларга туры килде: Мохтар Мутин, Шакир Шамильский, Хәким Сәлимҗанов, Камал III, Мәкәрим Мәһдиевләрне... Ләкин алар барысы да бик мәшһүр театр артистлары — концертларда, әдәби кичәләрдә аларның чыгышлары бары һәвәскәрлек эше генә иде.

Нәфис сүз сөйләү профессиональ сәнгать буларак бездә сугыштан соң гына тәмам формалашты, һәм бу турыдан-туры Айрат Арслан исеме белән бәйләнгән. Сәхнәгә аяк басуы белән диярлек, нәфис сүз сөйләү аның төп иҗатына әверелде. Ул шуңа бөтен гомерен, көчен, сәләтен бирде һәм сүз сөйләүне чын сәнгать дәрәҗәсенә кадәр күтәрде. Моның өчен кирәкле сыйфатларны да — буй-сын, төс-кыяфәт, ягымлы тавышны да — Ходай аңардан кызганып тормаган. Ул гүя тумыштан ук коеп куйган нәфис сүз остасы!..

Айрат безгә күптән таныш, күптән без аны тыңлап киләбез. Ул безгә һәрвакыт тансык, һәрвакыт аның сөйләвен көтеп алабыз. Чын талант, чын осталыкның тылсымы бу...

Әмма күпме еллар дәвамында күпме генә ишетүемә карамастан, быелгы «Тукай көннәре«ндә Айрат Арсланны өр-яңадан күргәндәй һәм ачкандай булдым... Җиткерә белгәндә сүзнең кодрәте гаҗәп икән ул!.. Инде яшьтән үк таныш Тукай шигырьләрен Айрат Арсланнан ишеткән чакта мин сабыйлыктан бик иртә чыккан, бик тиз олыгайган яшь-яшь кенә шагыйребезнең ачы язмышы үз халкының авыр язмышы белән никадәр тыгыз бәйләнгән булуын, ләкин шул ук вакытта аның үтә ялгызлыгын, нәүмиз җанын, газаплы, мәгәр гаҗәп айнык уйларын аеруча бер тирәнлек вә тетрәнү белән аңлаган-тойгандай булдым. Минем өчен бу Тукайны яңадан тагы да тулырак ачу иде... Мин инде Айратның Тукай сүзләрен никадәр нечкә тоеп, белеп, дөрес, төгәл җиткерүен әйтеп тә тормыйм...

Кешенең сәнгатьтә үз урынын белеп, шуны гомере буена яратып биләве — бик зур бәхет ул, минемчә. Айрат Арслан менә шул бәхеткә һәм мәртәбәгә ирешкән шәхес. Безгә дә зур куаныч ул — аның үз урынында булуы һәм «нәфис сүзләре» белән сөендерүе...

Озакка сузылсын бу бәхет һәм бу куаныч!

*1996*

**ИЛДАР ЮЗЕЕВ**

## Нәфис сүз остасы

Айрат Арсланга

Йә, кил әле, Айрат, минем янга,
Сүзсез генә бергә утырыйк,
Дөнья мәшәкатен онытыйк та
Эчтән шигырь укып тын торыйк.

Якташлык та, әз-мәз Такташлык та,
Тукайлык та бераз бар бездә.
Омтылыш та аларныкы кебек,
Сулыш юллары да тар бездә.

Күпме чыктың инде сәхнәләргә,
Халкың өчен янып, пошынып,
Сулыш юлларыбыз кебек һаман
Милләтебез яши кысылып.

Олпат тавышыңны тыңлаганда,
Мин дә горурланып куямын,
Тукай, Такташ, Җәлил сулышының
Дәвамнарын синдә тоямын.

Кызыкмадык дөнья малларына,
«Сәнгать» диеп гомер кыскарттык:
Сарай җырчылары саналганчы
Күңелләргә керү мең артык!

Юк,
Син татарның Левитаны түгел,
Нәкъ безнеңчә милли Айраты,
Синдә халкыбызның затлылыгы,
Нәфислеге, өмет, гайрәте.

Яндык, туңдык, көйдек сәнгать өчен,
Кызганмадык йөрәк җылысын;
Яшик әле, Айрат, яшик әле
Озынайтып милләт сулышын!

*15.01.95.*

**МӨХӘММӘТ МӘҺДИЕВ**

## Бәхетле артист

Халкыбызның зур ихтирамын казанып, Айрат Арсланов менә дүрт дистә елдан артык инде сәхнәдә, эфирда, экранда яши. Шундый артистлар, шундый сүз сәнгате осталары була — халык аларны аеруча ярата, аеруча якын итә. Айрат Арсланов — шундый бәхеткә ия булган шәхесләрнең берсе. Шундый шигырьләр, монологлар була — аларны бары тик аерым артистлар гына укый, әсәрнең эчке тормышын, сүзләр «астындагы» тирән мәгънәсен ача ала. Айрат Арсланов — әсәрнең кеше күзенә беренче карашка ташланып тормаган әнә шул эчке дөньясын ачып, тамашачыга җиткерүче сирәк очрый торган (бездә, Татарстанда, диюем) талантларның берсе.

Кемгә ничектер, минем өчен Айрат Арсланов шәхесе телевизор экранында һәр көн яши. Әйе, үзе экранда һәр көн күренмәсә дә, яши. Мин Казан телевидение студиясе күрсәткән концертларның берсен дә калдырмаска тырышам, әйтергә кирәк, бик актив — шатланып, сокланып, дулап, очыргаланып карыйм.

Шатлыгым, соклануымның сәбәбе билгеле инде: кемдер үзен, тамашачыны, сәнгатьне ихтирам итеп җырлый, сөйли, синең белән әңгәмә кора, югары культуралылыгы белән сине тәрбияли, үстерә. Кемдер исә сине чыгырыңнан чыгара. Нәрсә белән? Культурасызлыгы, шамакайлыгы, наданлыгы белән. Аһ, дисең, Айрат җитми...

Менә берәү сәхнәгә чыга да арзанлы сүз, тәрбиясез хәрәкәтләр белән залны яулап алмакчы була. Менә җырчы үзе җырлыйсы җырның авторлары кем икәнлеген әйткәндә наданнарча нотык сөйли, сүзендә, җөмләсендә басымнар үзгәртелгәнлектән, туган телебез изелгән. Вульгар җөмлә, вульгар тавыш. Хәзер бөтен җырчы да инде «җыр бүләк итә», авыл сәхнәсендә булса «күчтәнәч җыр алып килә» һ.б. Аһ, дисең, Арсланов җитми. Шуның мәктәбе кайда соң?

Вульгарлык инде яшь җырчыларга, яшь конферансьеларга үтеп керде. Артистларның сәхнәдә, экранда кул хәрәкәтләрен күргәч, ачу чыга. Безнең булачак артистларга мимика, жестикуляция, ритмика дигән фәннәр бер дә укытылмыймыни соң? Нигә Айрат Арслановтан өйрәнмиләр?

Айратны халкыбыз ник ярата? Нигә сәхнәгә, экранга ул чыкканда тәнеңә, миеңә рәхәт дулкыннар йөгерә, нигә кинәт кенә сәнгатьнең зур, сихри дөньясына үзеңне тапшырасың? Чөнки Айрат Арсланов сәхнә культурасына ия.

Айрат кебекләрне руслар «туганда ук күлмәк киеп туган» диләр. Ягъни гомер юлында юлдашы гел бәхет булган. Бәхет, әлбәттә, бик күп нәрсәләрдән тора, әмма шуларның берсе бәхәссез. Ул — тормыш юлында игелекле остазлар очрату.

Айратка әнә шундый бәхет насыйп булган. Казан дәүләт театр училищесында укыганда актерлык осталыгына аны Сәет Булатов, Кәшифә Тумашева, Ширияздан Сарымсаков кебек сәнгатькә фидаиләрчә бирелгән остазлар өйрәткән. Бәхет аны Мәскәүдәге Театр сәнгате институтына укырга кергәч тә калдырмаган. Анда ул профессорлардан И.С.Анисимова-Вульф, Я.М.Смоленский, С.А.Кочарян кебек олы сәнгатьнең зур осталары кулында белемен күтәрә.

Казанда телестудия ачылган көннәрдә аның экраннарыннан халкыбызга рәхәт, мәгънәле мизгелләр тапшыру өчен, кара таш астыннан әле генә коткарылган Бурнашыбызның Таһирын сәхнәдә уйнап, халыкны таң калдырыр өчен, Айрат Арсланов дигән артист барлыкка килә...

Табигать биргән бәхете дә сокланырлык инде. Сәхнәдә Айратны күргәндә, минем хәтеремә гел Мирхәйдәр Фәйзи сүзләре килә («Галиябану»дан): «Төсен, буен, акылын, фигылен, белемен, җитезлеген, үткерлеген Ходай «мә сиңа!» дип биргән дә куйган инде».

Әнә шул кыйммәтле табигый сыйфатлары янына аның югары сәхнә культурасы, зыялылыгы, эрудициясе, саф сөйләме (татарча һәм русча) килеп кушылган, һәм сәхнәдә, экранда соклангыч актер барлыкка килгән. Героик планда укыганда, ул безнең алда Маяковскийны, Симоновны, Такташны терелтә; Моабиттан Муса тавышы ишетелә. Тукай, Җәлил, Туфан шигырьләре һәм героик, һәм лирик планда яңгырый — Айрат Арсланов һәр программаның эчтәлеген, адресын, максатын, акцентын үзе билгели. Арсланов тавышы аша Тукай иҗатына багышланган программада без шагыйрьне өр-яңадан «укыйбыз», аңлыйбыз. Тукай Арсланов тапшыруында мескен түгел, фәкыйрь түгел, ул — көр тавышлы горур ир дә, лирик-эмоциональ күңелле, җәрәхәтле йөрәкле нечкә шагыйрь дә. Җәлилне дә шулай киң планда яңгырата Айрат. Игътибар итегез: «Синме соң бу, бөек Маркс иле?» — дип укый башлаганда, Айратның тавышы трагик кырык өенче, кырык дүртенче елларны, төрмә камерасы аһәңен бирә, колакка соры яңгырлы дәһшәтле Берлин төне эченнән ташкапчыктагы шагыйрьнең соңгы авазы ишетелә.

Язмыш безгә, арабызда Тукай образы яшәсен, Дәрдмәнд, Рәмиев, Җәлил, Туфан тавышлары һәрчак ишетелеп торсын өчен, мәһабәт кыяфәтле, бәрхет тавышлы Айрат Арслановны биргән...

*1989*

**ГАРИФ АХУНОВ**

## Сәхнәдә _

## Айрат Арсланов

Безгә, бер төркем татар язучыларына, Татарстанның эстрада осталары белән бергәләп Донбасс якларында булырга туры килде. Гадәттә, халык белән очрашуларда язучыларның игелекле юлдашлары актерлар була, андый очрашуларга, җилкәсендә мең төрле эш, мәшәкать булуга карамастан, Айрат Арсланов та бик теләп катнаша.

1972 елгы яз аендагы сәяхәтебез, СССР төзелүгә илле ел тулу уңае белән Украинаның Ворошиловград өлкәсендә үткәрелгән татар әдәбияты атналыгы көннәре, минем үземдә Айрат Арсланов иҗаты хакында мәкалә язып чыгу теләген уятты.

Бу, әлбәттә, беренче сызмалар. Мин һич кенә дә тулылыкка, нәфис сүз сөйләүнең барлык нечкәлекләренә төшеп язуга дәгъва кылмыйм. Максатым тыйнаграк: Айрат Арсланов иҗатының берничә төп моментына сәнгать белгечләребезнең һәм сәнгать сөючеләребезнең игътибарын юнәлтү.

**Халык улы булуыңны аңлау.** Атналыкка без унике язучы, биш җырчы, бер нәфис сүз остасы һәм берничә журналист барган идек. Ворошиловград предприятиеләрендә чыгышлар ясаганнан соң, безне, төркемнәргә бүлеп, районнарга чыгарып җибәрделәр.

Дүрт-биш кешелек безнең төркемдә Айрат Арсланов та бар иде. Безгә Кременное, Рубежное кебек шахтерлар шәһәрләрендә дә, ТЭЦ төзүчеләр янында да, терлекчеләр җәйләүләрендә дә булырга туры килде. Юллар һәр урында да асфальт түгел, басу юллары бар, тузаны бар, баш өстендә утлы шар кебек кыздырып торган кайнар кояшы бар, көн саен шундый юллардан йөзәр чакрым җир узарга туры килә. Табигыйдер ки, эсселектән, юлдан, тузаннан шактый ук арыган язучының, актерның шушы хәлләргә җайлашып, җәйләүләрдә җиңелчәрәк киемнән, өс-башын сәхнә киеменә алмаштырмыйча сөйләргә дә омтылуы мөмкин. Әмма бу очракта безнең барыбызга да мисал булып Айрат Арсланов килеп чыга иде. Йөзәр чакрымлы юлга ул кунак йортыннан дәү бер чемодан да күтәреп чыга. Бактың исә анда шыплап тутырган нәрсә дә юк, бик һәйбәтләп үтүкләп салынган сәхнә костюмы. Безнең Айратыбыз шул зур чемоданны, кайда гына бармыйк, һәрвакыт үзе белән йөртә, иң кыен урыннарда, мәсәлән, төзелеп яткан ТЭЦның таш-кирпеч өемнәре арасына яки берәр будкага барып киенә һәм... халык алдына һәркайчан ялт итеп торган киемнән, пөхтә булып, матур булып, гаять төз һәм зифа булып килеп чыга.

Пөхтә киенү, чибәр күренергә тырышу кешенең тумыштан ук килгән табигый бер гадәте булырга мөмкин, һәм бу шулай ук сәнгать кешесенең үз урынын, дәрәҗәсен белеп, аңлы рәвештә эшләгән эше дә булырга мөмкин.

Айрат Арслановта боларның һәр икесе бергә кушылган. Әмма аңлы рәвештә алып барганы көчлерәк булса кирәк. Без аңардан үзара, якын итеп: «Ничек син һәрбер очрашуга шулхәтле дә пөхтә киенергә, иң кыен шартларда да тышкы кыяфәтеңне сакларга иренмисең?» — дип сорагач, ул гади генә итеп болай дип җавап бирде:

— Без бит Татарстаннан килдек. Безне татар халкының уллары итеп кабул итәләр. Ничек инде үз халкыңны, Максим Горькийлар, Чеховлар патша Россиясенең иң авыр елларында да пөхтәлек һәм хезмәт сөю ягыннан зурлап телгә алган халкыңны, бүген, чиста-пөхтә киенү өчен бөтен шартлар булган заманда ким итеп күрсәтәсең?!

Әйе, Айрат Арсланов белән бер атна йөргән чакта, без, язучылар, аңарда үз халкыңның улы булу тойгысы ифрат зур икәнне күрдек. Минемчә, бу тойгы һәркемнең канына сеңгән булырга тиеш.

**Җаваплылык тойгысы.** Актердагы бу сыйфат турыдан-туры аның беренче сыйфатына килеп тоташа, алай гына да түгел, аның шул сыйфатыннан үсеп тә чыга. Үз халкыңның улы булуны аңлау тойгысы ул үз халкыңның нәрсәгә сәләтле икәнен башка халыкларга мөмкин хәтле тулырак итеп китереп җиткерү дигән сүз түгелме?

Әгәр бу шулай икән, актер үзен һәр җәһәттән камил югарылыкка күтәрергә тиеш. Иҗаттагы җаваплылык тойгысы программа төзүдән башлана.

Айрат Арсланов, артистларның үз терминнары белән әйтсәк, сөйләү жанрында егерме ел буена эшләп килә. (Башка жанрлардагы хезмәте хакында соңыннанрак сөйләрбез.) Егерме ел вакыт эчендә ул дистәдән артык программа төзеде, һәр программасын нык уйлап төзеде, гражданлык позициясе белән югары сәнгать законын бергә куша алуын раслады һәм шул сәбәпле ул иң таләпчән тамашачы, башкалабыз Мәскәү тамашачылары алдында да югары бәя алды. Программаларга күз салыйк:

Туган ягым — Татарстан
Татар совет поэзиясе
Шагыйрь гомере (Г.Тукай поэзиясе)
Герой-шагыйрь Муса Җәлил
Бөтен тавышка (В.Маяковский поэзиясе)
Мәхәббәт лирикасы
Кыска хикәя кичәсе
Антон Чехов хикәяләре
Чит ил поэзиясе кичәсе
Мин — Советлар иле гражданины
Күңелем Ленин белән сөйләшә.

Бу программаларда беренче карауга ук тирән идеялелек, җаваплылык күзгә ташлана. Татар совет поэзиясенең, татар классик поэзиясенең югары үрнәкләре сайланып, ныклы бер композициягә корылган. Аннары рус шагыйрьләре, рус язучылары, илебезнең барлык якларында яшәүче тугандаш халыкларның әдипләре тупланган. Әгәр актерның һәр программасын җентекләп күздән үткәрсәгез, аларның нинди зур җитдилек һәм киң диапазон белән төзелгәненә игътибар итми кала алмассыз.

Иң элек бер нәрсәне онытмыйк: сәнгать иҗатчыдан чама хисе, такт һәм югары зәвыклы булуны таләп итә.

Айрат Арсланов төзегән программаларда чын мәгънәсендәге талантлы зур язучылар, зур шагыйрьләр генә түгел, аларның да үз гомерләрендә иҗат иткән иң көчле әсәрләре, өстәвенә актерның үзе иҗат иткән программага, үзе халыкка тәкъдим итәчәк образга туры килә торган әсәрләре алына.

Дистәдән артык программаның төзелү принципларын сөйләп чыгар өчен генә дә нәфис сүз сәнгате хакында зур бер китап язарга кирәк булыр иде, һәм мин Айрат Арслановның эш үрнәгендә андый китап әле язылыр дип бик нык ышанам! Ә хәзергә программаның бары тик икесенә — «Күңелем Ленин белән сөйләшә»гә һәм Ворошиловград программасына гына тукталам. Шушы ике программа А.Арслановның сәхнә почеркын, актерның йөзен һәм зәвыгын беркадәр ачып бирә алыр дип уйлыйм.

Иң элек Ворошиловград программасы турында. «Дуслыкның көче океан» дигән программаның унбиш минутлык бер кисәге иде бу.

Айрат Арсланов — ялт итеп киенгән, озын буйлы, искиткеч ягымлы йөзле актер — халык алдына чыгып баса. «Сәхнә ягымлылыгы актерның ярты уңышы», — дигән К.Станиславский. Безнең Айратыбыз белән зал арасында шундук үзара ягымлы аңлашу, бер-берсенә ышану тойгысы уяна. «Здравствуйте!» — дип русчалап дәшә Арсланов. Бу аның, Татарстан вәкиленең, Донбасс шахтерлары белән исәнләшүе дә, шул ук вакытта рус шагыйре Владимир Солоухин шигыренең исемен әйтүе дә.

Актерның йомшак матур тембрлы тавышы зал өстенә агыла башлый. Бар иде бит безнең матур бер гадәтебез, без бер-беребезгә «Исәнмесез!» дип дәшә идек, юл чите тездән кар булса да, хәтта ләпек булса да, читкә чыгып юл бирә идек. Без ул гадәтләребезне шау-шулы шәһәрләрдә югалта башладык түгелме? Чыннан да, халык ташкыны агылып торган Горький урамында яки ГУМда һәр кеше белән берәм-берәм исәнләшеп йөрмәссең бит. Ә «Исәнмесез!» — нинди олы сүз, нинди ягымлы сүз, сәламәтлегегез әйбәтме, исәнсау яшисезме дигән сүз бит инде. Ә менә хәзер мин сезгә зур бер шатлык хисе белән күңел тойгымны әйтеп бирә алам: «Здравствуйте!» — «Исәнмесез!»

Зал өстеннән янә бер мәртәбә ягымлы эчкерсез елмаю, дустанә хис уза. Актер белән халык арасы тагын да якыная, тагын да җылына төшә кебек. Менә шуннан инде Арсланов украин шагыйре Рядченконың Муса Җәлилгә багышланган шигырен укый. Ни өчен татар шагыйренең яки башка халык шагыйренең түгел?

Беренчедән, без тугандаш украин халкы җирендә, икенчедән, Рядченко Муса батырлыгының төп мәгънәсен башка шагыйрьләргә караганда кыскарак та, остарак та итеп әйтеп бирә алган. Игътибар итик, «Исәнмесез!»не укыган чактагы Айрат тавышындагы лирик җылылык, дуслар белән күрешү сөенече инде бу юлы җир өстеннән узган трагедияне аңлату, фашист палачларына карата аяусыз нәфрәт хисе — Айрат тавышындагы интонацияләр — залны электрлаштыра, гүя халык йөрәгеннән кайнар ток уза. Салават күперендәге төрле төсләр кебек, Айрат тавышындагы интонацияләр үтә дә табигый рәвештә үсә, үзгәрә, байый бара, совет поэзиясенең йөз аклыгы булган Җәлилгә, шагыйрьне тудырган һәм үстергән Татарстан җиренә карата рәхмәт хисе булып тулышып җитә. Әнә шундый табигый җирлекне тудырганнан соң гына актер Муса Җәлилнең үз шигырьләрен укуга күчә. «Ышанма» шигыре белән ул аны барыннан да бигрәк туганүскән җиреннән, гаиләсеннән еракта газап чигүче тоткын шагыйрь итеп, кеше итеп бирә. Аннары геройшагыйрьнең ташкапчыкта рухы сынмавын аның шаян шигыре аша җиткереп, оптимистлыгын раслый, «Татарлар елмаеп үлделәр!» дип, Мусалар үлемен күргән шаһитлар әйткән сүзне сәнгать теле белән исбат итеп бирә, тик шуннан соң гына туган халкына, Совет ватанына, совет поэзиясенә васыять итеп әйткән «Җырларым» шигырен сөйли. Юк, сөйли дип әйтү аз, ул драматик актер булып, әйе, әйе, нәкъ менә драматик актер булып Муса батыр монологын залга әйтеп бирә. Менә шунда аңа Татар дәүләт академия театрында эшләп, драматик актер булып җыйган тәҗрибәсе ярдәмгә килә. Сөйләү жанрына өстәлгән ныклык, җитдилек аның сәнгатенә академтеатрдан башлап салынды, ә ул үзе, шул ныклыкны, чынлыкны, үз-үзен тотуда, халык белән уртак тел табуда булган ышанычын театрда таптым дип, «академ»га күңелендә рәхмәт хисе саклап йөри. Нәфис сүз осталары, дөресрәге, сөйләү жанрында эшләүчеләр өчен драматик театр әйләнеп узылмаска тиешле зур бер мәктәп дип карый.

Безнеңчә, бу шулай ук Айрат Арслановның үз иҗатына булган таләпчәнлегенең, халык алдында җаваплылык хисе тоеп эшләвенең тагын бер әйбәт мисалы.

Айрат Арслановның талантын халык та, Татарстан хөкүмәте дә аның иҗатының беренче дәверендә үк күрделәр. 1957 елда Мәскәүдә үткәрелгән татар әдәбияты һәм сәнгате декадасыннан соң ук аңа «Татарстанның атказанган артисты» дигән мактаулы исем бирелде.

Әнә шул исемне әле алга таба аклыйсы, үстерәсе, сәнгатьтә беркетәсе бар иде. Сәнгатьтә барлык художниклар омтылган һәм барлык җан җылылыгын салып эшләгән бер тема бар. Ул — Ленин темасы.

Айрат Арслановның да дистәдән артык программасы арасында Ленин темасы аерым бер югарылыкта тора.

Моңа ул гаять зур эзләнүләр, иҗат газаплары аша килде.

Татарстанның атказанган артисты Айрат Арслановка «Күңелем Ленин белән сөйләшә» исемле концерт программасы өчен 1969 елны республикабызның иң зур бүләге — Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе бирелде. Бу — эстрадада сөйләү жанрының югары бәя алуы иде.

Моңарчы без Айрат Арслановның иҗат алымына, иҗаттагы үсешенә тукталдык. Ләкин иҗаттагы үсеш художникның җәмгыятьтәге урыныннан беркайчан да аерым була алмый. Моны инде безнең Тукаебыз моннан алтмыш еллар элек үк әйтеп калдырган. Айрат Арсланов егерме елдан артык иҗат эшчәнлегендә илебезнең бик күп калаларында — Мәскәүдә һәм Ленинградта, Ульяновскида һәм Волгоградта, Свердловскида һәм Чиләбедә, Оренбургта һәм Уфада, Төмәндә һәм Томскида, Ташкентта һәм Сәмәркандта, тагын бик күп, бик күп калаларда булып татар һәм рус телләрендә совет әдәбиятын пропагандалады, татарның нәфис сүз сәнгатен күтәрде. Язучылар бригадалары, әдәби атналыклар, Мәскәүдә үткәрелгән Тукай һәм Такташ бәйрәмнәрендә татар совет әдәбиятының, татар классик әдәбиятының җегәрен һәм нәфислеген, илебез халыклары әдәбиятлары белән тугандаш гаиләдә гөрләп үсеп килүен күрсәтеп бирде.

Бөтенроссия конкурсларында ул ике мәртәбә лауреат булып дипломнар һәм кыйммәтле бүләкләр алды. Татарстан радиосында һәм телевидениесендә тамашачыларыбыз аның тавышын ишетеп, йөзен күреп тордылар.

Кабатлап әйтәбез, Айрат Арслановның сөйләү жанрында ирешкән уңышлары безне канәгатьләндерә һәм, күңелдәгесен яшерми әйткән чакта, бераз хәвефкә дә төшерә. Безнең менә дигән җырчыларыбыз бар. Ул өлкәдә өлкән җырчылар тәҗрибәсе тупланды, урта буын халык ихтирамын казанды, яшь җырчыларыбыз үсеп килә.

Ә менә сөйләү жанрында инде ветераннар булган Фәйзи Йосыпов, Әзәл Яһүдин кебек эстрада артистларына алмаш килмәгән кебек, Айрат Арсланов артыннан да ялтырап үсеп килүче нәфис сүз остасы юк. Казанның театр училищесында, культура институты филиалында һәм Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә нәфис сүз осталарының яңа буынын тәрбияләү, татар әдәбиятын пропагандалау мәсьәләләре көн тәртибенә җитди итеп куелырга тиештер.

Без, язучылар, бу сәяхәттән Айрат Арслановның югары сәнгать законнары буенча башкарган зур хезмәте Ворошиловград өлкәсе хезмәт ияләрендә тирән ихтирам һәм зур соклану уятуын күреп кайттык.

*1978*

**ШӘҮКӘТ ГАЛИЕВ**

Талантлы замандашым
халык артисты *Айрат Арслановка* мәдхия

Татар улы, шигъриятнең чын
үзе син:
Синдә моң да, горурлык та,
синдә гайрәт.
Туган телнең даһилары исеменнән
Син лаеклы, вәкаләтле илче, Айрат.

Күрде илләр, ишеттеләр һәр
тарафта,
Шигарендә Тукай — Гимн,
Җәлил — Байрак.
Күтәрелдең һәм күтәрдең
күңелләрне
Сәхнәбезнең уртасында
күкрәп-кайнап.

Халкыбызда бу затлылык вә
күркәмлек
Киләдер ул борынгыдан,
алыслардан.
Юк, вакланмый, яши милләт,
иманы сау —
Туа тора дөньябызга Арсланнар!

*1996*

**РОБЕРТ МИҢНУЛЛИН**

# Татар арысланы!

Заманында «Азат хатын» журналы редакциясе Баумандагы «Елочка» кафесында бик күңелле очрашулар уздыра торган иде. Шуларның берсенә яшь шагыйрь сыйфатында мине дә чакырдылар. Кунаклар арасында Айрат Арсланов та утыра. Ерактан ук аерылып, игътибарны үзенә җәлеп иттереп торганы исемдә калган. Мәҗлестә ул да шигырь укыды, мин дә. «Әнкәй» белән «Каз өмәсе»н укыдым шикелле. Тәнәфестә якыннанрак таныштык. Танышуга ук: «Шигырьләреңне әйбәт укыдың, тавышың да бик матур тембрлы икән. Беләсеңме, радиога ир-ат диктор кирәк. Син Мәрьям апаң янына бар әле, тыңласын әле тавышыңны. Мин аңа синең хакта әйтеп куярмын», — диде дә бөтенләй өнсез калдырды мине Айрат абый. Ык-мык итеп тордым да «ярар» дигәнне аңлатып башымны каккан булдым.

Мәрьям апа Арсланова ул вакытта радиода, чыннан да, диктор булып эшли иде. Бардым мин аның янына. Утыртты да «Социалистик Татарстан» гәзитеннән берничә кыска гына чит ил хәбәре укырга кушты. Кат-кат укытты. Тырыша-тырыша авыз эченнән ботка пешереп бик озак утырдым. Мәрьям апа тагын килергә кушты. Кая ул бару! Үз-үземне белеп, аяк та атламадым, билгеле...

Айрат абый белән шуннан бирле таныш без. Очрашып, аралашып торабыз. Кичәләрдә, концертларда бергәләп чыгышлар ясыйбыз. Безне якынайткан ике сәбәп бар. Аның беренчесе — шигърият, икенчесе — Башкортстан. Шуңа күрә безнең сөйләшер сүзләребез дә, уртак фикерләребез дә җитәрлек. Якын иткәнгәдер инде, ул минем шигырьләремне дә үзенең репертуарыннан төшерми. Миңа багышланган кичәләрдә,

радио- телетапшыруларда да бик теләп катнаша. Иҗатым хакында матур-матур фикерләр әйтергә дә тарсынмый. Гомумән, киң күңелле, эрудицияле, зыялы иҗат кешеләребезнең күренеклесе ул.

Татар турында сүз чыкса, мин һәрвакыт Айрат Арслановны күз алдына китерәм. Менә кем ул чын татар! Ул килеш-килбәте, ул кыяфәте, ул тавышы! Югыйсә татарны киноларда, спектакльләрдә, сурәтләрдә, әдәби әсәрләрдә, һичшиксез, кысык күзле, карсак гәүдәле, кәкре аяклы, нәзек тавышлы азиат итеп күрсәтү гадәткә кергән. Типик кыяфәтле татар кешесе шундый була, янәсе. Ә минем шулай уйлаучыларга Айрат абыйны күрсәтәсем килә. «Карап калыгыз, күреп калыгыз! Чын татар шушындыйрак була инде ул!» — дисем килә.

Айрат Арсланов — безнең сүз сәнгатен бик биеккә күтәргән, олы сәнгать дәрәҗәсенә җиткергән олуг артистыбыз. Татар шигърияте, аеруча Тукай белән Җәлил иҗатын пропагандалауда ул әйтеп бетергесез фидакарьлек эшләде. Аннары шунысын да онытмаска кирәк: ул татарча да, русча да бердәй матур итеп сөйли. Димәк, ул татар шигърияте башка халыкларга да кирәгенчә җиткерә алды. Шуның белән татарны да күтәрде!..

Концерт бара. Конферансьеның яңгыравыклы сүзләре яңгырый: «Сәхнәдә — Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык артисты, Тукай бүләге лауреаты, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов». Менә ул! Озын төз гәүдә! Бөркет карашлар! Стереотавыш! Хәзер барыбызга да газиз татар шигыре, татар сүзе яңгыраячак. Ул Сүзне татарның асыл тавышлы улы, татарның арысланы Айрат Гәрәй углы Арсланов яңгыратачак!

*1996*

## МАРСЕЛЬ ГАЛИЕВ

### Могтәбәр замандашыбыз

Ул — татар затлысы менә нинди була дип, Парижларда йөртерлек мәһабәт ир-егет.

Ул — телебезнең бай аһәңен бүтән милләт кешеләренә дә җиткерә алу осталыгына ия.

Ул — тышкы кыяфәт, гәүдә тотышы, эчке мәдәнилеге, зыялылыгы, кылган эше белән егерменче гасыр татар шәхесе дигән титулга ирешә ала.

Ул — могтәбәр замандашыбыз Айрат Арсланов!

Милләтнең тыны кысылган заманнарда да ул олы сәхнәләрдән торып сүз кодрәтен халыкка җиткерде, көчле, җанга якын җылы тавышы, шигъри сүз ганимәте белән күңелләргә шифа бирде.

Айрат ага шигъри әсәр укыганда, залны иңләп аккан күкрәү тавышына мин әсир ителәм, башны югары чөям, күкрәк читлеге киңәя, сулыш иркенәя, эчтәге горурлык шулай бөркет булып кагына башлый.

Айрат ага сүз остасы, танылган артист кына түгел, сәләтле укучы да, үзенә нектар эзләп, рухына хуш килгән әсәр табу нияте белән ул үз гомерендә бихисап санда китаплар укыгандыр, шагыйрь-әдипләрнең мирасыннан яисә бүгенге иҗат хәзинәсеннән тапкан асыл юллар белән ул үзе генә хозурланып калмый, халык-тамашачы белән бүлешергә дип, олы сәхнәгә ашыга.

Ул сәнгатьле итеп укыганда, мин Тукайның мәхәббәт шигырен яңадан ачтым, әрнү-гамьнәрен эчтә саклаган Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрнең күңел коесы тирәнлеген тойдым.

Айрат ага сөйли... Тетрәндергеч тавышы әле дә колагымда... Күзгә яшь килә...

— Сагындым, бик сагындым сине, Туган ил!

Бу — Гадел Кутуйның чит ил туфрагыннан торып бәхилләшүе...

Айрат аганың кылган хезмәтләре — халыкның күз уңында. Шундый шәхесне безнең чорга биргән өчен Тәңрегә рәхмәт. Ул бүген дә мәйдан уртасында — сәхнә түрендә. Аңа бәрәкәтле алкышлар яңгырын мул иңдерсен Ходай...

*1997*

## ФӘНЗАМАН БАТТАЛ

### Тукай илчесе

Милләт язмышы, тормыш хикмәтләре, чорыбыз шәхесләренең гамәлләре хакында уйга чумган чакларымда, ни хикмәттер, янәшәмдә Тукай утырганын тоям. Ул фикер агышымны барлап, нәтиҗә һәм бәяләремне үз үлчәве белән үлчәп, киңәш биреп торадыр сыман...

Менә бу юлы да шулай булды. Ошбу язмамны нинди фикердән, кайсы җөмләдән башларга аптырап утыруымны сизгән сыман, күңелемә аваз салды:

— Менә син хәзер Айрат Арслан дигән мөхтәрәм вә могтәбәр замандашың турында язмакчысың. Ә бит аңа мин дә зур бурычлымын! Әгәр минем шигырьләрем бу җиһанга аның илаһи вә көр тавышы аркылы яңгырамаган булса, әйтүе кыен, мине милләт бу дәрәҗәдә үк аңлар һәм зурлар иде микән?..

Урынымнан кабаланып диярлек торам да фатирым фонотекасына чирек гасыр элек кереп урнашкан патефон тәлинкәсен магнитолага урнаштырып куям. Менә ул бөек Тукайны тагын да бөек иткән тавыш! Менә ул газиз Тукайны һәр татарга гына түгел, башка милләтләргә дә бөтен барлыгы, бөтен асылы белән таныткан, киң җиһан күрерлек итеп күтәргән тавыш:

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!..

Кемгә ничектер, Айрат Арслановның тавышын тыңлаганда, минем күз алдыма кыраулы һәм чалт аяз көзге таң килә. Әнә кояш күтәрелеп килә. Изрәп яткан урман-болыннарга, түгәрәк аланнарга, алтын белән өретелгән иксез-чиксез кырларга күктән илаһи тавыш иңә. Әйе, нәкъ менә күктән иңә! Бу тавыш борчуларыңны җилгәреп ташлый да, һаваңны сафландырып, сулышыңны киңәйтеп, милләтең яшәгән әтрафны күзәтү өчен үз янына — күккә чакыра:

Җөмләтән изге икән ич: инешең, чишмәң, кырың,
Юлларың, авыл, әвен, кибәннәрең дә ындырың...

Бу фани дөньяга аны, үзенең илчесе итеп, Тукай рухы озаткандыр.

— Язуын яздым, Айрат энем, вәхаләнки, тавышымда хөрлек җитсә дә, көрлек җитмәде... Барча язганнарымны маңлаемнан сөеп үстергән милләтемә ишеттерсәңче! — дип озатып калгандыр...

Хәер, ил каршында чын ир дә, шагыйрь дә булып танылганнарның кайсысын гына күтәрмәде һәм куандырмады икән Айрат Арсланов үзенең биниһая сәләте, сокланргыч сәнгате белән! Такташ, Җәлил, Фатих Кәрим, Сибгат Хәким, Туфан рухлары гына түгел, Пушкин, Гете, Гейне, Лермонтов, Шиллер, Шевченко, Абай җаннары да тәкбир әйтеп торадыр аңа. Исәннәр арасындагы рәхмәтлеләрне исә санап чыгу да мөмкин түгелдер. Ә инде аның тавышы белән хозурланып үзләрен бәхетле тойганнар миллионнар белән исәпләнә. Алары — милләтнең үзе!

Әйе, укучым вакытлы кисәтә, Айрат Арсланов шигърияткә генә җигелгән ат түгел. Аның талантына проза да, драматургия дә буйсына. Буйсына гына түгел, ошбу сәнгать остасының игътибарына керергә ашкына. Һәр сүзгә, һәр фикер һәм авазга зур таләпчәнлек белән якын килүче Айрат алдына чиле-пешле, сай мәгънәле әсәр сала алмыйсың. Иҗат кадерен дә, үз мәртәбәсен дә яхшы белүче олуг артист капмый арзанлы кармакка — и вәссәлам! Чөнки беләм: ул, шул ук Тукаебыз әйтмешли, бар нәрсәдән дә изге һәм хөрмәтле милләт каршында һәр чыгышы белән имтихан тота. Ә чын татар, халкын ихтирам иткән татар, милләтен дөнья бәрабәренә дә сатарга тиеш түгел.

Мәртәбә дидек... Мәртәбә ул мактаулы дәрәҗә генә түгел, гомер буена күтәреп барачак йөгең дә! Адәм баласы, ни хикмәттер, иң элек әнә шул йөкне табарга тырыша. Дөресрәге, кабилиятенә карап, Ходай шул юлга кертеп җибәрә. Әгәр Ул сине кайсы да булса мәсләк өчен яратып та, ниндидер сәбәпләр аркасында үз арбаңнан төшеп каласың яки йөгәнне бүтән тарафка тартасың икән, гомерең буе бәхет күрмәячәксең... Бу җәһәттән Айрат балачактан ук бәхетле булды. Башкортстанның Бүздәк районында туган малай мәктәп елларында ук үзенең чибәр, тыйнак, белемгә омтылышы, «асыл сөякле» булуы белән якташларының игътибарын җәлеп итә. Матур көй яки мәгънәле шигырь ишетсә, сихерләнеп, Левитанныкыдай тавыш тыңлаганда әсәрләнеп калучы яшүсмер сыйныфташларыннан нык аерыла. Ләкин үзе бу аермалыкларны сизми: бүтән яшьтәшләре белән бергә Танып елгасында су коена, туган ягының хозурлыгына сокланасоклана балык тота, җиләк-җимеш җыя. Иске Балтач урта мәктәбендә укый башлагач, мәдәният йорты егетнең кыйбласына әверелә. Драма түгәрәгенә йөреп тәүге тапкыр сәхнәгә менүләр, район радиостудиясеннән шигырь укулар!.. Һәй, бу гомернең иң бәхетле, «иң бөек» мизгелләре шул елларда калмады микән?! Менә бүген җитмеш яшен түгәрәкләп йөрүче мәшһүр Айрат Арслановка әнә шул сорауны бирсәк, мөгаен, килешер иде безнең белән, килешер иде! Алсу таңлы, канатлы яшьлеге турында сөйләгәндә карашында очкыннар уйнавы, шул очкыннар арасында моң-сагышларның җемелдәп-җемелдәп куюлары шуны раслап тора сыман.

Ләкин яшьлек канатлары туктаусыз алга җилпенә. Кеше әле бу чорда олыгаю яки картаю ихтималын башына да китерми: ул — алга ыргылучы тулпар. Сәнгать мохитенә томырылырдай булып үскән Айрат, урта мәктәпне тәмамлауга ук, татар дөньясының — үз милләтенең башкаласына — Казанга ашкына. Татар дәүләт театр училищесы аңа үз кочагын ача. Үсеп килүче нәфис сүз остасының училище тәмамлавын бер яктан Татарстан радиосы, икенче яктан Дәүләт театры көтеп тора. Ниһаять, ул — актер, радиотыңлаучылар мәхәббәтен казана башлаган диктор да! Барысы да канәгать! Ләкин үзе канәгать түгел... Мәскәүнең Луначарский исемендәге театр институтына керә, тәмамлый, Галиәсгар Камал исемендәге Академия театрына актер булып кайта, татар һәм дөнья классиклары әсәрләрендәге геройларны сәхнәдә гәүдәләндерә. Нәфис сүз остасы буларак, аны Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе үзенә чакырып тора, дөньяның татарлар яшәгән төбәкләре көтә... Кайда гына барып чыкмасын, ул — «татарның визит карточкасы»:

чибәр, мәһабәт, горур һәм... ягымлы! Ул менгән сәхнәләрдән татар халкының гасырлар буе чарланган теле бөтен аһәңе, камиллеге белән яңгырый. Нинди генә әсәр укымасын Айрат, нәрсә генә сөйләмәсен, һәр татарда уртак фикер туа: «Татар икәнсең, әнә шуның кебек булырга тырыш!»

Кем әйтмешли, зур базарның товары да мул: Айрат Арсланов күптән инде Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Хезмәт Кызыл Байрагы ордены иясе. Хәер, ул лаек булган мәртәбәләрне, илкүләм конкурсларда алган дипломнарны санап чыгарга ниятләсәң, бу язманың яртысы зур исемлектән гыйбарәт булыр иде... «Мелодия» фирмасында чыккан граммофон тәлинкәләре күпме тагын! Йөз меңнәр белән таралучы бу тәлинкәләр кайсы гына илдәге кайсы өйнең түр башында татар теленең, сәнгатенең кадерле илчесе булып «утырмады» һәм милләтнең олуглыгына инандырмады икән?

— Иллә дә мәгәр үзең баруга җитми! — ди Айрат әфәнде.

Чөнки үзе генә түгел, барлык милләттәшләр дә белеп-күреп торалар: ерак Сахалинга яки Владивостокка барып чыгамы Айрат Арсланов, әллә Якут-Сахада, Урта Азия илләрендә гастрольдә йөриме, Мәскәү, Ленинград (бу очракта шәһәрнең исеме шулай гаделрәк), Норильск яки Урал төбәкләрендә чыгышлар ясыймы, дөньяга сибелгән татар һәркайда сокланудан баш иеп, мөмкинлек туса, аркасыннан, башыннан сөеп рәхмәт әйтә. Менә болары инде һәр бүләктән югарырак, рәсми дәрәҗәләрдән кадерлерәк!

Менә сәхнәдә — Айрат Арсланов. Ул мәһабәт һәйкәл сыман. Авызыннан чыккан сүзнең мәгънәсе генә түгел, төсе дә, исе дә, ерак бабалар дәверенә барып тоташкан тамыры да бар сыман. Яңгыраган һәр сүз сандалга үз вакытында килеп төшкән саллы чүкечне хәтерләтә. Паузалар, гүя миллисекундлар белән үлчәнеп, эталон дәрәҗәсенә китерелгән. Көчле аваз белән озатамы Сүз Галиҗәнапларын залга, әллә пышылдапмы — тамашачы сихерләнгән, тамашачы йотлыгып тыңлый. Сәхнәгә текәлгән карашларда бу очракта да тилмереп үтенү бар сыман: «Тагын, тагын, тагын да шундый сүзләреңне әйтә тор, күңелебезгә сеңдерә тор, берүк туктый күрмә, бу бәхеттән өзмә!»

Мондый чакта Туган тел илаһи кодрәт ала, үзенең йөрәкләр, иманнар хакиме икәнен тоя, һәр татарны үз кочагына алып өлгерә.

Бервакыт мин шундый сәер хәлгә тап булып тетрәндем — читтән кайткан, татар телен начар белсәм дә, югалмадым, дип кинәнгән милләттәшнең үксеп-үксеп елавын күрдем. Аның бер килүендә Айрат Арсланов тәлинкәсен әйләндереп утыра идем. Теге дә сәлам бирүдән гайре тел тибрәтмәде — бирелеп тыңлый башлады... Бераздан колагыма калтыранган сулышлы ыңгырашу, үксү ишетелде. Борылып карасам... Ни кылана бу сакаллы бәрәңге ап-аек килеш?! Кул аркалары белән күзләрен уып елый, үзе тәкрарлый: «Булмад-ды бәхет, брат, булмад-ды! Шушы телдә гөрләшеп, туган илкәйләрдә яшәп булмад-ды!.. Әнә нинди икән бит ул татар теле!..»

Әйе, әнә шундый ул туган тел! Айрат Арсланов кебекләр авызыннан яңгыраганда, күкрәгеңне генә түгел, рухи бөкрелегеңне дә турайта торган, горурландыра торган, бәгырьләреңне актарып елата да торган тел. Шартына китереп сөйләүчесе генә табылсын, бу тел кяферлек тутыгы белән капланган иманыңны да чистарта, сафландыра торган тел! Баксаң, сәгатьләр буе туган тел кадере турында вәгазь укулардан да өстенрәк икән мондый мизгелләр!.. Айрат Арсланов бүләк иткән мизгелләр.

Сәхнәләрдән һәм эфир аша матур итеп, саф һәм зәвыклы итеп сөйләүчеләрне «нәфис сүз остасы» дип зурларга күнеккәнбез. Шөкер, андыйлар безнең милләттә йөзләрчә, меңнәрчә. Ә инде шул асыл затлар кыясының иң югары ноктасындагы Айрат Гәрәй улы Арслановны туган телнең баш сакчысы, бераз шаяртып та әйтсәк, генеральный сакчысы дип бәялибез. Менә шуңа күрә дә аның тарафыннан әзерләнгән, алай гына да түгел, зур таләпчәнлек белән иҗат ителгән концерт программаларын радио, телевидение фондлары пәйгамбәрнең мирасын саклагандай сакларга тырышалар. Мондый иҗат җимешләре халкыбызны гасырлар буе куандырырга, сокландырырга тиеш әле. Алар — вакыт агышына буйсынмый торган, берчакта да искерми торган программалар — Кол Гали, Габдулла Тукай, Хәсән Туфан, Муса Җәлил, Гаяз Исхакый, Габделҗаббар Кандалый, Сибгат Хәким кебек әдип һәм шагыйрьләргә һәйкәл булырдай затлы һәм кыйммәтле тапшырулар.

*1998*

**ХАРРАС ӘЮП**

* * *

*Айрат Арслановка*

Юкка гына ук атыламыни? —
Тигәндер шул,
Илгә тигәндер...
Ил ярасы — ирләр йөрәгендә,
Аваз сала икән синнән бер:

Кычкырасың —
Йә ул шигырь була,
Йә күкләргә ашкан җыр була.
Гомерлек бер моңга әйләнергә
Яратыла икән ир бала.

Үзәк өзеп күтәрелә бит ул
Күкрәктән, йөрәк түреннән, —
Бәлки, күкләр газиз бәндәсенә
Эндәшәдер шулай, кем белгән?!

Савыгадыр аны тыңлаганнар,
Сабырлыклар җанга иңәдер.
...Заманнарның иң кирәкле сүзе
Ирләр йөрәгендә нигәдер...

**РАМИЛ ИСЛАМОВ**

## Ике районның улы —
## барыбызның горурлыгы

Тарихта олуг шәхесләрнең тәрҗемәи хәлләренә бәйле кайбер гыйбрәтле фактлар бар. Әйтик, антик юнан шагыйре Гомерның туган җире итеп исәпләнү шәрәфенә ия булу өчен Смирна, Хиос, Колофон, Саламин, Родос, Аргос, Афина шәһәрләренең үзара бәхәсләшүләре мәгълүм. Шәрыкнең мәшһүр классигы Фирдәүси фарсы телле байтак халыкларның уртак әдибе буларак та билгеле. Әгәр карашларыбызны үзебезнең тарафка юнәлтсәк, XIX йөз каләм иясе Мифтахетдин Акмулланы татарлар да, башкортлар да, казахлар да бердәй үз итәләр.

Әнә шундый мәртәбәгә лаек булган, киң катлау гавамның ихтирамын яулаган могтәбәр зыялы затлар хәзерге вакытта да безнең арабызда бар. Айрат Гәрәй улы Арсланов 1928 елның 10 апрелендә Башкортстанның Бүздәк районы Ахун авылында элемтә хезмәткәре гаиләсендә дөньяга килгән. Шул ук елда, ул вакытларда элемтә өлкәсендә җаваплы вазифа башкаручыларны эшләү урыннарыннан даими рәвештә күчереп тору тәртибе нигезендә, гаилә башлыгын Учалыга юллыйлар. Анда алты ел эшләгәннән соң, Гәрәй абзыйны Кырмыскалыга тәгаенлиләр. Ә инде 1935 елда ул Балтач районына билгеләнгәч, аның үзәге булган Иске Балтач авылына килеп төпләнәләр.

Берникадәр вакыт үзенең төп эшендә эшләгәч, аны Мәскәүгә кортчылык буенча курсларга җибәреп укытып кайтаралар, һәм ул районның җир эшләре бүлегендә әлеге тармакта белгеч буларак лаеклы ялга чыкканчы хезмәт куя. Боларга өстәп шуны да әйтеп үтү урынлы булыр: төрле җиләк-җимеш агачлары үстерү белән актив шөгыльләнүче Г.Арсланов тирә-якта мичуринчы сыйфатында да киң танылу ала.

Шул рәвешле Айрат Арслановның чын мәгънәсендә аңлы тормыш юлы бәрәкәтле Балтач җирендә башлана. Еллар үткәч, безнең якташыбыз үзенең бер интервьюсында бу хакта болай дип белдерә: «Минем балачагым, яшүсмер вакытым шунда үткәнгәме, шунда урта мәктәпне тәмамлагангамы, мин үземнең туган ягым дип Иске Балтачны атыйм. Балтачлылар да мине үз авылдашлары дип саныйлар, миңа хөрмәт күрсәтәләр, рәхмәт аларга!»

Балтач яклары турында сүз чыккач, әлеге шәхесне тәрбия кылган шул төбәк хакында бераз гына булса да әйтеп үтү лязим булыр. Барыннан да элек ул үзенең гүзәл табигате, күп кенә хариталарда күрсәтелгән тиз агышлы Танып һәм башка елгалары, әкияти күлләре-чишмәләре, сихри урманнары, хезмәт сөючән, кунакчыл һәм итагатьле халкы белән билгеле. Аның үткәндәге тарихы да бай. Мәсәлән, XVIII йөздә колониаль изүгә каршы крестьяннар күтәрелешенең төп идеологы булган Батырша (Баһадиршаһ Габдулла улы Галиев) чыгышы белән хәзерге Югары Карыш авылыныкы. Е.Пугачев җитәкчелегендәге 1773–1775 еллардагы кузгалышларның актив әйдаманнарыннан берсе — Салават Юлаев яулары шуннан үткән. Иҗтимагый-сәяси ул вакыйгалар документларда гына чагылыш табып калмаган, ә кайбер авыллар тирәсендәге топонимик атамаларда сакланып, хәтерне һәрдаим яңартып торалар.

Айрат башлангыч һәм урта белемне районда беренче булып 1935 елда ачылган унъеллык мәктәптә ала. Аны башлап хәреф танырга һәм укырга-язарга өйрәтүче укытучы Җәмилә апа Риянова була. Ул елларда мәктәптә тарихтан Закир Хәбиров (директор), физикадан Ибраһим Фәтхуллин (уку-укыту эшләре мөдире), Наҗия Ихсанова, биологиядән Павел Архипов (районда ул беренче булып Ленин ордены белән бүләкләнә), географиядән Айсылу Ибраһимова һәм бертуган Кочетковлар, рус теле һәм әдәбиятыннан

Елена Попова, математикадан Ислам Хәйдәров, Гали Гомәров, химиядән Фәрдәт Дәүләтшин, алман теленнән Олимпиада Васильевна, башлангыч хәрби күнекмәләрдән Муллаян Хисамов, Имамхәмәт Шәмсиев һәм башкалар укыта. Алар арасыннан З.Хәбиров, И.Хәйдәров, А.Иванов сугыш кырларында батырларча һәлак булалар. Ә М.Хисамов исә кайткач, фронтта алган авыр яраларыннан озакламый күзләрен мәңгегә йома...

Әлеге мөхтәрәм мөгаллимнәрне Айрат ага хәзер дә сагынып, тирән ихтирам белән искә ала, һәм андый чакларда аның күзләре дымланып китә.

Мәктәптә укыганда ул үзен тырыш укучыларның берсе итеп таныта. Туган телгә, татар әдәбиятына мәхәббәте дә нәкъ шунда башлана, күп язучылар һәм шагыйрьләрнең иҗатлары белән таныша. Буш вакытларын район китапханәсендә үткәрү Айратның иң яраткан шөгыле була. Ул, әле кечерәк сыйныфларда укыганда ук, мәктәптә район һәм республика күләмендә үткәрелә торган төрле мәдәни чараларда, үзешчән көчләрнең олимпиадаларында актив катнаша башлый. Ул елларда яратып укыла торган Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Гафури әсәрләрен сәхнәләрдән сәнгатьле итеп сөйли. 1938 елда районның «Генераль сызык өчен» дип исемләнгән газетасы үзенең унберенче апрель санында өченче сыйныф укучысы «иптәш Арслановның декламация сөйләүдә танылуы» хакында язып та чыга. Бу уңайдан алгарак китеп булса да әйтик: әлеге язма — киләчәктә зур исемнәргә ия булачак артистка матбугат битләрендә бирелгән иң беренче бәяләмә!

Тора-бара аны район радиоузелындагы студиягә шигъри әсәрләр укырга чакыра башлыйлар. Радиоузел димәктән, ул Уфа тапшыруларыннан тыш Казанны да трансляцияли торган була. Эфирда яңгыраган концертлар аша Айрат беренче тапкыр мәшһүр композиторлардан Салих Сәйдәшев, Мансур Мозаффаров, Җәүдәт Фәйзи, Заһид Хәбибуллин иҗатларын, Гөлсем Сөләйманова, Рәшит Ваһапов кебек билгеле җырчыларның, атаклы гармунчы Фәйзулла Туишев һ.б.ның чыгышларын ишетә. Язмыш аны киләчәктә сәнгатьнең ул корифейлары белән очраштырачак, якыннан таныштырачак һәм бергәләп эшләү насыйбы тиячәк...

Югары сыйныфларда укыганда Айрат районның мәдәният йорты каршында эшләп килә торган драма түгәрәгенә теләп йөри башлый. Әлеге өлкәдә шулай ук сәләтен таныткан егет тиздән спектакльләрдә төп рольләрне башкара.

Айрат Арслановның үсмерлек еллары, билгеле ки, Бөек Ватан сугышы чорына туры килә. Ул — әлеге афәтнең тылдагы барлык михнәтләрен үз күзләре белән күргән, үз җилкәсендә татыган кеше. Фронтка киткән ирләрне алыштырып, башка яшьтәшләре кебек үк, ул да җиң сызганып төрле эшләрдә эшли. Алай гына да түгел, резервтагылар исемлегенә кертелеп, күрше Аскын районындагы механизаторлар әзерли торган училище базасында оештырылган хәрби курслар үтә.

Тормышның биниһая авырлыкларына карамастан, ул 1945 елда Иске Балтач урта мәктәбен тәмамлый. Мәктәптән соң аның алдында кая барырга икән дигән сорау тормый. Егетнең максаты бер, һәм ул ап-ачык — үзеңне зур сәнгатькә багышларга!

Шул ук елның август ахырында Айрат Арсланов Казанга килә һәм Татар дәүләт театр училищесының актерлык бүлегенә, татар сәнгатен үстерү өлкәсендә күп көч куйган Сәет Булатов классына укырга керә. Анда ул сәхнә теленнән белемне Ф.Ф.Витт һәм Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшләүче актриса Л.Салиәскәровадан үзләштерә. Аның белән бергә хәзерге вакытта СССРның халык артисты Шәүкәт Биктимеров, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Госман Әхмәтҗанов һәм башкалар да укый.

Айрат Арсланов театр училищесында укыган елларында ук Татарстан радиосында диктор һәм нәфис сүз остасы буларак иҗади эшчәнлеген башлый. Әлеге уку йортын тәмамлаганнан соң, ул үзенең белемен тагын да арттыру, камилләштерү нияте белән Мәскәүдә Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтының (ГИТИС) актерлык бүлегендә укый. Анда профессорлар Н.С.Анисимова-Вульф, Я.М.Смоленский, С.А.Кочарян кебек танылган остазлардан дәресләр ала. Аннан кайткач, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли башлый.

Анда эшләү дәверендә А.Арсланов күп кенә кабатланмас сәхнә образлары тудыра. Әйтик, Т.Гыйзззәтнең «Шомлы көннәр»еннән — Мирвәли, Ф.Бурнашның «Таһир-Зөһрә»сеннән — Таһир, К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл»еннән — Булат, Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил«еннән — Алиш, М.Кәримнең «Кыз урлау»ыннан — Мөхәмммәтша, М.Әмирнең «Тормыш җыры»ннан — Басыйр, Э.Золяның «Рабурден варислары»нан — Доминик, Ш.Камалның «Карчыга»сыннан — Талипов, Р.Ишморатның «Серле моң»ыннан — Сәүбән, Х.Уразиков һәм Ш.Сарымсаковның «Сәүбәновлар»ыннан — Халявин һ.б. шундыйлардан.

1965 елдан Айрат Арсланов — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең әйдәп баручы артистларыннан берсе. Аның элеккеге СССР күләмендә кайсы шәһәр-авылларда чыгышлар ясаганлыгын билгеләүгә караганда, кайсысында булмаганлыгын исәпләп чыгаруы җиңелрәктер, мөгаен. Яшьтән үк бирелгән табигый тембрлы йомшак җылы тавышын Мәскәүнең, Санкт-Петербургның зур концерт залларында, хәтта ерак Суоми иленең башкаласы Хельсинки каласында да тыңлыйлар.

Мәзкүр филармониядә эшләгән елларында ул бик күп әдәби концерт программалары әзерли һәм башкара. Алар арасыннан, мәсәлән, «Каһарман шагыйрь Муса Җәлил», «Шагыйрь гомере» (Г.Тукай), «Татарс-

тан шагыйрьләре поэзиясе», «Шагыйрь Сибгат Хәким», «Туган җирем — Татарстан», «Россияннар» (Х.Туфан), «Барлык тавышка» (В.Маяковский әсәрләре буенча), «Сергей Есенин» һәм башкаларны әйтергә мөмкин.

Феноменаль хәтергә ия артистның репертуарында Г.Тукай, Һ.Такташ, М.Җәлил, Ф.Кәрим, Х.Туфан, С.Хәким һәм хәзерге башка күп авторларның әсәрләре белән бергә рус шагыйрьләреннән А.Пушкин, С.Есенин, В.Маяковский, К.Симонов шигырьләре дә зур урын алып тора. Күп милләт халыклары үзләренең классикларын Айрат Арсланов укуында тыңлыйлар.

Соңгы елларда турыдан-туры аның катнашлыгы белән оештырылган радиотапшырулардан Г.Исхакый һәм Г.Тукай әсәрләреннән «Милли фаҗига», С.Максудиның «Мәгыйшәт»е, «Идегәй» эпосы буенча композиция, Ә.Рәшитнең «Сөембикә», «Кол Шәриф», «Мөхәммәдьяр» поэмалары, шагыйрьләрдән Хәсән Туфан, Шәехзадә Бабич, Сәгыйть Рәмиевләргә багышланган зур тапшырулар, Татарстан Республикасы көне уңаеннан «Үз илем, үз республикам бар», җәлилчеләр турында «Татарлар елмаеп үлделәр» исемле композицияләр һәм башкалар бар.

Мәскәүнең «Мелодия» фирмасы аның укуында М.Җәлил, Г.Тукай, Һ.Такташ, Х.Туфан, С.Хәким әсәрләрен тәшкил иткән грампластинкалар яздырып чыгарды.

Айрат Арсланов — үзен кино сәнгатендә дә сынап караган артистларыбызның берсе. Мәсәлән, Горький киностудиясе тарафыннан төшерелгән «Евдокия»дә (1960), «Мосфильм» һәм «Азәрбайҗан-фильм» бергәлегендә иҗат ителгән «26 Баку комиссары»нда (1965) ул кабатланмас образлар иҗат итте.

Иҗади казанышлары өчен Айрат Арсланов Татарстанның (1974) һәм Россиянең (1981) халык артисты дигән мактаулы исемнәргә лаек булды. 1969 елда ул Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге белән бүләкләнде. 1971 елда актерга Хезмәт Кызыл Байрагы ордены бирелде. 1957 елда Бөтенроссия нәфис сүз осталары конкурсында катнашып, СССР Язучылар берлегенең поэзия буенча мәртәбәле бүләген алды. Октябрь инкыйлабының 40 еллыгына, А.С.Пушкинның тууына 175 ел тулуга багышланган бәйгеләрдә лауреат исемен яулады. Ул — Халыкара информатизация академиясенең шәрәфле әгъзасы.

Олуг шәхесләр, аеруча артистлар турында сүз барганда, гадәттә, аларның гаилә хәлләре белән дә кызыксыналар. Шөкер, Арслановлар ул яктан күпләргә үрнәк булып торалар. Айрат аганың җәмәгате Мәрьям апа барыбызга да шулай ук эфир аша күптәннән билгеле. Ул тумышы белән Кемерово өлкәсеннән. Алар икесе дә театр училищесында укыганда танышалар һәм 1951 елда гаилә коралар. Мәрьям апа 1949–1963 елларда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актриса булып эшли. Бер үк вакытта, читтән торып, ул чактагы Казан дәүләт педагогия институтының филология факультетын тәмамлый. 1953–1963 елларда Казанның 113 нче урта мәктәбендә балалар укыта. Ә инде 1963 елдан Татарстан дәүләт радиосында диктор булып эшли. Хезмәттәге уңышлары өчен аңа «Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре» дигән мактаулы исем бирелде. Озак еллар дәвамында ул «Тел күрке — сүз» тапшыруын алып баручыларның берсе булды. Аның ягымлы тавышын эфир аша хәзер дә ишетеп торабыз.

Әлеге күркәм гаилә ике галимә кыз тәрбияләп үстерделәр. Өлкәне — Гөлнар — Казан дәүләт университеты доценты, инглиз теле укытучысы. Ә Алсу исә фарсы теле һәм Иран тарихы белгече, Татарстан Фәннәр академиясенең Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтының өлкән гыйльми хезмәткәре.

Кабатланмас сүз остасы, чын мәгънәсендә тел сагында торучы Айрат ага Арслановка быел 75 яшь тулды. Барыбызны да сөендереп, ул әле һаман хәрәкәттә, эштә. Илебездә, республикабызда уздырыла торган бер генә мәдәни чара да, зур күләмдәме ул, кечкенәме, аның катнашыннан башка узмый. Радиодан даими рәвештә чыгышлар ясый, вакытлы матбугат битләрендә үзенең истәлекләре белән уртаклаша, сүз сәнгате турында әһәмиятле мәкаләләре дөнья күреп тора.

Мөхтәрәм юбилярыбыз киләчәккә күркәм планнар корып яши. Ике районның улы — барыбызның горурлыгы булган Айрат агага — сәгадәтле бу көннәрендә бары тик озын гомер, сәламәтлек, гаилә бәхете, иҗади уңышлар гына телибез!

*2003*

**РӘДИФ ГАТАШ**

## Олуг остаз, чын санигъ...

Айрат ага Арслановсыз безнең сәнгатьне яки татарның рухи, мәдәни тормышын — XX гасырның икенче яртысын күз алдына китереп була микән? Һич юктыр, һәм ул, бәхетебезгә, олуг Маэстро булып, яңа гасырга, яңа меңьеллыкка да күчеп, әле безнең арада яшәвен, тиңсез иҗаты белән сөендерүен дәвам итә. Олуг остаз, чын санигъ ул.

Замандашлары да кемнәр бит әле: Рөстәм Яхин, Азат Аббасов, Шәүкәт Биктимеров һәм Илһам Шакиров кебек корифейлар. Аларга Сәйдәшнең соңгы саубуллашу моңы һәм илаһи нуры белән балкыган өлкән агалары — гасыр башының алтын баганалары булган әдипләр, шагыйрьләр, сәхнә ветераннары фатихасы һәм бәхиллеге бирелгән. Мотлак, бу шулай. Айрат ага Арслановның да беренче зур кичәне алып баруы —

зур сәхнәгә чыгуы — әнә шул бөек зат — Сәйдәшнең юбилей тантанасында булуы (композитор яшь артисттан моны үзе үтенгән) — гаҗәеп матур символик мәгънәгә ия түгелмени? Һәм бу иҗат юлы — халык йөрәгенә барган юл да ул! Күп кичәләр, театрлар, радио, телевидение, Казан, Мәскәү заллары, Финляндия кебек чит илләр, халкыбыз яши торган һәр төбәк-тарафлар белән бәйле рәвештә олуг бер дәреслек — сәнгать китабы булып әверелде.

Сүз остасының — Татарстанның һәм Русиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге иясе Айрат Арслановның — үзе исән чагында ук халык күңелендә бер һәйкәл булып калкуы иде бу! Артистның 70 яшьлеге уңае белән басылып чыккан «Сүз тәме» китабында бу хакта шактый тәфсилле, тулы яктыртыла — бу юлларны язганда ул минем алдымда ята, һәм мин аны актаргалап алам. Олуг шагыйрьләр, әдипләр, җырчылар, сәхнә кешеләре, замандашлары, дуслары, яшьләр, шигырь сөючеләр язган мәкаләләр, шигырьләр, ихтирам, мәхәббәт сүзләре анда! Ә «Сүз тәме» ул халык тарафыннан расланган сөю сүзенә карата да урынлы! Ул мәңгелек Тукай теле, шигыре яңгырашында. Ул дәвам итә. Айрат Арсланов яшь вакытта, академтеатрда уйнаган чорында, Таһир ролендә уйнаганын бер күрер өчен генә кызлар театрга йөри торган була — бу турыда мәшһүр бер шагыйрәбез еш сөйләргә ярата. Ә без, аннан яшьрәк буын, егетләр, булачак шагыйрьләр, Айрат абыйны олуг шагыйрьләрнең юбилей кичәләрендә күрә идек. Г.Кутуйның 60 еллык кичәсендә «Сагыну» нәсерен укуы әле дә күз алдында тора, тавышы да колакта. Мәһабәт буй-сын, ирләрчә олпатлык, табигыйлек, тавышының гаҗәеп матур тембры, бәрхеттәй ягымлылыгы — бу инде без күрергә теләгән чын ир-ат, сәхнә күрке, халыкка үзенең зурлыгын, көчен, хәтта күркәмлеген, дәрәҗәсен күрсәтү өчен — димәк, бер рухи яңарыш өчен махсус җибәрелгән, тарихи зарурилыктан пәйда булган сүз пәйгамбәре иде.

Кайсы гына шагыйрьне яңгыратмады Айрат ага үзенең сүз тылсымында, нинди генә гарше күкләргә ашырмады ул шигъри сүзне! Пушкинны да укыды ул, Тукайны да, Такташ, Туфан, Җәлилне дә! Һәм бик күп конкурсларның лауреаты да булды — бусы да шигырь һәм сүз яңгырашы бәхете иде. Әйе, кайсыбызны гына яңгыратмады ул радио, телевидение аша, кемнәрне генә канатлы итмәде. «Айрат укыган шигырь шәп була инде ул», — дия торган иде Әмирхан ага Еники, без фәкыйрьләр турында олуг артист тапшыруын тыңлагач. Ә Сибгат ага Хәким? Ул һәрвакыт «бер горурлык хисе» белән яна иде шигырьләре яңгыраганда. Башкалар да шулай. Уфадан Нажар ага, Атнабайлар да якташлары өчен горурлык кичерәләр иде, һәм кабат-кабат әйтелергә, искә алынырга тиешле нәрсә: ул — шагыйрьләргә Айрат ага биргән сөйләү, сәхнәдә үзеңне тоту культурасы, шагыйрьлекне әдәп белән кушу тәрбиясе иде! Һәм безнең шагыйрьләр бу мәсьәләдә олуг остаздан күп нәрсәгә өйрәнделәр. Шундый артист янәшәсендә кемгә генә «уютно» булмасын?!

Шунысын да әйтергә кирәктер: сүз сәнгате, сәхнә таләбе олуг артист, нәфис сүз остасы өчен һичкайчан да кәсеп яки зәүкы өчен генә булмыйча, ул сәхнәне, микрофонны, экранны олуг максатка — халыкка хезмәткә багышлады. Шуңа да аны милләт хадимнәре, халык уллары зур бәяләде: «тел сакчысы», «тәрбияче», «рухыбызны саклаучы», «милли көч арысланы», «матурлык һәм мәһабәтлек илчесе», «шагыйрьләр дусты» һ.б. эпитетлар белән мактап, дөрес аңлап, аның эшчәнлеген Тукайлардан башланган зур юлга китереп ялгап, аңа зур функция йөкләделәр. Ә гасыр азагындагы яңарышта, милли күтәрелештә Маэстроның сүз көче тагын да калкурак, җетерәк күренде...

Айрат агада тагын бер сәләт — әдиплек таланты да булуы мәгълүм: соңгы елларда ул көндәлек матбугатта үзенең истәлекләре белән уртаклаша, иҗатташ дуслары, төрле һөнәр, сәнгать кешеләре турында яза — милләтебезнең көчен, мөмкинлекләрен барлап, аларга халыкның дикъкатен юнәлтә. Сүз тәменең язмада да матур чагылышы бу. Ә белеме, эрудициясе! Бик сирәк очрый торган феномен ул бу яктан: бай интереслар, эзләнүләр, сораулар, хәрәкәт һәм нәтиҗәләр синтезы кешесе ул!

Тагын бер кызыклы ягы: үзе катнашкан радиотапшыруларны (димәк, шагыйрь, әдипләр иҗаты турындагы язмалар) тасмага яздырып, аерым фонд булдырган ул. Радио хезмәткәрләре тиз генә «юып», «чистартып» бара — үз мисалымда да күргәнем булды — озак саклау мөмкинлекләре юк икән, имеш... Шуңа да күп шагыйрьләрнең, сәнгать кешеләренең кадере артачак тавышы Айрат ага коллекцияләрендә сакланачак дип беләм...

...Арсланнар да картая микән? Элек 75 яшьлек кеше — зур, бик озын гомер иясе, хәтта үлемсез булып күзаллана иде. Ә Айрат ага? Ул һаман әлеге Таһирдай гашыйклар, үзе кумир иткән шагыйрьләр, әдипләр, мәңгелек рух һәм моң ияләре, җыр, шигырь кешеләре яшендә! Бәлки мәңгелек яшьлек илендәдер ул: сәнгать, илаһи сүз, шигырьнең картлыгы буламыни?! Һич юк. Сез безнең өчен гел яшь остаз, һаман шагыйрьләрнең үрнәк дусты булып каласыз, Айрат ага!

*2003*

## МӨДӘРРИС ӘГЪЛӘМОВ

### Җырлар калка

*Айрат Арслановка*

Кайсы буын килгән бу якларга,
Кайсы нәсел,
Кайсы бабасы?
Беркем белми моны, халык моңы
Ишетелгәч тынып каласың.

Үзәннәрдән күтәрелгән җырлар,
Таулар эргәсенә кагылып,
Юнәлешен үзгәртә дә оча,
Оча Казан ягын сагынып.

Һәрбер ташка монда җыр сыенган,
Җыр сыенган һәрбер куакка...
Кичләрендә чыксаң, юлдай озын
Халык моңы керә колакка.

Ул моңнарны читкә җибәрмичә
Саклаганмы Урал таулары?
Таулар түгел, халкым шундый минем,
Тик моңнардан тора бар җаны.

Аларның бит ерак бабаларын
Патша монда сөреп җибәргән...
Җирдән сөргән,
Җырдан сөрәлмәгән,
Җырлар калка, калка тирәннән.
*1967*

**РОБЕРТ ӘХМӘТҖАН**

## Затлы сүз иясе

Үз гомеремдә иң беренчеләрдән булып кайсы нәфис сүз остасын тыңлаганымны хәтерләмим. Күп тыңланган инде, төрлесеннән. Инде күп авазлар җәйге күк күкрәведәй офыкларга китеп, ераклашып, тоныкланып бара...

Әмма шулай да балачакта беренче тыңланган шигъри сүзләр колакта чыңлап тора әле:

Җиктереп пар ат, Казанга
Туп-туры киттем карап;
Чаптыра атларны кучер,
Суккалап та тарткалап...

Авазларының «рып-тырып-рып...» булып кабатланып килүе белән үк пар атның тырпылдап чабуын, тояк тавышларының дөпелдәвен төсмерләгән әлеге образлы сурәт, бөек Тукайның шагыйранә осталыгы бүген дә сокландыра мине! Соңыннан, студент булып киткәч, бераз гына мәгърифәт суын эчкәч, шагыйрьнең ошбу сурәт тылсымының сингармонизм ысулы икәнлеген дә белдек, шөкер. Ә бу ысул дигәне шигырьдә могҗиза тудыруга сәләтле икән ләбаса!

Шулай да кем укыды икән ул чакта? Фәйзи Йосыповмы, Әзәл Яһүдинме? Әллә соңыннан үзе белән очрашып сөйләшү бәхетенә ирешкән талантлы өлкән артист Хәким ага Сәлимҗановмы? Хәер, кем генә булмасын, нәфис сүз сәнгатенә ихтирамым әнә шул көннән бермә-бер артты миндә! Соңрак рус сәнгатькәрләреннән Качалов, Яхонтов, Журавлев кебек шигъри сүз осталарының иҗатына сокланганым булды. Арада Качаловның В.Маяковскийның «Товарищу Нетте, пароходу и человеку» дигән әсәрен укуы хәтергә уелып калган. Бу шигырендә «батум» сүзендә ике торбалы пароход авазын ишеттереп укыды актер!..

Ә инде соңыннан, Казанга килеп, студент булып, юктан да канатланып йөргән елларда, безнең шигъри күктә яңа йолдыз — Айрат Арсланов дигән йолдыз яктыра башлады. Тора-бара, ниһаять, ул нәфис сүз сәнгате осталыгына ирешүдә үзенә бер эталон булып китте. Минем иҗатта куанычлы бер вакыйга шул: Айрат ага 1962 елның 12 апрелендә Кешенең галәмгә тәүге очышына багышланган, ул чакта мәгълүм резонанс тудырган «Йолдызстан» дигән поэманы Мәскәү курантлары чыңы белән бизәп, радио өчен магнитофон тасмасына яздырды. (Хәзер ул тарихи тасма фондта саклана микән, белмим?) Аннан соң инде аз дигәндә дә ярты гасырга якын вакыт узган! Инде өр-яңа гасырда яшәп ятуыбыз. Иҗтимагый тормышта да, ил-көн яшәешендә дә, сәясәттә дә, мәдәният өлкәсендә дә зур үзгәрешләр барлыкка килде, тормыш сәхнәсе әйләнеп, яңа заманның «декорация»се алышынды, гаять каршылыклы, хәтта низаглы атмосфераның тыгыз кат-

ламнарына килеп кердек. Әмма шундый катмарлы, скандаллы чорда да шигърият, нәфис сүз сәнгате, ташны тишеп чыккан яшел кыяк сыман, кояшка тартыла, халыкның рухи тормышын бизәп яши бирә, шөкер. Осталар, шигъри сүзне кадерләүчеләр арасында көтеп алынганы һәрчак Айрат Арсланның ягымлы таныш тавышы булыр!

Шунлыктан барлык шагыйрьләрнең дә үз әсәрләрен аның укуында ишетергә теләүләре гаҗәп түгел. Әлеге остазның укылышында күпме шагыйрьләрнең әсәрләре, тылсымлы йөрәк тембрына ятып, үзенә бер җәүһәр булып яңгырадылар, радио фондында үзләренең лаеклы урыннарын алдылар. Айрат Арслан дигән останы татар радиосыннан, шулай ук аның телевидениесе тарихыннан аерып алу һич мөмкин түгелдер! Алар үзара бер ансамбльне тәшкил итәләр дисәм, укучым гаҗәпләнмәстер дип ышанам. Юк, мин бу хәлне артистның тавышына ияләшү дип кенә аңлата алмыйм. Аның сере һаман шул ук бер сәбәпкә — Маэстроның сүз тылсымына кайтып кала. Магиясенә дияргә дә мөмкин.

Татар әдәбиятын, аеруча «көйле сүз» булган шигъриятен пропагандалауда, турыдан-туры аның укучысының йөрәгенә «илтеп салуында» Айрат Арсланның хезмәтләре бәяләп бетергесез. Кайсы мәдәният сараеның заллары тамашачы белән шыгрым тулы — шунда сәхнәгә Арсланның чыгуын көтәләр! Күпме аншлаглы, алкышлы тамаша залларын күрмәгән дә кайсы гына эфирда тибрәлмәгән, нинди экраннарда чагылмаган аның мөлаем йөзе, төз сыны, ак кершәндәй якаларындагы кара күбәләге?! Аның гастрольләре географиясен мәйданга җәеп салып карарлык! Авыллар, калалар, вокзаллар, разъездлар, илләр, кыйтгалар билгеләнгән анда! Үтелгән юллар... Анда дүрт фасылның яңгыры, кары, җилләре...

Иҗатына гаять җаваплы карау, сайлаган теге яки бу әсәрне кайта-кайта эшләү, иҗат газапларын кичереп тә, соңыннан ирешелгәннәрдән канәгатьсез калу — сәнгать остасының остаханәсе әнә шундый көндәлек мәшәкатьләрдән гыйбарәт. Айрат ага, бәхетенә, үз гомерендә нәфис Сүз Остасы гына түгел, Сүз Остазы булуга ирешкән нәфис зат! Шөкер, миңа да үз гомеремдә, Опера театрында әдәби бүлек мөдире булып эшләү дәверендә дә, радио-телевидение дулкыннарыннан да төрле сүз осталарының шигъри авазларын ишетергә туры килде. Үзешчәннәр дә укый, профессионаллар да. Шуларның барын да тыңлап караганнан соң: «Болай гына шагыйрьләр дә укый алырлар иде, мөгаен», — дигән чаклар да булды. Әйе, укыйлар ул шигырьне, һәркем үзенчә укый, үз тавышы белән, әмма аларның нәрсәседер җитми, тозымы дигәндәй!.. Шундук аңлашыла: аның тавышы, тылсымы юксындыра, бәрхет тембры җитми икән ләбаса! Бәрхет баритон тембр ул, иркә, нәфис җәнлек сыман гел иркәләүне сорый кебек, нәзакәтле, нәзберек камертон кебектер...

Әлеге тавышны тыңлап, аның күңел дулкыннарында тирбәлеп, шигъри тугайларын, үзәннәрен гизеп ләззәтләнгәч, күңелдә шундый тойгы кала:

— Әле ярый шигъриятне прозадан аерган, поэзиянең кыйммәтен күтәргән, Шагыйрьнең җан аһәңен саклаган үлчәм бар: ул — Шигырь актеры берәмлеге! Бу өлкәдә беренче булып элек тә, бүген дә Арслан кала, шөкер!

— Әле ярый шигъриятне укучы күңеленә ирештерүдә үзенең профессионаллары, махсус осталары бар. Аларның рәте башында бүген дә Айрат Арсланның торуы хак.

— Шигъри сүзне тавыш куәте белән, көчәнеп түгел, ә йөрәгең белән, аны акварельгә тиң ягымлы хиссиятле төсмерләргә, нюансларга салып, пластик тембр белән, Илаһи сүзгә сәҗдә кылып уку сораладыр. Үземчә мин Останың осталык серен шулай фаразлыйм.

Драматик актерлар, һичшиксез, үз рольләрендә талантлы булырга мөмкин. Ә менә шигъри сүз күпләрнең амплуасы түгел. Моны мин яңалык дияргә җыенмыйм. Артист халкы моны үзе дә яхшы аңлый, әлбәттә.

Айрат Арслан, үзенең сәнгатьтәге төп вазифасын югары тоткан хәлдә, язучы белән укучы, шагыйрь белән тамашачы арасында инде ярты гасыр үзенә бер вәкаләтле илче ролен башкарып килә. Милләтнең рухын сафландыра, аның телен саклап калуда үзенең көч-гайрәтен кызганмыйча хезмәт итә. Татарның милли дулкынында аның үз дулкыны, үз мәктәбе бар!

Айрат Арслан татар сәнгате дөньясында бердәнбер!

*2003*

**МИРКАСЫЙМ ГОСМАНОВ**

## Камиллекнең көче

Артистны һәм гомумән сәнгать әһелен чын-чынлап аңлар һәм бәяләр өчен аның эшчәнлеген бераз ераккарак китеп карарга кирәктер. Әлбәттә, аның сәнгатьтә тоткан урынын, дәрәҗәсен, киң танылуын истән чыгармаган хәлдә. Чөнки күренеш-вакыйгалар, шәхесләр ерактан әйбәтрәк күренә. Миңа шундый «алым» мөхтәрәм артистларыбызның берсе — нәфис сүз остасы Айрат ага Арсланов иҗатының әһәмиятен, бәясен тулырак аңларга һәм үземчә бәяләргә ярдәм итте.

1995 елның җәендә миңа ике атна чамасы Финляндиядә булып кайтырга туры килгән иде. Андагы татар җәмәгатьчелегенең «җәйге мәктәпләре»ндә тарихыбыз буенча лекцияләр укып, семинарлар уздырыр өчен чакырылган идем. Әлбәттә, бераз гына буш вакыт булуга, форсаттан файдаланып дигәндәй, үз белгечлегем буенча да эшләргә омтылдым. Ягъни хәзер бездә «фин татарлары» дип атала торган, совет чоры матбугатында гел «ак эмигрантлар» сыйфатында тасвирланган кавемнең тарихы буенча мәгълүматлар җыярга тырыштым...

Чынлыкта Финляндия татарларының сәяси эмиграциягә бернинди мөнәсәбәте юк. Алар фин җирләренә XX гасыр башында ук барып урнашканнар (нигездә, Нижгар-Сергач ягы авылларыннан чыккан бәхет эзләүчеләр). Әле Финляндия «бүленмәс» Русия империясенең «аерылгысыз» өлеше — бер губернасы гына булган чакта ук. Әмма революциядән соң Финляндия мөстәкыйль дәүләт булып бүленеп чыккач, алар шул рәвешчә «чит ил кешеләре» булып калалар.

СССР чорында чит илләрдәге милләттәшләребезгә, мәгълүм ки, рәсми мөнәсәбәт бөтенләй тискәре иде. Шуңа күрә алар белән ирекле аралашу мөмкинлеге бөтенләй юк иде. Үзләренең тарихи ватаннарыннан аерылган, шул рәвешчә «ак эмигрант» халәтенә төшерелеп, рухи-мәдәни яктан мохтаҗлыкка тарыган кавемгә төрекләр ярдәм кулы сузды: дәреслекләр, укытучылар җибәрде. Нәтиҗәдә аларда «без төрекләр» дигән берьяклы милли-идеологик юнәлеш тарафдарлары көчәя, хәтта татарлыкка каршы көрәш башлана. «Татарчылар» бөтенләй җиңелү халәтенә төшә яза...

Нибары 60 нчы еллар уртасында гына Хельсинкида яшәүче милләттәшебез галим һәм җәмәгать эшлеклесе Үмәр Даһер — Гомәр Таһирның тырышлыгы нәтиҗәсендә совет хөкүмәте кайбер татарларны Финляндиягә махсус җибәрә башлый. С.Батыевның тәкъдиме белән шул чактагы Үзәк Комитет секретарьларының берсе булган Үзбәк Мөхетдиневнең яклавы буенча Хельсинкига барып чыккан беренче «Казан илчесе» Хәмит Сәйфуллин дигән кеше була. Моннан соң галимнәрдән Мөхәммәт Гайнуллин, Хатип Госман һәм Резеда Ганиевалар сәфәрдә булып кайта. Аннары 1968 елда бер төркем артистларыбыз...

Композитор Рөстәм Яхин, артистлардан Венера Шәрипова, Айрат Арсланов, Илһам Шакиров, Марат Әхмәтов һәм Марс Макаровлардан торган төркемне башта вокзалда бары Гомәр Таһир гаиләсе генә каршы ала. Башка кызыксынучы булмаган шикелле. Әмма беренче концерттан соң мөнәсәбәт бөтенләй үзгәрә. Артистларга карата гына түгел, бәлки милли аң, мәдәни кыйбла өлкәсендә дә үзенчәлекле рухи түнкәреш — революцион борылыш барлыкка килә...

Илһамның илаһи көчкә ия милли моңын, бигрәк тә искитәрлек табигый киң колачлы һәм тетрәндергеч дәрәҗәдә тирән хисле «Кара урман» җырын тыңлау юксыну, сагыш һәм рәнҗүләр нәтиҗәсендә таш булып каткан күңелләрне эретә, бәгырьләргә үтеп керә. Айрат аганың үзенә бер аерым кодрәткә ия тавышы белән ташка уелган төсле өзеп-өзеп ана телендә яңгыраган «Туган тел» шигыре тыңлаучыларның күңелендә элек сүнә барган (һәр ике яктан да сүндерелеп барган) хис-тойгыларны тергезеп җибәрәләр. Яңадан тарихи ватан, ата-бабадан мирас калган газиз туган тел хисләре дөрләп кабына. Егерме-утыз минутка дип танышыр өчен генә оештырылган беренче очрашу ярты төнгә кадәр сузыла.

Гармун моңы, назлы скрипка кылларының серле өннәре, илаһи көчкә ия тавыш, күңелләрдә, аңнарда уелып-уелып кала торган туган тел — «әнкәм-әткәм теле»нең ана сөте кебек тәмле, газиз сүзләре!..

Бер якта шулар.

Икенче якта исә сагыш, юксыну, өметсезлек нәтиҗәсендә таш булып каткан күңелләрнең эрүе — кайнар яшь, ихлас иңрәү авазы... Бигрәк тә олы яшьтәге агайлар, ак чәчле карчыклар үзләрен үзләре белешмичә үксеп елыйлар. Аларга карап яшьрәкләрнең күзләре дә дымлана...

...Миңа өч-дүрт мәртәбә әңгәмәдәшләремнән шундый сүзләрне ишетергә туры килде:

— Бездә элек татарны аерым бер халык түгел, ә зур төрек милләтенең бер ярчыгы гына дип исәпләүчеләр көчәйгән иде. Күпчелегебез моңа ышана башлаган иде. 1968 елны килгән артистлар безне башкача җилкендерделәр! Илһам Шакировның җыры белән Айрат Арсланның сүзе бигрәк тә... Ана телебезнең шулкадәр матур икәнлегенә ышандык...

Олы яшьләрдәге бер агай, әлеге фикерне икенче яктан куәтләп, болайрак әйтте:

— Мин иң актив төрекчеләрдән идем. Большевиклар тырнагына эләкмәс өчен Төркиягә сыенуны дөресрәк саный идем. Әмма Казан артистлары бөтен уй-хыялларыбызны үзгәртте. Безне җыр-моң белән җиңделәр. Без җиңелдек...

Әйе, 1968 елны артистларыбыз салган юллар буенча Финляндиягә аннан соң да сәнгать әһелләребез, галимнәребез кат-кат барды. Моннан соң Казан кунакларын вокзалда төркем-төркем булып киң җәмәгатьчелек каршы ала. Моннан соң «без фәлән, сез төгән» дип бүлгәләүчеләр кимегәннән-кими бара. Тагын бераздан Хельсинки, Тампере шәһәрләреннән дә Казанга, Нижгарга милләттәшләребез кунакка кайта башлыйлар.

Тарихи гаделлек менә шулай үз урынын ала.

Бу фактлар, минемчә, күп нәрсәләр хакында сөйләсә кирәк. Беренчедән, сәнгать дигән хикмәтнең көче хакында. Икенчедән, шул сәнгать белән коралланган талант ияләренең тәэсир көчен, кодрәтен күрсәтәләр. Өченчедән... Хәер, артык санап тормасаң да ярар...

Татар халкының моңын югары сәнгать дәрәҗәсенә күтәргән җырчыбыздан, туган телебезне эстетик зәвык белән яңгыраткан нәфис сүз остасыннан Хельсинкидагы финнарның сокланулары да мәгълүм нәрсә. Артистларыбызны мәшһүр президент Урхо Кекконен кабул итә...

Хельсинкидагы күпсанлы әңгәмәләр вакытында җәмәгатьчелекнең бөек артистларыбыз хакында сокланып, вакытның тиз узуы өчен беркадәр моңаеп, беренче очрашуларны сагына-сагына хатирәләргә бирелүен кат-кат күзәтергә, ишетергә туры килде миңа. Һәм моңа артык гаҗәпләнергә дә урын юк кебек. Чөнки Илһам Шакиров сәнгатеннән бүтән җырчыларның берсендә дә кабатланмый торган затлы, илаһи моң агылып тора. Ә Айрат ага Арсланов башкаруындагы шигырьләребездә (Габдулла Тукай, Муса Җәлил, Хәсән Туфан шигырьләрендә бигрәк тә!) нәфис сүз сәнгатенең мөмкин булган бөтен камиллеге, бөтен көче гәүдәләнә.

Ләкин төптәнрәк уйласаң, гаҗәпләнерлек нәрсәләр дә бар монда. Тоталитар система хөкем сөргән чорда әдәбиятыбыз төссезләнеп, милли матбугатыбыз тешсезләнгән, киң таралмаган татар мәктәпләре ябылып, китаплар чыгу да саега башлаган иде. Нәтиҗәдә милли аңыбыз, рухи бердәмлегебез тамырларына балта чабылган иде. Менә шул авыр шартларда СССР буйлап сибелгән халкыбызда бердәмлек хисен саклауга хезмәт иткән төп, хәтта бердәнбер дип әйтерлек чарабыз сәхнә сәнгате — театр һәм эстрадабыз булмадымы соң?!

Ул елларда сәхнә-эстрада артистларының ерак өлкә-республикалардагы чыгышларыннан тыш ярым караңгы авылларыбызда кабызган «клуб утлары»ның әһәмиятен дә онытмыйк...

Театр һәм сәхнә сәнгатендә осталык, иҗади камиллек дигән «нәрсәләр»нең рәсми цензурага әллә ни буйсынмый торган сыйфатын, көчен дә истән чыгармыйк.

Әйе, XX гасырның уртасы һәм икенче яртысында, иҗтимагый хәятыбыз тирән кризиска тарып, халкыбыз рухи таркаулыкка дучар ителгән чакта, аның бердәмлеге, туган теле һәм киләчәге өчен көрәшүчеләр сафында иң алдан сәхнә әһелләребез барды.

Айрат ага Арсланов шул фидакарь, ил кайгысын иңенә күтәргән ир-егетләребезнең берсе булып кала алды һәм калачак.

*1998*

**ГАМИЛ АФЗАЛ**

*Халык артисты Айрат Арсланга*

Сүз әйтергә тәвәккәллек кирәк,
Сүз йөрәккә ялкын үткәрә,
Сүз киптерә төп башына терәп,
Сүз меңнәрне яуга күтәрә.

Сүз кешене әйдәп алдан йөри,
Сызгандыра салмак беләкне,
Сүз күңелдә очкын булып көйри,
Сүз арыслан итә йөрәкне.

Сүз уйларны кайрый кайрак кебек,
Сүз сафларны ипли корычтай,
Сүз көрәшкә чыга байрак кебек,
Сүз дошманны кисә кылычтай.

*1986*

**НУРМӨХӘММӘТ ХИСАМОВ**

## Халыкның ул үз сынына охшаган

Һәркайсыбызның альбомында төрле елларда һәм төрле фотограф төшергән рәсемнәр сакланадыр. Шулар арасында безгә аеруча ошаганнары, якынраклары бар. Без аларны үз йөзебезнең чын чагылышы буларак кадерлибез. Хәлбуки алар — профессиональ фотограф төшергән, ретушьлаган рәсемнәр.

Әмма безнең шуларда үзебезнең дөресрәк, асылрак сурәтебезне күрүебез һич тә субъектив хаталану түгел. Чөнки магний яктысы кешене чынлыктагыга караганда картайта төшеп, күренер-күренмәс җыерчык сызыкларын көчәйтеп, чекерәйтеп чыгаручан. Ә оста профессионал әнә шушы кәеф бозучан акцентларны йомшартып, кешенең үзенә дә, читләргә дә ягымлы булган төзек чыраен, мөлаем төсмерләрен терки белә.

Ни өчен соң әле мин гүзәл артистыбыз Айрат Арсланов турындагы уйлануларны фотограф һәм ул ясаган сурәт хакындагы хөкемнәрдән башлыйсы иттем? Бу очракта минем фикерләрем даһи фотограф, дөресрәге, даһи рәссамга — табигатькә юнәлдерелгән. Ул, әлеге сәхнә каһарманын иҗат иткәндә, татар халкының үз-үзе һәм читләр каршында асыл сыйфатларын тулы гәүдәләндергән, сокланырлык мөләемәтен чагылдырган сурәтен иҗат итәргә карар кылган, һәм ул сурәт Айрат Арсланов рәвешендә каршыбызга баскан.

Татар тамашачысы яктыртылган нурлы сәхнәдә, көзгедәге кебек, үз сынын, үз сурәтен күрә. Экранда, илдәге һәм дөньядагы бихисап сәхнәләрдә татар халкы үзенең җисмани йөзен, рухани сурәтен күргәндәй була, күңеленә горурлык тула, сөенеч иңә, шушы сынын барлык халыкларга, бар дөньяга күрсәтәсе килә. Күрсәтә дә, күрәләр дә. Зифа буй-сын, чибәр, чибәр генә түгел, гүзәл йөз, сөрмәле керфекләр күләгәсенә төренгән нурлы зур кара күзләр, акчарлак канатыдай ике якка гайрәтле ыргылган кашлар, вәкарьле, салмак хәрәкәт һәм килешле ымнар, үзенең олы вазифасын тирән төшенү һәм дәрәҗәсен белү, шул ук вакытта гаҗәеп табигыйлек һәм тыйнаклык, хәтта беркадәр оялчанлык та...

Менә шушы сурәт күкрәктән чыккан тирән һәм кабатланмас тембрлы тавышы белән Тукайның әле драматизм тулы шагыйрь язмышына кагылышлы, әле туган җир табигатенә хушланган, якты аһәңле, әле татар тормышының мәзәкле якларына елмайган шаян шигырьләре, әле Туфанның туган тел һәм милләт язмышы өчен әрнегән, милли ваемсызлыкка нәфрәтләнгән һәм бөекдержавачыл тәкәбберлекне каһәрләгән кырыс лирикасы, әле Сибгат Хәкимнең милли горурлык һәм халык гаме белән сугарылган камил шигырьләре, әле Гадел Кутуйның кайтып илен күрү өчен җан аткан нәсерләре, әле Шәүкәт Галиевнең кайбер егетләр холкын пародияләгән җылы юморы аша татар тамашачысы үз халкының рухани бөеклеген, яшәүгә булган тыелгысыз ихтыярын һәм ихтирамга, тигезлеккә, ireккә хокукын төшенеп, кичереп утыра. Үз-үзен танып белә.

Табигать тә, иҗтимагый шартлар да әле күздән кичергән сыйфатларга ия мәгълүм шәхесләрне нәкъ үзенең кирәк вакытында, кирәк урынында мәйданга чыгара. Айрат Арслановның андый тарихи үткен ихтыяҗга туры килүе нәрсәдә чагыла соң? Ил тормышында милләтләрнең язмышы хәтәр өметсезлек томаны баскан офыкка якынлашып килгән чорда иҗат итте ул. Тукайның халыктагы таза иманны гәүдәләндергән, Туфанның сугышчан гайрәт тулы шигырьләре белән тамашачыны ул татар халкындагы тарихи җегәрнең төкәнмәслегенә ышандырды, бөек шагыйрь белән берлектә:

Туган телебез дигән бу алмаз
Чабаталы чорда югалмады,
Ильич яктысында югалмас! —

дип кистереп әйтте.

Айрат Арсланов репертуарында Советлар иле дигән зур дәүләтнең ватандарлык хисен чагылдырган көр аһәңле шигырьләр дә, Татарстан җирен данлаган патетик әсәрләр дә, әхлакка һәм тормышның төрле хәлләренә кагылышлы шаян парчалар да киң урын ала иде. Шунлыктан рәсми идеология һәм даирәләрдә ул абруй казанган сәнгатькәр дип беләм. Хәлбуки ул шушы абруй кысаларында рәхәт чигәргә яратучы иҗатчы булып калмады, аның репертуары ул кысаларны һәрчак кузгатып, этеп, киңәйтеп, ерып чыгучан булды. Аның Х.Туфан, С.Хәким, И.Юзеев, Р.Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Р.Гаташ һәм Зөлфәт әсәрләреннән гыйбарәт чыгышлары һәрвакыт милләт һәм ил гаме белән янудан торды. Шунлыктан тамашачы бу елларда күз алдыннан узган кискен борылышта мөхтәрәм сәнгатькәрнең иман хәзинәсендә бер йөктән бушанып, икенчесен төяү кебек үзгәрешләрне күрмәде. Аның иманы, күрәсең, һәрчак халкы иманына аваздаш булып килгән. Шунлыктан ул һәрвакыт күңелләргә газиз, сөйкемле, якын.

Безнең халык — үзенең табигате һәм тарихи тәҗрибәсе белән эстет кавем. Аның матурлыкка, нәфисләккә сизгерлеге үтә нечкә. Күркәмлекне ул күреп ала, аны бөтен барлыгы белән иңли һәм бәяли белә. Соңгы берничә дистә ел эчендә бездә Айрат дигән исемнең киң таралуын нәрсә белән аңлатып була? Бары сәхнә күрке булган әлеге сәнгатькәр затның тышкы һәм рухани күркәмлеге, талант абруе белән. Татар кешесе шул рәвешле үзенең улына якты, абруйлы язмыш, затлы рухият юрамакчы, һәркем үз баласын Айрат Арслановча күркәм сынлы итеп күрәсе, аңа аһәңле исеме белән эндәшәсе килә. Бу күренешнең нәкъ менә актерның иҗат гомеренә туры килүе бары шундый нәтиҗә ясау өчен нигез бирә.

Кояшлы алан кебек, прожекторлар яктысына чумган рампага, аякларына киң басып, мәһабәт җилкәсен киереп, карага һәм акка төренгән сыгылмалы сыны белән Айрат Арсланов килеп чыктымы — татар халкы тарих сәхнәсендә үз сынын күргәндәй була.

*1998*

**КЫЯМ МИҢЛЕБАЕВ**

## Сүз остасы

РСФСРның халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Айрат Арслановны кемнәр генә белми икән! Республикабызның төрле төбәкләрендә дә, күпмиллэтле илебезнең төрле почмакларында да әледән-әле концертлар бирә нәфис сүз остасы.

Айрат Арслановның тышкы матурлыгы эчке гүзәллек белән үрелеп яши: холкында аның һичбер дорфалык күрмәссең, ул гомумән кече күңелле, бүтәннәр белән аралашып яшәүчән. Тамашачылар белән дә бик рәхәтләнеп аралаша артистыбыз, сәнгать әһелләре, язучылар белән дә. Әңгәмә барышында ул аларның эчке дөньяларын да өйрәнә, сөйләү алымнарын да үзләштерә. Әйтик, үз вакытында ул олуг әдибебез Ә.Фәйзи белән, тора-бара талантлы шагыйрьләребез Х.Туфан, С.Хәкимнәр белән дуслашып-аралашып яши, алардан шигъриятнең серләрен сораша, Тукайның һәм Җәлилнең иҗатларын тагы да ныграк ачыклый, поэзиянең серләренә төшенә, һәр ишеткәнен, һәр укыганын үзенең профессиональ осталыгын камилләштерүгә юнәлдерә. Һәм әнә шул камиллекнең үрнәкләрен халык игътибарына тәкъдим итә. Бөек Тукайның 100 еллыгына телевидение өчен тулы метражлы ике тапшыру әзерли: аларның берсендә халык шагыйренең лирикасын чагылдырса, икенчесен сатирага багышлый. Габдулла Тукайның иҗатын тулырак күрсәтү нияте белән радио аша шигырьләрдән аерым, «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш» сатирик поэмасыннан аерым ике тапшыру әзерләсә, Ә.Фәйзинең «Тукай» романы буенча да тапшырулар циклы оештыра. Эфирда болар күркәм бер яңгыраш ала.

Халкыбызның горурлыгы булган шагыйрь Муса Җәлилнең 80 еллыгына багышлап телевидениедән хәйран зур тапшыру булды; анда сәнгатебез осталары — СССРның халык артисты композитор Рөстәм Яхин, нәфис сүз остасы Айрат Арсланов һәм РСФСРның атказанган артисты җырчы Эмиль Җәләлетдинов катнашты. Мондый зур әзерлекле тапшырулар, һичшиксез, культурабызның алтын фондын баеталар һәм киләчәк өчен саклананалар.

Айрат Арсланов моннан тыш Х.Туфанның иҗатын ныклап өйрәнеп кенә калмады, аның Г.Тукайга һәм М.Җәлилгә багышланган әсәрләреннән махсус тапшыру әзерләде.

Ә соң искиткеч матур, мәһабәт тавыш белән ике бөек шәхеснең — Тукайның һәм Җәлилнең иҗатын пропагандалау, әсәрләрен укып, грампластинкага яздыру үзе генә дә ни тора! Моны инде поэзиягә олы хөрмәт күрсәтү дип бәяләргә кирәк.

Талантлы әдип Мөхәммәт Мәһдиев әдәбият һәм әдәбият дәреслекләре үрнәгендә, зур талантлар киткәч, уртакул ыбыр-чыбыр килүенә күңеле әрнеп язган иде. Әйе, андый хәлләр әдәбият һәм сәнгать өлкәсендә әледән-әле кабатлана — вакуумны гадәттә халтура тутыра. Ә соң сәхнәнең кайчан бушап калганы бар? Анда очып менәргә атлыгып торучылар һәрчак табыла. Шуңа күрә дә шәкертләр булдырырга, яшь буынны тәрбияләргә, үзегезгә алмашны кайгыртырга кирәк. Милли әдәбиятның мәшһүр пропагандисты буларак танылгач, сез инде киләчәкне дә кайгыртырга тиешсез...

Ә менә әдәбият өлкәсендә үзен иркенрәк тоя артистыбыз: яшьрәк буын шагыйрьләрне дә читсенми, алар белән дустанә, аралашып яши. Моның мисалын без Май бәйрәме көннәренә багышланып, ике-өч атна узгач, яңадан кабатланган «Тургай җыры» исемле тапшыруда да күрдек.

Бу хәйран матур тапшыруда Айрат Арсланов, поэзиядәге өлкән буын вәкилләре белән генә чикләнмичә, бүгенге көндә актив иҗат итүче шагыйрьләрдән Р.Фәйзуллин, Зөлфәт, Р.Әхмәтҗанов һәм Ф.Сафиннарның язгы җанлануга, табигатьнең уянуына мәдхия җырлаган шигырьләрен дә укыды. Шунысы кызык: үзең укыган чагында бик үк сиземләп җиткермәгән нечкәлекләрне, шигъри бизәкләрне гүя артист нәкъ менә игътибар үзәгенә алган да шуларга басым ясыйдыр сыман. Бар бит шагыйрьләребездә гаҗәеп моңлы, искиткеч шигъри юллар, бар, һәм Айрат Арсланов укыганда аларның камиллегенә аеруча нык сокланасың.

Поэзияне күңеле белән тоя бу сүз остасы, үзе укырга алынган һәр шигырьнең рухына, авторның стиленә туры китереп, бу әсәрне иҗат иткәндәге халәтенә кереп, интонацияне кирәгенчә үзгәртә ала, укыган әйберенең мәгънәсенә бәйле рәвештә настроение бирә, җанландырып җибәрә. Югары культурага ия булган артистның текст укыган чагында эмоциягә бирелә белүе, хисләрне бай куллануы тыңлаучыларның күңелен тулысынча җәлеп итә.

*1987*

**ШАМИЛ МАННАПОВ**

## Мәкам

*Атаклы нәфис сүз тылсымчысы, сәхнәбез йолдызы Айрат абый Арслановка*

Чү! Тәүге кат кайчан ишеттем соң
Бу сәмави, моңлы мәкамне?
Әниемнең бишек җырыннанмы,
Догасыннан микән әткәмнең?
Шагыйрь гамен, туган халкым диеп
Януларын, көрәш җегәрен

Ачык тойдым,
Тыңлаганда Аның
Мәкам белән шигырь сөйләвен.

Тарих дәрьясының төпкеленнән
Күңелләргә кага һәр сүзе.
Бу хисләрне әллә Шагыйрь белән
Кичергәнме юкса ул үзе?
Кичергәндер...
Ул да, Йосыф кебек,
Зөләйхага гашыйк булгандыр.
Тукай белән, Җәлил белән бергә
Өзгәндер дә коллык богавын,
Давылларны ярып очкандыр Ул,
Ирек яулау өчен бүгенгә,
Көрәшләрдә шәһит булганнарны
Терелтергә безнең күңелдә,
Ирек яулау өчен бүгенгә!

Ходай аңа затлы мәкам биргән,
Ачкычларын сүзләр серенең.
Шул мәкамнең нуры-яктылыгы
Күрсәтә күк бөтен затлылыгын
Һәм җегәрен татар теленең.
*1997*

**АЙДАР ХӘЛИМ**

## «Тумыштан ук коеп куелган ул...»

«Тумыштан ук коеп куелган ул...»

Бу минем сүзләр түгел. Бу — мәрхүм классигыбыз Әмирхан ага Еники тарафыннан Айрат Арслан турында 1996 елда әйтелгән сүзләр.

«Коеп куйган...» «Бәрхеттән коелган...»

Татарстан китап нәшриятының 1998 елда «Сүз тәме» дигән бик мәгънәле исем белән Айрат Арслан иҗатына багышлап чыгарган җыентыгында Әмирхан ага аны «Һәрвакыт тансык» дип тә атый. Шунысы кызык: Гомәр Бәширов, Нурихан Фәттахлардан башлап Газинур Моратларга кадәр йөзгә якын кеше катнашкан, гаҗәеп зур зәвык, соклану, моң белән сугарылган бу китапта башка бер генә каләм иясе дә әлеге атаманы кабатламый. Тагын шунысы да кызык: Әмирхан аганың мәкаләсе «Сүз турында сүз» дип атала.

Бу фикерләрем әле үтеп барышлый гына. Иң мөһиме, минем Айрат Арслан турында язасым килә. Мактыйсым килми. Аны ачасым гына килә. Булдыра алырмынмы икән?

Җитмәсә, бүген әле алар икәү: «ов»ларны алып ташласак, Айрат Арслан һәм Мәрьям Арслан. Хәер, алар элек тә гомер-гомергә бергә иделәр, без аларны күрми генә идек. Элегрәк аларның берсен бишек күләгәсе каплаштырып куя иде. Бүген без аларны күрми булдыра алмыйбыз. Алар — бер бишектә уртак балалар үстереп, 40 елдан артык татар сүз сәнгатендә сүз бишеге тирбәтеп, анда башактай тос башлы шагыйрьләр вә әдипләрне дөньяга бар итеп, шуның белән генә дә татар иҗтимагый тормышына һәм фикер агышына искиткеч зур хезмәт керткән сәхнә вә эфир каһарманнары. Милләтнең, халык әйтмешли, «бергә ятып, бергә торган» ирле-хатынлы улы һәм кызы. Татарның Гөлнар һәм Алсу исемле ике галимәсен, фән магистрларын үстергән ата-анасы. Милләтнең ирле-хатынлы сәнгатькәрләре, димәк, иҗтимагый көрәшчеләре.

Бүген алар язмышында искиткеч зур вакыйга: Башкортстанның көмеш дулкынлы Танып буйларындагы Иске Балтач авылында укылган изге никахларыннан соң мәңге бергә дип җитәкләшеп китүләренә 50 ел тула.

Әйе, алтын туй! Бар милләт, бар дөнья алдындагы алтын туй! Әйе, бүген учка кысып кертсәң дә хисапка кермәгән 10 миллионлы бармаклар арасыннан сытылып чыккан күп миллионлы һәм «күпмилләтле» татар милләтендә менә шундыйрак вакыйга, туганнар. Бүген барлык төрки дөнья гына түгел, кеше телен һәм кошлар телен аңлаган барлык тере дөнья, гармонияләр дөньясы да котлый Мәрьям белән Айрат Арс-

ланны. Чөнки сәнгати сүз ул — эфир кошы. Эфир исә ул — Аллаһы Тәгаләнеке. Татар телендә яңгыраган җыр һәм нәфис сүз ул инде һавага очу белән барлык кешелек дөньясының гомуммирасына әверелә.

Гаиләнең, аның эчке тормышының үз законнары бар. Алар шәхеснең үзе кебек үк кабатланмас. Бу законнарның берсен мактап кына күтәреп, икенчеләрен хурлап кына түбәнәйтеп булмый. Шуңа күрә гади, көндәлек хәятта без кайчакта борынгы бабаларыбыз кебек «Тормыш булгач, төрле вакыт була инде» дип, үзебезне юатырга мәҗбүрбез. Әйе, тормыш булгач, үзебез әйтмешли, «мондый төрлелек» Мәрьям апа белән Айрат абый язмышында да булгандыр. Тормыш булгач, савыт-саба да шалтырамый тормагандыр. Сүз монда «очсыз пыялалар» турында бармый. Сүз бер милләтнең бу ике баласының тәңгәл килүе, танышуы, якынаюы һәм кавыша алуы турында бара. Алар — бер-берсен куышып һавага күтәрелгән диңгез альбатрослары кебек мәгъруур җаннар.

Мәрьям һәм Айрат Арсланнар — икесе бер рухи сәҗдәгә, икесе бер намус кәгъбәсенә табынган, ягъни икесе дә бер сәнгатькә хезмәт иткән сирәк затлар. Татарда зат, затсызлык дигән сүз бар. Мин әле шул «зат» дигән нәрсә хакында роман язып ятам. Минем Мәрьям һәм Айрат Арслан дигән кардәшләрем исә зат кына түгел, затлы пар. Бер сәҗдәгә табына торган затлы пар. Татарда мондый парлар чынлап та сирәк.

Үзегез уйлап карагыз: Себергә куылган татарлар гаиләсендә, кайдадыр Кимрау (Кемерово) өлкәсендә дөньяга килгән һәм, әйтергә кирәк, без уйлап өйрәнгән форматлардан чыгып фикерләгәндә, татар тел дөньясын үстерүдә турыдан-туры катнашу, дистә еллар буе аның штабында төп башкаручыларның берсе булып хезмәт итү түгел, татар телен белмәскә, телне белмәгәне өчен «макталырга», «акланырга», хәтта татарны «тырпит не могла» тиешле Мәрьям ханым... Ул очраклы рәвештә 40 нчы еллар уртасында Казанга килә, «очраклы» гына театр училищесына укырга керә... Уфа янындагы мишәр төбәге, Батырша ватанында туып үсеп, әле ул чактагы Сталин режимы шартларында милли кысылу, туган татар теле кысылуының нәрсә икәнен күз алдына да китерә алмаган гади, якты, таза, сукса тимер өзәрлек асаба татар егете булган Айрат та, Иске Балтач татар урта мәктәбен тәмамлап, «очраклы» гына шул ук Казан театр училищесына укырга керә... Алар икесе бергә «очраклы» гына шул уку йортын тәмамлыйлар. Айрат — атаклы Камал театрына, Мәрьям исә Татарстан радиосына юл ала... Очраклылык озакламый законлы никахка әйләнә. 1951 елда алар өйләнешәләр.

Берәү булса барыннан да канәгать булып, тынычланып калыр иде. Нигә борчылырга: эш урыннары бар һәм дә ки шактый абруйлы, белем дисәң, анысы җитәрлек кебек. Ә менә фатирлары гына юк юклыкка. Әмма яшь парга, күрәсең, беренче чиратта нәкъ шул белем җитми. Алар яшьлекләрендә, Әбүгалисина сыман, белем мәгарәләрен танып белергә булалар. Ары таба укуларын дәвам итеп, Мәрьям — Казан педагогия институтын, Айрат исә Мәскәүнең театр сәнгате институтын тәмамлый...

Менә шул заманнардан алып инде Мәрьям апа Татарстан радиосында диктор, Айрат абый исә Татарстан филармониясендә алып баручы артист булып эшли. Алар турында кайвакыт «лаеклы ялда» дип әйтеп җибәрергә яраталар. Дөрес түгел. Андыйлар ялга китми. Андый артистларны халык ялга җибәрми дә. Мәрьям апаның һәр якшәмбедә яңгыраган «Тел күрке — сүз» һәм кайбер башка тапшыруларын гына искә төшерегез. Аларны бит тыңлаучылар зар-интизар булып көтеп алалар!..

Айрат абый турында инде әйтеп тә торасы юк. Аның башкаруында яңгырамаган берәр күренекле шагыйребез, язучыбыз, публицистыбызның әсәрләре калды микән?! Ул радиодан, телевидениедән (элегрәк) укымый, ул күрми кала торган шигырь китаплары бар микән?! Ул, бары тик ул гына бит соңгы 40 елда татар шигъриятенең Кол Галидән Марсель Галигә кадәр җиткән исемлеген чын сүз сәнгате, шигырь уку сәнгатенә әйләндерә алды.

Мин Айрат Арслан язмышында, ихтимал, әлегә башкалар күрмәгән бер феноменаль билге дә күрәм кебек. Шуны менә хәзер башкалар белән дә уртаклашасым килә. Сез карагыз әле... Сез карагыз гына... Имештер ки, бер «караңгы» татар авылында туып, бер «караңгы» татар мәктәбен тәмамлап, бер «караңгы» татар сәхнәсендә авылдан авылга шигырь укыштырып (кемгә кирәк ул?!) йөргән мәхдүм... Һәм ошбу «караңгы» мәхдүм, мин сезгә әйтим, шулкадәр матур, чук гүзәл сынлы, килеш-килбәтле...

Моның сәбәбе нәрсәдә? Чыганаклар каян килә, җәмәгать? Каян, кайсы Парижлар, нинди Аурупа, Азиядән килә бу кадәр сайланган мәдәнилек? Үзебезнең өлешкә төшкән бу кадәр сирәк тылсымчының кадерен белеп бетердекме без? Хет кадерен белә башладыкмы?

Айрат Арсланның безнең милләткә генә түгел, күпмилләтле барлык дөнья сәнгатенә алып килгән алтын-көмеш ятышлары — алар бит аңардагы кешелек культурасының югары математикасын, әгәр шулай әйтергә яраса, матдәнең каршылык күрсәтү көчен мәңгелеккә җиңүен раслыйлар. «Караңгы» татар дөньясына бу кадәр илаһи байлык каян килгән?

Туган телдән. Туган җирдән. Туган якның саф суыннан, челтер чишмәләреннән. Әти-әнидән.

Әнә алсуланып янган офык. Моны кичке шәфәкъ диләр. Су буеннан шәфәкъ дәрьясына уралып икәү күтәрелә. Мәрьям һәм Айрат Арсланнар алар.

*2001*

**ЗИЛӘ СӨНГАТУЛЛИНА**

## Рухландырып,
## дәрт биреп торучы

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрының тамашачылардан башка бик күп дуслары бар. Төрле елларда театрның иҗат эшендә катнашкан артистлар, композиторлар, рәссамнар, шагыйрьләр... Шулар арасыннан мин театрыбыз эшендә кырык елдан артык актив катнашып килгән, тамашачыларның һәм артистларыбызның мәхәббәтен яулап алган халык артистыбыз Айрат Гәрәй улы Арслановны аерып күрсәтер идем.

Ул театрыбызның бихисап концертларында катнашкан, безнең Мәскәүдә һәм башка шәһәрләрдә үткәрелгән гастрольләребездә булган, безнең бик күп премьераларыбызны карап, артистларыбызны рухландырып, дәрт биреп торучы өлкән дустыбыз, чын сәнгать кешесе дип әйтәсем килә минем.

Инде күп еллар миңа да танылган сүз остасы белән күп сәхнәләрдә бергә эшләргә туры килде. Мин аның талантын, эш сөючәнлеген, коллегаларына булган дустанә мөгамәләсен күреп сокланам. Аның кебек классик манерада укучы, сәхнәдә үзен горур тотучы, укыла торган әсәрләрен зур осталык белән башкаручы зыялы сәхнә осталарыбыз күп түгел бит.

Ф.И.Шаляпин исемендәге халыкара опера фестивальләренең беренче көннәреннән үк безнең күп спектакльләребездә булып, Шаляпин укуларында катнашып, фестивальгә килгән кунакларыбыз белән аралашып яшәүче, театрыбызның чын дусты ул Айрат Арслан. Олы сәнгатебезгә бирелгәнлеге белән безнең яшьләребезгә дә зур үрнәк ул. Мин аңа чын күңелемнән озын иҗат гомере телим.

*1997*

**ФОАТ ГАЛИМУЛЛИН**

## Шагыйрь түгел — шигырь

Узып бара торган бер дистә унъеллыкның безнең өчен кадерле булган шәхесләре, вакыйгалары бихисап. Шуларның берсе — Айрат Арсланов, аның тавышы. Тавыш дигәч, үзеннән-үзе аңга җырчы килә. Юк, Айрат Гәрәй улы Арсланов җырчы түгел (иманым камил, вокаль башкару юлы белән китсә дә, ул зур уңышка ирешкән булыр иде). Ул — сүз остасы. Үзенчәлекле бәрхет тавышы белән ярты гасыр буена ничә буын кешеләрен әсәрләндереп яшәүче гаять талантлы зат.

А.Арслановның балалык һәм яшьлек вакытында, ягъни утызынчы-кырыгынчы елларда, бу төбәкләрдә татар телен белем бирү һәм тәрбия өлкәсендә файдалануда кысу-бозуларга әллә ни юл куелмый. Ул чорда, А.Арсланов әйтүенә караганда, «...радио челтәре Башкортстан радиосы тапшырулары белән бергә Казан радиосы тапшыруларын да трансляцияли иде». Тел мохитенең ана телендә булуы яшь кешенең үз милләте, аның рухы, мәдәнияте белән горурланып үсүенә китерә, психикасының сәламәт булуын тәэмин итүче факторларның берсе булып әверелә. Яшь Айрат та җирле радиотапшыруларда татар шагыйрьләре Г.Тукай, Һ.Такташ әсәрләрен укып катнаша. Телнең тәмен, аһәңен тоюга гамәли эшчәнлек нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Туган төбәге булган Башкортстанның Балтач районында ук әдәбиятыбызның гүзәл үрнәкләрен башкаларга җиткерү юлында ясалган беренче кыюсыз адымнар аның сәнгатьтәге олы юлының тәүге мизгелләре була.

Күңеле туган телебезгә, сүз сәнгатебезгә мәхәббәт белән тулы яшүсмернең кыйбласы ачыклана, ул — Казан, аның да театр мәктәбе. Унсигез яшьлек егет биредәге сәнгать мохитендә үзенең гомерлек иҗат юлын таба.

Яшь егетне профессиональ сәхнәгә җәлеп итүдә күренекле композитор Салих Сәйдәшевнең роле зур. 1951 елда үзенең 50 яшьлек юбилеена багышланган тантана-концертны алып барырга С.Сәйдәшев Айратка тәкъдим итә. Ул әле бүген дә шушы концертны, кино кадрларыдай, бөтен нечкәлекләре белән күз алдыннан үткәрә ала. Бигрәк тә С.Сәйдәшевнең — үтә тыйнак, ягымлы шәхеснең — халык алдында шактый уңайсызланып басып торуы, үзенә карата әйтелгән җылы сүзләрдән җайсызлык тоюы хәтерендә калган. Аның каравы әсәрләре башкарылганда аның йөзенең илһамланып, вакыт-вакыт җитдиләнеп китүе, оркестрның нәфис гармониягә ирешеп уйнавы өчен композитор-дирижерның җанын бирергә җитеп тәэсирләнеп җитәкчелек итүе күңелдә уелып калырдай мизгелләр булган икән.

Диктор авторлар әзерләгән тапшыруларны бар итә дә ала, юк итә дә ала. Соңгы чиктә барысы да аның осталыгына бәйләнгән. Көн саен көнгә берничә тапкыр эфирга чыгучы дикторны бер куркыныч сагалый, аның тыңлаучыны туйдыруы, ялыктыруы да мөмкин. Менә ни өчен төрлелеккә, җанлы сөйләмгә ирешү, укуыңны тыңлаучыны фикердәшең, хистәшең итеп тою иң дөрес юл булып чыга.

50 нче еллар урталарыннан ул Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында артист булып эшли. Иҗат кешесе өчен үзен төрле амплуаларда сынап карау бик кирәк. Театрның ул вакыттагы баш ре-

жиссеры Ш.Сарымсаков аңа театрга кучәргә тәкъдим иткәч, А.Арсланов та шулай уйлый һәм, әйтергә кирәк, ялгышмый. Төп театрыбыз тарихына ул үзе тудырган төрле-төрле бик тә үзенчәлекле рольләр тудыруы белән кереп калды.

Әле шушы көннәрдә күренекле артистыбыз Рауза Хәйретдинованың җитмеш еллык юбилее уңае белән ТДАТта күргәзмә оештырылды. Мәгълүм булганча, Рауза ханым бик күп еллар «Зәңгәр шәл» спектаклендә Мәйсәрә ролен оста итеп уйнап килде. Биредә аның төрле елларда Булат ролен башкарган М.Имашев, А.Аббасов һәм А.Арсланов белән төшкән рәсемнәре куелган. Мин шул рәсемнәр янына килгәндә, анда ике өлкән яшьтәге апа-әбиләр сөйләшеп торалар иде.

— Карале, бу бит Айрат Арслан! И ахирәт, «Зәңгәр шәл»гә шушы Айрат уенын карарга дип йөри идек, хәтерендәме?

— Кая инде исемдә булмасын, бигрәкләр дә матур уйный иде шул.

К.Станиславскийның шундый сүзләре бар: «Мөлаемлыгы — артистның ярты уңышы». Матур буйсын, чибәр йөз дигәндә Ходай Тәгалә безнең Айрат Арслановка берсен дә кызганмаган. Казанда телевидение студиясе ачылгач, диктор итеп иң әүвәл аны чакыралар. Монда эшләү өчен тирән һәм киң белем, ягымлы тавыш һәм әлеге дә баягы мөлаемлык — барысы бергә кирәк. Эшли А.Арсланов телевидение дикторы булып һәм тагын меңнәрчә-меңнәрчә тамашачыларның мәхәббәтен казана.

Табигый сыйфатларыңның булуы, әлбәттә, бик тә мөһим. Шулар өстенә А.Арсланов үтә дә тырыш, алга омтылыш белән яши торган кеше. Инде берәү булса, болай да уңышларга ирештем, дип, тыныч кына эшләвен белер иде. Әмма мондый гамьсезлек Айрат Гәрәй улына һич тә туры килми. Ул үз-үзеннән канәгать түгел. Шушы нәрсә аны туктаусыз эшләтә, камилләштерә һәм көннәрдән бер көнне Мәскәүнең театр сәнгате институтына алып килә. Биредә актерның үз эшчәнлегенең асылына карата караш офыклары тагын да киңәеп китә. Ниһаять, А.Арсланов үзенең төп урынын таба, ул — эстрада. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эшләү чоры аның иҗат биографиясенең иң югары ноктасы булып тора. Аның хәтерендә татар әдәбиятының гаҗәп бай хәзинәсе саклана. Анда шигъри һәм проза әсәрләренең нинди генә затлы үрнәкләре юк!

Миңа еш кына олы әдип-шагыйрьләребез иҗатына багышланган кичәләрне алып барырга туры килә. Хәтерлим, Г.Кутуйның туксан еллыгына багышланган шундый кичә Актерлар йортында узды. Ш.Сарымсаков, Ә.Еники, Р.Фәйзуллин һәм башка хөрмәтле әдәбият-сәнгать әһелләре чыгыш ясады. Залда Айрат Арсланов та утыра. Ул көнне Айрат абый авырып тора иде, күзгә үк күренә — кәефе юк. Әмма әлеге кичәгә килгән, килми кала алмаган. Мин сәхнәдән аны күзәтеп утырам, бу сүз остасы башкаруында берәр әсәр яңгыратасы килә. Аның исемен әйтүгә, ул яшәреп киткәндәй булды, сау-сәламәт кешеләрчә атлап сәхнәгә менде һәм «Сагыну» нәсерен укый башлады. Зал тып-тын калды. Г.Кутуй нәсеренә салынган хисләр тыңлаучыларны биләп алды. Артист залны үзе кичергән хисләр тирәнлегенә алып керде. А.Арсланов башкаруында бу әсәрне элек тә тыңлаганым бар иде, әмма бусы... Бу мизгел әлеге кичәнең иң югары ноктасы булды шикелле.

Ә М.Җәлил шигырьләрен укуы! «Моабит дәфтәрләре» циклын иҗат итүчене дә, авторның уй-хисләрен тәмам җелегенә үтеп аңлап, аларны иң югары дәрәҗәдә башкаручыны да егерменче гасыр тудырды. Г.Тукайга багышланган «Шагыйрь гомере», «Татарстан — туган җирем» һәм башка программалары, һәм тагын йөзләрчә башка бик күп әсәрләре аның репертуар байлыгын күрсәтәләр. Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге, җөмһүриятебезнең халык артисты исеме аның иҗатының лаеклы рәвештә тәкъдир ителүе турында сөйли.

А.Арслановның татар теленең матурлыгын раслауда, аңа хөрмәт тәрбияләүдә, аны кимсетү, кысу шартларында да камиллеген күрсәтеп бирүдәге хезмәтләре бәяләп бетергесез. Аны тыңлаганнан соң, минемчә, һәркем: «Менә нинди ул минем туган телем!» — дип горурланмыйча калмый. Бу — аның хезмәтенә һәм иҗатына бирелгән иң олы бәя.

А.Арсланов шагыйрь түгел. Әмма мин аның үзен шигырь итеп күз алдына китерәм. Шигырь исә матур, мәгънәле, нәфис, фикерле, хисле була. Боларның барысы да Айрат Арслановта бар.

*1998*

**ФӘНИС ЯРУЛЛИН**

## Гүзәл гамь

*Айрат Арслановка*

Сөйли Маэстро зур сәхнәдән,
Меңнәрчә күз аңа төбәлгән.
Канатланып шигырь оча залда,
Күңелләргә тулган гүзәл гамь.

Җанга бүтән берни кирәк түгел,
Мөлдерәмә күңел бу гамьнән.
Ишетелә Маэстро тавышы,
Әллә җирдән, әллә галәмнән.

Уйлата да, хәтта елата да,
Һич битараф итми бу тавыш.
Йөрәклардән сыгылып-сыгылып чыга
Татар шигырендәге моң-сагыш.

*1997*

**РАФАЭЛЬ СИБАТ**

## Сөйлисе сүзе бар әле...

Татарстанның һәм Россия Федерациясенең халык артисты Айрат Гәрәй улы Арслановны шәхсән үзем татар мәдәниятендә, нәфис сүз сәнгатендә иң нечкә хисле, бик тә зыялы, ифрат яхшы тоемлы, югары зәвыкка ия мәшһүр артистлардан саныйм. Мин генәме?..

Әнә шул җөмләне язып нокта куюга ук, күңел әллә ничек дәртсенеп-сискәнеп куйды.

— Соң, агайне, аның илаһи талантына уннарча йә йөзләрчә атаклы кешеләр генә түгел, меңнәрчә-меңнәрчә тамашачылар да баш ия.

Олуг Талант һәрвакытта да Күктән иңдерелә, ул бар икән, кеше үз иҗадилыгында гаҗәп тә зур хикмәтләр ясый. Ул мин күргән беренче чыгышы белән үк күңелне айкап, җанымны яндырып, рухыма меңнәрчә шәмнәр элгән әкият герое кебек тәэсир итте...

1966 елның апреле иде...

Даһи Тукайның тууына 80 ел үтеп, әлеге юбилейны (искә алуны дисәк тагы да дөресрәк булыр) уздырып йөргән чагы җәмәгатьчелекнең. Ул вакытта шигырь бәйрәме хәзерге кебек М.Җәлил исемендәге Дәүләт опера һәм балет театрының тынычрак урынында — ә анда Тукайга зур гына һәйкәл куелган! — түгел, ә машиналар, автобуслар, трамвайлар, троллейбуслар дөбер-шатыр чабып йөргән Кабан күле ягында уздырыла иде. Менә шунда беренче тапкыр күрдем мин Айрат абый Арслановны. Ул Г.Тукайның «Китмибез» шигырен укыды.

Менә күтәренке урынга зәвык белән киенгән озын төз гәүдәле берәү торып баса. Артка таралган шомырт кара чәчләр, чибәр йөз, әз генә эчке моң сирпелгән җылы, ләкин игътибарлы горур караш...

Ә шигырь укуы? Аның шигырьне укуы...

Матур тембрлы бәрхет тавыш шигырьне әллә ничек менә! — гүзәл чәчәкне кочагына алгандай, иплэп-җайлап кына, селкетми генә җаныннан этеп чыгара. Ә бит аның тавышы көчле, тезмә әсәрне урамда укый, монда һәркемнең ишетеп калуы кирәк.

Менә шул вакыт минем уема бер генә фикер килде: «Чын артист нәкъ менә Айрат Арсланов кебек булырга тиеш! Бар яктан да...»

Әлеге уемнан бүген дә кайтканым юк, ни генә димә — кайтканым юк! Беренче тәэсир күп вакытта озакка була бит ул, Айрат Гәрәй улыннан калганы да шундыйларга керә, ул — гомерлек! Шуңамы ул татарда 30–40 яшьләре тирәсендә үк мәшһүр кешеләрнең берсенә әйләнде һәм бүгенге көнгә кадәр шул «марка»сын югалтмый тотып килә. Ә бер уйласаң, аның сәхнә гомере генә дә 55 ел вакытны алып тора. Инде аңа быел апрель аенда 75 яшь тулды, дисәк, моңа бик күпләр ышанмас, чөнки Айрат абыебыз егетләр кебек әле. Дөрес, яшь барган саен авырулар да чакырылмый гына кунакка килә, хикмәт андамыни, хикмәт аларны зарланмый гына уздырып җибәрүдә. Ә инде аның «егет»легенә килсәк, Лена Шагыйрьҗанның «Шигъри ядкарь»ен искә төшерик:

> Мутланышып кайчак кызлар белән
> Саный идек бармак бөгепләр:
> Казанда бер ун ир бар микән
> Айрат Арсланов кебекләр...
> Гашыйк булып йөрдек читтән генә,
> Кызлар үлә — гашыйк булмаса...
> Театрдан башыбыз чыкмас иде,
> Таһир булып әгәр уйнаса...

Димәк ки...

Айрат Гәрәй улы кебек ирләр Казанда унау да юк дигән уй кергән кызлар башына. Сүз юк! — хаклы алар.

Белмим, баш миенең кайсы буразнасына сызылып-сызылып куелгандыр, миндә һәрвакытта да бер уй-фикер яши килде:

— Артист матур булырга тиеш!

— Артист һәр яктан да чибәр булсын ул!!

— Артист һәрвакытта да гүзәл күренсен!!!

Нигәме?

Шундый булу үзе үк ярты уңыш! Бары шуннан соң гына белем, үзең сайлаган юлга тулысынча, мәңгегә, фанатикларча бирелгәнлек...

Әнә карагыз! Айрат Арслан дигән мәшһүр артист сәхнәгә үк арыслан мәгърурлыгы, куәте, тынычлыгы, үз-үзенә ышанганлыгы белән чыга. Аның башкаларны тарту көченең бер ягы, бәлки, нәкъ менә шундадыр. Аның берүзенә сүз сәнгатенең өч төрле жанрында иҗат итү, эшләү таланты бирелгән була: радио дикторы, театр, нәфис сүз сәнгате. 20 яшендә үк ул Татарстан радиосы тапшыруларын алып бара, ә инде Казандагы Татар дәүләт театр училищесын һәм Мәскәүнең Луначарский исемендәге театр сәнгате институтын тәмамлауга, Татар академия театрында артист булып эшли башлый, ләкин соңыннан барыбер иҗади хезмәтендә нәфис сүз сәнгатен сайлый. Аны, һич тә арттырмыйча, күпертмичә, ике телле башкаручы дияргә була. Татар шагыйрьләреннән Тукай, Һади Такташ, Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Нури Арслан, Илдар Юзеев, Равил Фәйзуллин, Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләм, Харрас Әюп әсәрләрен укыса, рус поэзиясеннән Пушкин, Маяковский, К.Симонов, М.Львов, С.Есенин һәм башкаларны сәхнәдә укып дан казана, Бөтенроссия конкурсларында катнашып әллә ничә тапкыр лауреат, дипломант була. Менә кайда ул татарның сүз сәнгатендә очышы! Кемгә ничектер, миңа ул Рудольф Нуриевның балет дөньясында йолдызга әйләнүе, «оча торган татар» булуыннан бер дә ким түгелдер кебек тоела. Чөнкиме? Чөнки... Айрат Арсланов та нәфис сүз сәнгатендә илаһилыкка ирешә алды, ул бу яктан кабатланмас шәхес булып тора, андыйлар, кемдер әйтмешли, гасырга бер генә туа. Андый даһилык таҗына дәгъва кыла алган кеше бездә тагы берәү генә бугай, ул — Илһам Шакиров. Гомумән, кай яклары беләндер күпмедер дәрәҗәдә алар бер-берсенә охшашлар да кебек. Талантлары, илаһилыклары беләнме? Әнә шагыйрь Зөлфәт үзенең «Күрсенмә, татар!» шигырендә нәрсә ди:

Упкын читләрендә калган чакта
Без — татарның кара язмышы,
Упкыннардан йолды Илһам моңы,
Айрат абыйның таң тавышы.
Иксез-чиксез вакыт уза торыр —
Яңаларны җиргә чакырыр.
Ләкин татар
Айрат булып сөйләр,
Моңы булыр Илһам Шакиры.
...Мәңгелекнең теге ягына да
Барып чыккан татар кардәшем.
Илһам Шакир булып моңайсын да
Айрат Арслан булып сөйләшсен!

Әлеге мәшһүр сүз остабыз безнең илне аркылыга-буйга йөргән, концертлар, очрашулар белән Мәскәүдә, Ленинградта, Ульяновскида, Волгоградта, Свердловскида, Чиләбедә, Оренбургта, Уфада, Төмәндә, Томскида, Алма-Атада, Дүшәнбедә, Ташкентта, Сәмәркандта, Хабаровскида, Норильскида... Йә, аларны — ул калаларны санап чыгарга да бер бит түгел, биш-уны җитмәс, туктыйк! Әмма дә ләкин...

Тик шулай да аның 1968 елда ук татар артистларының җитәкчесе булып Финляндиягә барып чыгуын искә алмау ярамастыр — фин һәм Казан татарларын тоташтыру ич бу, алар белән якын элемтәгә керү, чит җирләрдә калганнар белән мәдәни-сәнгати-әдәби мөнәсәбәтләр, аралашулар оештыру. Бу язмамны язганда мин Татарстан радиосын да тыңлый идем, менә шунда бер фин-татар егетенең: «Мин Казанга татар һәм рус телләрен өйрәнергә килдем», — дип саф татарча сөйләве йөрәгемә сары май булып ятты. 1968 елларда ук Айрат Арсланнар уяткан буын бу, дөресе — шул буынның балалары. Татар кайда да татар ул, күп җирдә аның милли җаны йоклаган — аны уятырга кирәк! Ничек? Илһам Шакиров моңы, Сәйдәш музыкасы, Айрат Арсланов сүзе белән...

Мин үзем бүген дә бер нәрсәгә борчылып яшим: сәхнәне моңсыз яшь җырчылар, шамакай булып йөрүче конферансьелар басты. Аларга нәрсә — музыканы таулардан таш тәгәрәгәннән катырак акырт та микрофонга үкер, билдән түбән якның хикмәтле хәлләр кичерүе турында, тамашачы елмаерга өлгергәнче үзе сәхнә идәнендә тәгәрәп көлеп, анекдот-мәзәк сөйләү булсын. Ташка үлчим!..

Кайда Илһам Шакиров мәктәбе?..

Кайда Айрат Арсланов мәктәбе?..

Әллә инде бүгенге яшьләр яисә уртарак буын мокытланып беткәнме, шашканмы, белемсез-тәрбиясезме? Булыр, булыр — булмас димә...

Сүз тәмен кемнәрдән өйрәнәләр?

Сүз тәмен белгән кешеләрдән! Димәк, Айрат Арсланнан һәм аңа тартым-охшаш артистлардан!! Менә кайда ул туган телнең гүзәллеге, көче, кодрәте, илаһилыгы, мәңгелеге...

Минем үземчә бер нәни генә күзәтүем дә бар: халык үз ихтыяҗына бик кирәк чакта үз арасыннан бер бөек улын йә кызын тудыра. Әйтик, 50 нче еллар тирәсендә, дөресрәге, хәтта бераз соңрак, шәһәр җирләрендә татар телендә сөйләшүчеләр күзгә күренеп кими барды. Әле бит бу Татарстанда! Башкортстанда, башка рус өлкәләрен искә төшереп тә торасы килми, анда ул татарча дигән нәрсә мифик җанварның аваз салуы кебек кенә күренәдер. Әнә шулай меңьеллык шагыйрьләре булган бөек тел бетүгә йөз борды, ул күбрәк авылда гына калды. Һәм менә...

Әйе! Һәм менә тыңлагыз әле бу телне, ишетегез әле аһәңен, аңлагыз әле сүз тәмен дигәндәй, милләт татар сүз сәнгатенә үзенең бер улын бирә. Киләчәктә мәшһүр, атаклы булачак улын...

Андый арыслан улны без бераз соңрак Айрат Арсланда күрдек, бу гали затның сүз сәхнәсенә килүенә сөенеп йөрдек, өметебезне аның тавышы белән төрдек. Ул юмарт җанлы иде, халкына вакытын да, тырышлыгын да, көчен дә җәлләмәде, вакыты җиткәндәй, Тукай сүзләре белән «Китмибез!» дип, татар сәхнәсенә күтәрелде. Ә «китмибез» нәрсә иде соң ул? Бу — протест, дөньяга үз теләгеңне, хак сүзеңне әйтү.

— Татар үз теленнән китми!

— Татар татар булып кала, дөньядан китми!

Менә нәрсә иде ул «Китмибез!» Һәр фикернең астында икенче фикер бар, бәлки, өченче, дүртенче... Монда да шундый катлаулы һәм катламлы фикерләр...

Әйе! Айрат абый Арслан үз халкына шундый олуг эш эшләде, хезмәт күрсәтте, алда да берүк исән-сау гына булсын да сәхнәдән төшмәсен, радио-телевидениедән китмәсен, чөнки аның сөйлисе сүзе бетмәгән.

Безнең татарга соңгы вакытларда нәкъ аның кебек фидакарь кешеләр җитеп бетми кебек тоела миңа, чөнки үзе турында гына уйлаучылар артканнан-арта, күбәйгәннән-күбәя бара. Мал хисе һәм эгоизм исе басты безне...

...Айрат Арсланов...

Әдәбият-сәнгатьтә иң бөек шәхесләрне искә төшерсәк, без: поэзиядә — Тукай, музыкада — Сәйдәш, рәсем сәнгатендә — Бакый Урманче, җырда Илһам Шакиров дибез. Ә менә нәфис сүз сәнгатендә — Айрат Арслан!

Әйе, матур сүз алышында арыслан ул... Иң мөһиме, алга таба да әйтер Сүзе бар, укыр Сүзе бар, сөйләр Сүзе бар...

Ә андыйлар булганда халыкның милли җаны бар, «Без — татарлар!» дигән сыны бар, алда да яшәр түле бар һәм, әлбәттә, меңнәрчә еллардан килгән газиз, изге, кадерле, илаһи, гүзәл... — Бөек Теле бар.

*2003*

**РЕНАТ ЕНИКЕЕВ**

## Музыкаль зәвыклы шәхес

Композиторларыбызның Айрат Арслановка хөрмәте һәм мәхәббәте чиксез. Ул безнең күптәнге якын дустыбыз. Классикларыбызның иҗатын һәм шәхесен Айрат Арсланов кебек яхшы белүче сәнгатькәрләребез сирәктер. Шуңа күрә без искә алу кичәләрендә, мемориаль такта ачу тантаналарында аны еш күрәбез һәм аның гаять кыйммәткә ия фикерләрен тирән дулкынлану хисләре белән кабул итәбез.

Ораториаль жанрда исә композиторларыбыз үз әсәрләрен махсус Айрат Арсланов башкаруын истә тотып иҗат итәләр.

Аеруча әһәмияткә ия кичәләрне алып барудан тыш, Айрат Арсланов безнең даими тыңлаучыбыз да. Тирән эрудицияле, нечкә музыкаль зәвыклы шәхес буларак, Айрат Арсланов белән яңа башкарылган әсәрләр турында фикер алышу күңелле дә, файдалы да. Мәдәниятебезнең Айрат Арсланов кебек олы һәм уникаль шәхесе белән алдагы елларда да иҗади дуслыгыбыз озын гомерле булсын дигән теләктә калам.

*1997*

**ӘХСӘН БАЯН**

## Рәхмәт!

*Сүз остасы Айрат Арслановка*

Рәхмәт сиңа барча шагыйрьләрдән,
Олысыннан рәхмәт, кечесеннән.
Ә бигрәк тә мин аларның, Айрат,
Аерып рәхмәт әйтәм өчесеннән.

Рәхмәт Тукай, Такташ һәм Җәлилдән —
Яшисең бит гүя алар өчен —
Уй һәм сүзләренә үз жаныңнан
Ялкын өсти-өсти янар өчен.

Сиңа рәхмәт китап битләрендә
Тып-тын гына яткан көй-җыр өчен,
Синең көчле, моңлы тавышың аша
Яңгырашка ия шигырь өчен.
Якты өсти алган гомер өчен,
Сиңа рәхмәт!

*1996*

**НАҖАР НӘҖМИ**

## Осталык көче

Осталык — матурлыкка алып бара торган гамәл, ләкин Айрат Арслановтагы матурлык үзе осталыкны югарырак баскычка күтәрә торган сыйфат.

Айрат Арслановка Ходай Тәгалә берни дә жәлләмәгән: буй-сынын да, төс-башны да, хәтта өс-башны да — матур кешеләргә кием дә ныграк килешә, дип әйтә калсаң, фәкать Айрат Арслановны күз алдында тотарга кирәк.

Ләкин Айрат Арслановның төп матурлыгы аның йөрәгендә, ул йөрәк — тирән һәм нечкә тоя белгән йөрәк, моңлы йөрәк.

Моң... Гадәттә, җырчыларга карата «Ул моңлы тавышлы» диләр. Айрат Арсланов җырчы түгел, ә сүз остасы, әмма үзенең тавышы моңлы.

Әле искә алган бөтен сыйфатлар Айрат Арслановта бергә кушылып, бербөтен гармония хасил итәләр, бу гармонияне сүзләр белән генә күз алдына бастыру мөмкин түгел, ә Айрат Арслановның үзен күрергә һәм тыңларга кирәк һәм аны, ул гармонияне, бер генә мисалда да күрсәтү җитә.

Мәсәлән, Айрат Арсланов берничә башкорт шагыйренең шигырьләрен үз репертуарына сайлап алып Башкортстан радиосы аша укыгач, радио хезмәткәрләре тагы берничә башкорт шагыйренең шигырьләрен укуны сораганнар һәм шигырьләрен аңа җибәргәннәр. Айрат Арсланов аларның үтенечен, әлбәттә, кире какмаган.

Бер дә бер көнне радио аша Айрат Арсланов укуында шул шагыйрьләрнең шигырьләрен тыңлагач исем китте: бик тә уртача шигырьләр шундый чын шигырьләр булып яңгырады ки, мин эчемнән генә: «И осталык көче!» — дип куйдым.

*1997*

**ФЛЕРА САФИУЛЛИНА**

## Телебезнең бөеклеген, гүзәллеген тоеп...

Айрат Арсланов... Бу исем үзе үк дистәләрчә еллар буе аһәңле тавышы белән күңелләрне тетрәтеп, җилкендереп, моңландырып, хушлатып яшәгән мәшһүр артистларыбызның тыйнак осталыгы турында сөйли. Әйе, бу исем Айрат аганың үзе шикелле үк зәвыклы да, пөхтә дә, төзек тә, ямьле яңгырашлы да.

Айрат аганың сәхнәгә чыгуы да, аның килеш-килбәте дә, өстендәге киеме дә, сөлектәй гәүдәсе дә, аның һәрвакыт урынлы кул, гәүдә, йөз хәрәкәтләре дә, тавышының һәрчак үлчәнгән көче дә, бизәге дә, көе дә, тизлеге дә сәхнә остасының затлы, нәзакәтле булуын сөйли.

Шигырьне ул ритмик калыбы буенча түгел, эчке мәгънәсенә басым ясап укый. Укыла торган әсәре, шигырьләре һәрвакыт югары эстетик зәвык белән сайланган булыр. Мин аның беркайчан да буш шигырьләр укыганын хәтерләмим.

Айрат аганың укуы сәнгатьчә эталон дәрәҗәсендә: аннан орфоэпик хаталар табу мөмкин түгел, аның һәр авазы ачык, төгәл һәм телебезнең әдәби әйтелеш кануннарына бөтенләе белән җавап бирә. Айрат ага сүзләрнең язылышын укымый. Бөтен хикмәт шунда: язылган җөмләне ул бердәнбер мөмкин булганча укый белә.

Аның өчен сәхнәдә СҮЗ бар, шул сүзләрдән тезелгән шигъри энҗеләр бар, шулар арасында безнең колагыбызга гына түгел, йөрәгебезгә үткәреп сөйләүче Айрат ага бар.

Айрат ага үз иҗаты белән күп еллар буе татар сәхнәсен бизәп, аның сәнгатьчә югары дәрәҗәсен саклап килде. Тукаебыз да ул укыганда матуррак яңгырый... Яраткан шагыйребез тагын да күбрәк ачыла бара кебек.

Шигырьне аның кебек укучы юк. Сибелеп яшәгән татар халкы арасында Айрат ага концертлар белән күп йөргән. Аны бер тыңлау бәхетенә ирешкән кеше телебезнең матурлыгын, шигъри яңгырашын, бай мөмкинлекләрен тоя ала. Олуг артистыбыз кая барса да, туган телебезгә сусаган йөрәкләргә ялкын өстәп китә...

*1998*

**ГОСМАН ӘХМӘТҖАНОВ**

## Сабакташым һәм хезмәттәшем

1945 елны, әле сугыш та бетмәгән вакытта, республика хөкүмәте сугышка кадәр эшләп килгән театр техникумының эшен яңартырга, сәхнә өчен кадрлар әзерләү хәстәренә керешә. Бу юлы уку йортын Татар дәүләт театр училищесы итеп ачалар, һәм аңа укучылар җыю башлана. Без — 30 лап сугыш чоры балалары — шунда кереп укый башладык. Араларында мин генә сугышта яраланып кайткан таяклы инвалид идем. Аягымның төзәлүгә барганын әйткәч, алдылар. Ишебез арта барып, без өч төркемгә бүлендек. Берсен — Ширияздан Сарымсаков, икенчесен — Сәет Булатов, өченчесен Кәшифә апа Тумашева җитәкләде.

1 нче курсны тәмамлагач, безгә турыдан-туры 2 нче курска Айрат Арслановны алдылар. Бу егет безнең бөтенебездән аерылып тора иде. Беренчедән, килешле буй-сын, тумыштан килгән интеллект, бай тавыш материалы, сабырлык, тыйнаклык... Һәм ул шунда ук безнең барыбыз өчен дә бер үрнәккә, эталонга әверелде. Буй-сын, матурлык белән булмаса да, тотыш, мөгамәлә, холык җәһәтеннән аңарга охшарга тырыша идек. Укытучыларыбыз да аның бу күркәм сыйфатларын күреп алдылар.

Безне татар теле, әдәбияты буенча мәшһүр Латыйф Җәләй, сөйләү техникасы һәм сүз осталыгына Луиза апа Салиәскәрова (Х.Туфан хатыны), атаклы вокалист Федор Витт укыта иде. Бу педагоглар безгә төрле әсәрләр сайлап, шуларны бүлеп-бүлеп укыталар иде: Толстойның «Боз сугышы», Пушкинның «Полтава» поэмаларын, Г.Тукай, М.Гафури, Ф.Хөсни һәм башкалар әсәрләрен. Монда бер башланган стильдән, аһәңнән тайпылмыйча, башкалардан калышмый, сынатмыйча уку мөһим иде. Менә шунда инде Айратның тавыш мөмкинлекләрен күреп алдылар, аны акрынлап радиотапшыруларга, концертлы кичәләргә тарта башладылар. Әминә Сафиуллина, Мәрьям Фәйзуллина, Шәүкәт Биктимеров, Фатих Шәрәфиевләр дә радиода еш катнашалар иде.

Безне — училищены кызыл дипломга тәмамлаучылардан биш кешене — Татар дәүләт академия театрына алдылар. Театрда көндәлек иҗат тормышы башланды... Ш.Сарымсаков безнең училищеда уйналган «Шомлы көннәр»не зур сәхнәгә куйды. Айрат анда революционер Мирвәли ролен уйнады. Айратның театрдагы эшләреннән иң зурысы, ихтимал, «Таһир-Зөһрә»дә Таһир образы булгандыр. Монда аның җыр сәләте киң ачылып китте. Шулай ук «Зәңгәр шәл»дә Булат образы. Вокал белән бәйләнгән бу авыр образларны Айрат зур уңыш белән башкарды.

Әмма болар барысы да Айрат өчен бер этап, трамплин булдылар шикелле. Ул ялгыз сүз сәнгатен, «бер актер театры» дигән сәнгать төрен сайлады һәм бу өлкәдә гаять зур уңышларга иреште. Болай гына әйтү аз, әлбәттә, гаять зур батырлык үрнәге күрсәтте ул. Башта училищедан, театрдан аерылмыйча гына радиога, аннан, телевидение ачылгач, экраннарга чыкты.

Һәм менә эстрада. Анда ул — патша! Тормыш гамьнәре, мәшәкатьләре, кайгы-хәсрәтләре арасында бәргәләнеп, адашып йөргән йөрәкләрне әсир итеп, аларны әдәби сүз, җылы аһәңнәр диңгезендә тирбәтеп дәвалаучы табиб дияргә була. Һәм мәгърифәтче.

Әлбәттә, аңа кадәр дә сәхнәдән, эстрададан сөйләүче артистлар бар иде. Хәким ага Сәлимҗанов, Әзәл ага Яһүдин, Фәйзи ага Йосыпов үзләрен яхшы сүз осталары итеп таныттылар. Әмма Мәскәү ГИТИСында укып, Сурен Кочарян, Яков Смоленский кебек танылган профессор — сүз осталарыннан белем алып кайткач, Айрат ике телдә дә — татарча да, урысча да бердәм камил сөйләшә. Шул сәбәпле татар шигъриятен урыслар арасында пропагандалауда аның хезмәте әйтеп бетергесез зур булды. Һәртөрле аудиториядә ул үзен бердәй иркен тотты. Минемчә, соңгы ярты гасырда һәрбер яңа китап-шигырьләр җыентыгымы ул, әллә саллы проза томнарымы, публицистик газет-журнал мәкаләсеме — иң элек Айрат кулына килеп керә иде. Чөнки ул үзе дә йотлыгып китап эзләүче, яңа әйбер, яңа сүз эзләүче буларак һәр яңалыкны кулдан ычкындырмаска тырыша, икенчедән, безнең барлык могтәбәр шагыйрь, язучы, галимнәребез үзләренең яңа әйткән сүзләрен Айрат «беләвендә» чарлап карарга тырышалар һәм бик теләп аңа автографлы китапларын бүләк итәләр иде. Янәсе, бәлки, сезнең игътибарны җәлеп итәрлек әйбер дә табылыр?

Чынлап та, күп кенә язучыларыбызның күренекле әсәрләре аның башкаруында олы сәхнәгә чыкты. Радиода булсын, телевидениедә, эстрада, гади концертларда булсын, тыңлаучылар йөрәгенә иң дөрес әйтелгән сүз, иң мантыйклы фикер күңелгә иң ятышлы аһәң булып кереп урнашалар. Хәсән абый Туфан акланып кайткач, алар бер-берсен тапкан яхшы дуэт кебек булдылар. Хәсән абыйның үзенең дә укуы бик кызыклы, үзенчәлекле иде, әмма Айрат укуында алар тирән классик форма алдылар. Айрат шулай ук Сибгат Хәким, Нури Арсланов, Нәби Дәүли, Илдар Юзеев, Әхсән Баян, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов кебек бик күп олы шагыйрьләрнең дә җан дустына әверелде. Муса Җәлилнең әсирлектә язган шигырьләре дөнья гизеп илебезгә кайткач, аларны беренче яңгыратучылар Айрат Арслан һәм мәрхүм Салих Сәйдәшев булдылар. «Җырларым»ны без Айраттан кайнар шигырь буларак ишетсәк, Салих абыйдан үлмәс җыр рәвешендә ишеттек. Аннан соң азатлык җилләре исеп, элек халкыбыз югалткан бик күп исемнәр кайта башлады. Кол Гали, Сәйф Сараи, Кол Шәриф, Мөхәммәдьяр, Габделҗаббар Кандалый, Гали Чокрый, Дәрдмәнд, Шәехзадә Бабич, Галимҗан Ибраһимов һәм башкалар исемнәрен санау да озакка китәр иде. Һәрберсенең халкыбызга кайтуында Айрат Арслановның хезмәте биниһая зур булды. Аның филармониядәге төп эшеннән кала һәр үткәрелгән чараларда, һәрбер кичәләрдә, очрашуларда катнашырга өлгерүенә хәйран калырлык. Кайларда гына үткәрелми иде ул очрашулар. Мәктәпләр, музейларда, район һәм авылларда, күп очракта ачык һавада, ә кайчакта үтәли җил уйнап торган салкын биналарда.

Шундый чакта алган авырулар да аңа сабак булмады, аның кайнар трибун йөрәген сүрелдерә алмады. Салкын биналарда чыгыш ясаганда да ул һәрвакыт формада булырга, затлы костюмнан, ап-ак якалы күлмәктән, галстуктан яки бантиктан булырга тырыша. Бу ягы белән ул мәрхүм Салих ага Сәйдәшевкә охшый: ул да һәр минутта, һәр секундта халык алдына чыгып басарга, иҗатка әзер иде. Сүз остасы... Нинди сыйфатлар кирәк соң бу сәнгать өчен? Әлеге дә баягы әйтеп киткән мәһабәт буй-сын, колакка ятышлы көр, аһәңле тавыш, тел законнарын белү, көчле мантыйк һәм тагы бераз композиторлык. Әйе, әйе... Чөнки тел остасы да кулына текстны алгач, аның аһәңен, ритмын, фразаларга бүленешен, төп һәм ярдәмче темаларны табарга һәм үзенә, кәгазьдә булмаса да, күңелдән партитура төзергә тиеш, һәм бу партитура мәңгегә күңелгә сеңеп калырга, ягъни теләсә кайсы вакытта сөйләгәндә дә ул искә төшәргә һәм дөрес нота кебек бер юлдан алып барырга тиеш.

Айрат Гәрәй улы Арсланов белән башта сабакташ буларак, соңыннан радиода иҗатташ, хезмәттәш буларак аралашуыма шөкрана итәм һәм горурланам. Чөнки Айрат белән радиода бихисап күп тапшыруларны бергә эшләдек.

Бер-беребезнең эшеннән һәрвакыт канәгать була идек. Чакырган вакытта аның тарафыннан һич кенә дә «юк» дигән сүз ишетмәдем. Ошамаган әйбер булса да бергәләп җиренә җиткерә идек. Әмма Айрат кемдер эшләп кулга китереп тоттырганны да көтеп ятмый. Үзенә ошаган энҗе бөртекләрен бергә туплап, үзе композицияләр ясап китерә. Мин дә үз тарафымнан аларга иң муафыйк музыкаль фрагментлар табып, урынлы җирдә генә бизәргә тырыша идем. Андый әсәрләрнең исемнәрен санау бик озакка китәр. Мисалга берсен генә әйтеп китәм: Г.Исхакыйның Г.Тукай үлеменең берьеллыгына карата (Тукай үлгәндә Исхакый сөргендә була) язган әсәре «Милли фаҗига». Без аны эшләгәндә күз яшебезне тыя алмадык...

*2003*

**ҖӘҮДӘТ СӨЛӘЙМАН**

*Айрат ага Арслановка багышлыйм*

Ак битләрне каурый-каләм бизәсә дә,
Уйламагыз шигырь яза шагыйрь диеп,
Алданмагыз, сүзләр сүзгә иярсә дә,
Күңелегезгә хуш килерлек вәзен киеп.

Юк, тырышмыйм ошасын
дип берәр кемгә,
Юк, мин язмыйм язам
диеп бер-бер шигырь.
Ширпы суырам бәгыремнән
рифма берлә,
Сызлауларым басылсын дип,
тынсын бәгырь.

*Октябрь, 1994*

**ЛӘБИБ ЛЕРОН**

## «Без бәхетле идек,
## без хәзер дә бәхетле!»

Ышан миңа — бәхет шунда,
Безне сөйгән һәм ышанган урында.

*М.Лермонтов*

**Икесе дә милләтебезнең асыл заты, зыялысы булган бу искиткеч гүзәл парга үзләрен күрә-белгәннән бирле якты күңләшү илә сокланып яшим. Сокланырлык та шул: инде ничәмә-ничә еллар алар һәрвакыт бергә, һәрчак иңгә-иң — мәхәббәттә дә, гаиләдә дә, сәнгатьтә дә... Борчу-мәшәкатьләр, шатлык-куанычлар уртак. Үзләре чибәр, сөйкемле, тавышлары ягымлы, мөлаем. Аларның йөз-карашларыннан садә елмаюлар һәрдаим сирпелеп тора. Күптән түгел генә миңа әлеге күркәм пар белән очрашып, үзара дустанә гәпләшеп алу насыйп булды.**

**Бергә яшәүләренә илле ел тулган, ягъни алтын туйларына — олуг бәйрәмнәренә әзерләнгән көннәре иде аларның.**

**Әңгәмәдәшләрем — Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты Айрат Гәрәй улы Арсланов һәм аның сөекле хатыны Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Мәрьям Ислам кызы Арсланова. Тәүге соравым аларның кайчан, ничек танышулары хакында иде. Җавап сүзен Мәрьям ханым алды:**

— Безнең танышуыбыз укыганда булды инде. Без бит икебез дә театр училищесында бергә укыдык. Мин ул чакта Казанда, әтием фатирында, үги әниемнәрдә яши идем. Күптәннән артист булырга тели идем. Училище директоры, шул ук вакытта актерлык осталыгыннан дәресләр бирүче Сәет абый Булатов мине «өметле» дип укырга алды. Икенче курста укыганда Айрат килде. Аны шундук икенче курска алдылар. Этюдлар, спектакльләр уйнаганда парлы рольләрне гел безгә бирәләр иде. Т.Гыйззәтнең «Ташкыннар»ында Айрат — Мирвәли, мин — Айсылу, А.Арбузовның «Яшьлек белән очрашу»ында Айрат — Максим, мин Маша идем. Шулай итеп без һаман бергә уйнадык. Айратка бик күп кызлар күз салалар иде. Айрат үзе беркемгә дә карамый, бик важный гына йөри... (*Мәрьям ханым рәхәтләнеп көлә, аның ихлас, самими көлүенә Айрат абый белән икебез дә кушылабыз.*) Бервакытны, Айрат ул чакта Горький урамында тора иде, мин травматология институты яныннан үтеп барам икән. Айрат мине үзе яшәгән фатир тәрәзәсеннән карап торган. Очрашкач әйтә: «Сине мин гел күзәтеп торам. Бу юлысында да тәрәзә пыялаларындагы чагылышыңа карый-карый килдең», — ди. Икенче мәртәбә тагын әйтә: «Бүген сине чүт машина таптамады», — ди. Ишегалдыннан машина килеп чыккан икән, мин куркып киткәнмен. Мин шикләнә калдым: «Нишләп бу мине тәрәзәдән карап тора икән?» — дим. *(Янә көлешәбез.)* Бервакытны Айрат прәннекләр белән сыйлый башлады. «Авылдан әни пешереп җибәрде», — ди. Ул вакытта бит ипи дә карточка белән генә иде. Мин инде янә уйлана калдым. «Бу миңа битараф түгел, күрәсең», — дим үз-үземә. Шуннан соң ул безгә килеп йөри башлады. Үги анам аны бик яратты. Без аны үзебезнең кеше итеп каршы ала идек. Бергәләп мич ягабыз. Ул чакта мичкә ягышлы иде әле...

— Идел буендагы бакчагызга бәрәңге утыртырга, казырга да бара идек, — дип, көлә-көлә искә төшереп, Айрат абый да сүзгә кушылды.

**Сүз иярә сүз китте. Туган яклар, нәсел-нәсәпләр турында сөйләшүгә күчтек.**

— Мин үзем Башкортстаннан, — дип, әңгәмәне дәвам итте Айрат абый. Менә мин балачакта Учалыда (хәзер шәһәр инде ул), Кырмыскалыда — Мирсәет Солтангалиевнең туган ягында яшәдем. Аннары без Балтачка килеп төпләндек. Ул Башкортстанның төньягында. Борай, Тәтешле районнары белән чиктәш. Шул вакытта әти, бер ел Мәскәүдә укып кайткач, кортчылык буенча зоотехник булып эшли башлады. «Алтмыш колхозның кортлар патшасы», — дип йөртәләр иде аны. Менә шундый гаиләдән инде без. Минем хакта бер язучы: «Бал ашап үскән егет», — дип язып та чыккан иде... *(Көлә.)* Бал ашадык инде. Әтигә ярдәмләшеп, кортларны карашып. Безнең үзебезнең ун-унбиш баш корт (умарта) була иде. Әтинең бакчасын «Мичурин бакчасы» дип йөртәләр, бөтен мичуринчылар белән диярлек хатлар алыша иде. Төньяк Башкортстанда виноградка хәтле үстерә иде. Әти безгә үзе үстергән виноградларны гел җибәреп торды. Калайдан савыт ясап, аны балавыз белән сылап, почта аша кәрәзле бал да җибәрде. Әти урысча да яхшы белә иде. Авыл интеллигенты инде менә. Миңа бик булышты...

**Айрат абыйның әлеге хатирәсеннән соң әңгәмәне Мәрьям апа ялгап алып китте:**

— Мин Себердә туганмын. Кемерово өлкәсенең Сарсаз дигән бер татар авылында. (Тормыш-көнкүреш авырлыгыннан качып, бәхет эзләп Себер ягына күченгәннәр, шунда нигез корган авылларына Сарсаз дип исем кушканнар. — *Л.Л.*) Минем бабамнар Чиләбе өлкәсеннән чыкканнар. Бабам, Кемерово өлкәсенә килгәч, тимер юлда эшләде. Шул вакытларда әти һәм әни өйләнешәләр. Әтине авыл советы рәисе итеп ку-

ялар. Бераз эшләгәннән соң Казанга рабфакка укырга китә. Шунда янә өйләнә. Шулай итеп без авылда калабыз. Бабай белән нәнәй, этине онытып бетермәсеннәр дип, апам белән мине Казанга еш алып киләләр иде. Берара без эти гаиләсендә дә яшәп алдык. Әти бик чибәр кеше иде. Язучылар оешмасында партоешма җитәкчесе булып эшләде. Өлкән язучылар аны әле дә хәтерлиләр. 1937 елда этине кулга алдылар. Аны кулга алгач, әниебез Шәмсенур безне янә Себергә алып китте. 1940 елда этине аклап төрмәдән чыгаралар. Чыгуга аны өлкә комитетының ул чактагы беренче секретаре Зиннәт Муратов үз янына агитация һәм пропаганда бүлеге мөдире итеп эшкә ала. Шуннан соң эти мине гел үз янына чакырды: «Кил, кызым, кил, юлыңа акча җибәрәм», — ди торган иде. «Вокзал начальнигына да акча җибәрәм, ул булышыр», — дия иде. Кызганычка каршы, сугыш башланды. Шулай итеп мин баралмыйча калдым. Әти үзе теләп сугышка китә. Батальон комиссары була. Әти сугыштан кайтмый, хәбәрсез югала. Дөрес, соңыннан, безнең көннәрдә, аның каберен эзтабарлар тапты. Мине чакырганнар да иде. Мин баралмадым инде...

**Шул дәһшәтле сугыш елларында Мәрьямгә, сигезенче сыйныф баласына, яшьтәшләре белән бергәләп завод станогы янына басарга, токарь хезмәтен башкарырга туры килә. Сугыш беткәч, әнисе Шәмсенур апа иренең фронттан язган васыятен — «Кызларны укыт, кеше ит!» дигән сүзләрен үтәп, хәленнән килгәнчә, ничек кирәк — шулай җайлап, акча юнәтеп, апасы Гәүһәр белән икесен Казан каласына озата...**

— Ул елларда менә шулай тормыш итә башладык инде, — **диде Айрат абый, Мәрьям апаның сүзләрен куәтләп.** — 1949 елда театр мәктәбен икебез бергә тәмамладык. 1951 елда өйләнештек. Хәзерге өйләнешүчеләр белән үзебезнең кавышуны чагыштырып карыйм кайчак. Мәрьямнең бер пәлтә кисәге, кечкенә чемоданы бар иде. Минем дә шулай. Укырга абыйның шинелен киеп килдем мин. Ятак бар да одеял-мазарлар. Мәрьямнең үги анасы фатирында беренче кызыбыз Гөлнар туды. Шулай яши торгач, үзебезгә беренче фатирны алдык. Ленин районыннан. Унөч квадрат метрлы бер бүлмә. Шунда икенче кызыбыз Алсу туды. Шунда торып яттык инде менә. *(«Шундый бәхетле идек без, безгә бүтән бернәрсә дә кирәкми иде», — дип әйтеп куйды шулчак Мәрьям апа.)* Әйе, шундый бәхетле идек. Безгә артистлар җыела иде. Рөстәм Яхин, Нияз Даутов, Усман Әлмиев керә иде. Мостафа Ногман еш була иде...

**Берничә елдан соң фатирның яхшырагына, зуррагына ирешә Айрат абый гаиләсе.**

**Айрат абый белән Мәрьям ханым үзләренең туйларын ничек һәм нинди шартларда уздыруларын да якты вә күңелле хатирә итеп искә төшерделәр.**

— Безнең туебыз өчәү булды бит, — **диде Айрат абый.** — Мәрьям апаң белән икәү кичә хәтергә төшереп утырдык. Берсе монда, Казанда булды. Гомәр абый Еникиев, Сәет абый Булатов, остаз-педагогларыбыз, артистлар килде, хатыны белән беренче мәдәният министры Йосыф ага Закиров булды. Шуннан соң кайттык инде Балтачка, минем туган авылга. Монда безгә никах укыттылар. Без ул вакытта бик актив комсомоллар идек. Әни мулла чакырткан булган. Ул таң вакытында ук килеп җитте. Безне дәшәләр, Мәрьямнең эти-әнисенең исемен сорыйлар. «Нинди никах ул?» — дибез. Икенче бүлмәдән чыкмаска итәбез. Өлкәннәр сүзенә дә каршы килеп булмый. Шулай укыттык инде никахны. Никахлы булдык. Шуннан соң Себергә, Мәрьямнәр ягына кайттык. Анда да туй. Бик зурлап үткәрдек...

**Менә шулай башлана милләтебезнең бүгенге көндә йөзек кашы булган бу затлыларның бергәбергә тормыш итүе.**

**Театрны никадәр яратса да, Мәрьям ханым, этисенең «Зур белемле кеше бул!» дигән сүзләрен истә тотып, педагогия институтының тел һәм әдәбият бүлегенә укырга керә. Аны тәмамлагач, Казанның 113 нче мәктәбендә балалар укыта башлый. Шул елларда аны радиога диктор итеп чакыралар. Егерме елдан артык радиода диктор вазифасын башкара ул. Бүгенге көндә дә әлеге хезмәтенә тугрылыклы — мәртәбәле «Тел күрке — сүз» тапшыруын яратып, җаны-тәне белән бирелеп алып бара.**

**Айрат абый да үзенең хезмәтен радиода диктор булып башлый. Театрда эшләгән елларында Мәскәүнең театр сәнгате институтын тәмамлый. Театрда күп кенә героик рольләр башкара. Бүгенге көндә дә радио белән даими элемтәдә тора. Өч дистә елдан артык Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясенең әйдәп баручы артисты була. Сәнгать сөючеләргә ул затлы башкаручы, нәфис сүз остасы буларак бик яхшы таныш олуг Шәхес. Могтәбәр язучыбыз Марсель Галиев Айрат абый Арсланов турында болай дип язган иде: «Ул — татар затлысы менә нинди була дип, Парижларда йөртерлек мәһабәт ир-егет. Ул — телебезнең бай аһәңен бүтән милләт кешеләренә дә җиткерә алу осталыгына ия. Ул сәнгатьле итеп укыганда, мин Тукайның мәхәббәт шигырен яңадан ачтым, әрнүгамьнәрен эчтә саклаган Хәсән Туфан, Сибгат Хәкимнәрнең күңел коесы тирәнлеген тойдым...»**

**Кавышуларына һәркем сокланырлык матур гаилә коруларына илле ел тулган көннәрдә мин ике асыл ярга саулык-сәламәтлек, шатлык-куанычлардан гына торган озын гомер, бетмәс-төкәнмәс гаилә бәхете һәрчак юлдаш булуын телим.**

**Милләтебезнең кадерлеләре, Айрат абый һәм Мәрьям ханым, тәүге туегыз шикелле үк, алтын туегыз да күңелләрегездә мәңге җуелмас якты хатирә булып калсын. Иншалла, шулай булыр да ул.**

*2001*

**РАЗИЛ ВӘЛИЕВ**

## Мәгънәле сүз моңлы, көйле була

*(Разил Вәлиев белән әңгәмә)*

**Разил Вәлиев. Татар халкының мактанычы һәм горурлыгы булган, милли рухлы, һәммә татарның күңел түрендә йөргән бөек шәхесләр бар. Шигъriяттә — Тукай, музыкада — Сәйдәш, җырда — Илһам, рәсем сәнгатендә — Урманче... Ә нәфис сүз сәнгатендә, һичшиксез, Айрат Арсланов! Татар шигъриятенең меңьеллык бай тарихы бар, әмма шигырь уку сәнгатенең үткәне, элекке осталары безгә анык билгеле түгел. Булгандыр, һичшиксез булгандыр алар... Бер очрашуда, Айрат абый, Сез гасыр башында яшәгән трагик актер Мохтар Мутинның гаҗәеп оста шигырь укучы, шигырь сөйләүче булганын әйткән идегез... Сүз сәнгатендә Сез дә буш урында барлыкка килмәгәнсездер, Сезнең дә Мохтар Мутин кебек элгәрләрегез, укытучыларыгыз булгандыр бит?..**

**Айрат Арсланов.** Рус сәнгатендә сәнгатьле уку Гоголь заманнарыннан башлана. Гогольнең шундый сүзләре дә бар: «Әле киләчәктә сәнгатьле укучылар спектакльләрне алмаштырыр».

Рус актеры Щепкин бу өлкәдә күп эшли. Әлеге сәнгатьне тудыруда Горбунов дигән актерны атарга була. Ә соңрак, совет чорындагы остазлардан — Закушняк. Ул интим хикәя кичәләре оештырган.

Ә безнең татар халкында сәнгатьле укуны безнең чор башларында туган сәнгать дип беләм мин. Әлбәттә, беренче чиратта бөек Тукаебыз исемен атарга кирәк. Тукай үзенең шигырьләрен бик матур укыган. Аның дусты Габдулла Кариев та шигырь укуны оста башкарган. Мин Әзәл Яһүдиннең истәлекләрендә укыган идем: «Мин бала вакытта безнең өйдә Габдулла Кариев язмасында Тукай әсәрләре бар иде», — дип искә ала ул. Моннан 20 ел элек Тукай башкаруында язылган пластинкалар булган дигән сүз ишеткән идем. Тукай Кариев белән бик дус булган бит. Әгәр дә Кариев язылган булса, әлбәттә, ул Тукайны да димләмичә калмагандыр бу эшкә. Шушы язмалар, пластинкалар табылса, безнең мәдәният өчен бик кыйммәтле байлык булыр иде. Әлбәттә, Габдулла Кариев та, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская да үзләренең труппалары белән бик күп йөргәннәр, спектакльләрдән гайре концертлар да биргәннәр һәм алар икесе дә сәнгатьле уку белән шөгыльләнгәннәр. Менә сез әйткән Мохтар Мутинга да килеп җиттек. Ул үзе Татарстанның Актаныш районы Такталачык авылында туган. Бәләбәйдә гимназия тәмамлагач, Уфада «Галия» мәдрәсәсе шәкертләрен һәм башка зыялы яшьләрне туплап, труппа оештырган, спектакльләр куйган. Шул вакытларда ук ул концертлар бирә торган булган. Концертларда Габдулла Тукай һәм Сәгыйть Рәмиев әсәрләрен һәм үзе уйнаган спектакльләрдән монологлар укыган.

**Р.В. Бөек затлар үзләре генә бөек булып калмыйча, талантлы яшьләрне әллә каян күреп алып, аларга канат куялар, ярдәм кулы сузалар. Әле яңа гына сәхнәгә чыга башлаган Айрат Арслановны Салих Сәйдәшев үзенең 50 яшьлек юбилей кичәсен алып барырга чакыра. Кичә тәмамлангач, иңнәреннән сөеп мактый, киләчәк иҗатына хәер-фатиха бирә. Сәйдәш фатихасын алу Сезнең өчен зур җаваплылык та, олы мәртәбә дә булгандыр бит, Айрат абый?**

**А.А.** Ул чакта мин радиода эшли идем. Үзегез беләсез, радиога эшкә бик иртә — сәгать алтыда торып барабыз, җидедә микрофонны ачабыз. Салих Сәйдәш бик иртә тора иде. Аның флигеле театр йорты янәшәсендә, һәр иртәдә капка төбендә очрашабыз: «Айрат, нихәл? Эшкә киләсеңме?» — дип сорый. Мин аның фатирына килеп йөрдем. Радиодан эш буенча җибәргәләделәр.

Салих абыйның өендә импровизацияләнгән концертлар була, анда артистлар күп килә иде. Шул концертларга ул мине алып керә иде. Мин керергә оялам, ләкин ул мине сөйрәп алып керә.

Беркөнне ул мине үзенә чакырды да: «Айрат, тиздән минем юбилей кичәсе була. Мин ул кичәне синең алып баруыңны сорыйм», — диде. Мин бераз каушап калдым. Чөнки мин 1949 елда гына театр мәктәбен тәмамлаган кеше, сәхнәдә әле бер концертта да катнашканым юк. Менә шундый бөек затның концертын алып барырга тиешмен. Мин әйтәм: «Салих абый, бик зур рәхмәт Сезгә. Ләкин мин бит әле куркып калдым». «Курыкма, барысы да яхшы булыр, сине ишеткәнем бар, Тукайны бик матур укыйсың. Концерт кичәсендә бер-ике шигырен дә укырсың», — дип күндерде Салих абый.

Шулай итеп, 1951 елның 10 гыйнварында хәзерге Кәрим Тинчурин театры бинасында (ул вакытта Академия театрыбыз иде) Салих Сәйдәшевнең бик зур юбилей кичәсе үтте. Аның концерт өлешен алып бару миңа насыйп булды. Концерт зур уңыш белән үтте. Анда бик зур актерларыбыз, җырчыларыбыз, музыкантларыбыз катнашты.

Әйе, Сез әйткәнчә, концерттан соң Салих Сәйдәшев, минем кулымны кысып, аркамнан сөеп: «Менә синең радиога гына түгел, татар эстрадасына да аяк басуың шушы көннән башлансын», — диде. Салих абыйның ул сүзләре минем хәтердә мәңгегә калды.

**Р.В. Сезнең яраткан шагыйрьләрегез күптер. Шулай да Сезгә татар теленең тәмен тоярга ярдәм итүчеләрнең иң беренчесе дип кайсы шагыйрьне саныйсыз?**

**А.А.** Мин, әлбәттә, яшьтән үк Тукайны укып, аның иҗатын яратып үстем. Минем әтием дә авыл зыялысы иде. Ул — авылда зоотехник булып эшләгән кеше. Без аның белән кичләрен рус һәм татар әдәбиятын укый идек: Тукайны, Такташны, Мәҗит Гафурины... Бу да яшьтән үк әдәбият белән кызыксынуга нипдидер этәргеч биргәндер. Аннан соң районда яшьләр арасында олимпиадаларны еш үткәрделәр. Ул вакытта безнең мәктәптә күпләр Һади Такташ иҗатына мөкиббән иде. Барысы да Такташны укыйлар. Мин дә, олимпиадаларда катнашып, призлар алганым хәтердә.

Ә нинди шагыйрь дип әйтсәгез, шагыйрьләр бик күп. Тукай китабы — минем көндәлек китабым. Күңелем төшсә дә мин кулыма Тукай әсәрләрен алам, ул һәрвакытта көч-дәрт өсти торган шагыйрь.

**Р.В. Концертлар һәм кичәләрдә, гадәттә, үзәк урында җыр була. Җыр арасындагы бушлыкны тутырыр өчен яисә җырны җырга ялгау, артистны ял иттереп алу өчен генә арага бию номерлары кертәләр, шигырь яисә мәзәк сөйлиләр. Мондый кичәләрдә сөйләнгән шигырьләр, гадәттә, бик тә урта кул була, шигырь сөйләүче ничек тә тамашачының күңелен күтәрергә, аны көлдерергә генә тырыша.**

**Айрат абый, Сез беренчеләрдән булып бу традицияне бозарга җөрьәт иттегез. Сез татар сүзенең, татар шигыренең бәясен күтәрдегез. Сез катнашкан кичәләрдә сүз һәрчак иң алгы урынга чыга... Билгеле, моның төп сәбәбе осталыктадыр... Әмма икенче бик зур сәбәп — тирән мәгънәле шигырьләр, әдәби әсәрләр сайлаудадыр... Чын шигырьне, чын әдәби әсәрне танырга, аңларга кемнәр өйрәтте Сезне?**

**А.А.** Элек безнең дәүләттә идеология дигән нәрсә бар иде. Идеясезлек булмасын, идея алгы планга күчсен дип өйрәтәләр иде.

**Р.В. Айрат абый, Сез бит татарча гына укымыйсыз. Тагын бер яктан уникаль шәхес Сез — ике телдә дә — русча да, татарча да укыйсыз. Андый кешеләр татарда башка бар микән әле ул?**

**А.А.** Мин өч мәртәбә Бөтенроссия конкурсларында катнаштым. Аның беренчесе 1957 елда Октябрьнең 40 еллыгына, икенчесе 1969 елда В.И.Ленинның 100 еллыгына багышланган иде. Мин аларның икесендә дә лауреат исеме алдым һәм Пушкинның 175 еллыгына багышланган конкурста катнаштым. Анда, Пушкинны саф татарча укып, өченче урынны алдым. Соңыннан миннән сорадылар: «Сез урысча укыйсызмы?» — дип. Мин лирикадан берничә әйбер укып күрсәттем.

Ә менә филармониядә эшләгәндә Маяковскийны бик яратып укый идем. Есениннан да программа эшләдем. Чеховның кыска хикәяләреннән программа төзеп укыганым булды. К.Симоновны, Д.Көгелтиневне, Р.Гамзатовны программага кертә идем.

*Время и деньги. — 2003. — 11 апреля.*

**СИБГАТ ХАКИМ**

## Владеющий искусством звучащего слова

Вечера мастеров художественного слова, посвященные творчеству Пушкина, Блока, Маяковского, Есенина, будь то во дворцах культуры Казани, или же в московских концертных залах, я не пропускал никогда. Слушал и мысленно опять возвращался к татарской поэзии — все ж велика наша поэзия! Поразительно своеобразные, большие таланты есть у нее, подобные Тукаю, Мусе Джалилю, Такташу, Хасану Туфану. Вот бы и их вывести в просторный, широкий мир! На мой взгляд, было бы непростительным грехом не познакомить с ними другие народы.

Человеком, взявшим на себя эту ответственную, благородную миссию, явился Айрат Арсланов, теперь уже признанный всеми народный артист Республики Татарстан и России, лауреат республиканской Государственной премии им. Г.Тукая. На наш взгляд, вступил он на сцену очень своевременно — в дни торжества народного духа после Великой Отечественной войны, когда «Маобитские тетради» Мусы Джалиля вдохнули в сердца новые силы и мощь. С тех пор он сорок лет в постоянном труде. В его репертуаре — «Поэт-герой Муса Джалиль», «Жизнь поэта» (Г.Тукай), «Татарская поэзия», «Родной край мой — Татарстан» и др. программы.

Айрат Гареевич Арсланов, лауреат нескольких Всероссийских конкурсов артистов-чтецов, является одним из популярнейших мастеров художественного слова на татарской эстраде. Уже несколько десятилетий его голос доносит до слушателей с эстрады, по радио и телевидению лучшие произведения татарских поэтов и писателей. С большим успехом пропагандирует артист татарскую литературу на русском языке не только в республике, но и далеко за ее пределами.

Айрат Арсланов отличается мастерским умением донести до требовательного, высококультурного слушателя образцы нашей поэзии.

Блистательно владеющий искусством звучащего слова, он заставляет слушателей жить чувствами героев исполняемых произведений, воспитывает в них высокое чувство прекрасного.

*1962*

**АЙРАТ АРСЛАНОВ**

## Сүз гаме

Сүз — кешеләр аралашуы өчен иң кирәкле чараларның берсе. Фикерне аңлаешлы, күңелдәге барлык хисләрне тәэсирле итеп әйтә алу — һәрбер культуралы кеше өчен зарури нәрсә; бигрәк тә сәхнә өлкәсендә эшләүчеләр өчен сүз белән сак эш итә белү аеруча әһәмияткә ия.

*«Сүз кешеләрнең тормыш тәҗрибәсен, сәнгатьле фикер йөртә белү осталыгын, эстетик тәрбиясен үзендә саклый,* — дип яза галимә Илидә Бәширова. — *Ул — буыннан буынга күчеп килә торган рухи байлык, үзе белән бик сак мөгамәләдә булуны ярата торган җанлы материал; рәсем, архитектура, музыка һ.б. сәнгать төрләре материалларыннан сүз нәкъ менә шул ягы белән аерыла».*

Казаныбызда һәм республикабызда бик күп сәнгать учаклары — театрлар, филармонияләр, концерт заллары эшләп тора. Әлбәттә, аларда бара торган спектакльләрдә, концерт программаларында драматург, сценарий авторлары үз әсәрләрендә төп фикерне сүз аркылы җиткерәләр. Димәк, сүз, аның белән сак мөгамәләдә булу сәхнә эшендә иң мөһим урынның берсен алып торуы бәхәссез. Табигый ки, тамашачылар бу өлкәдә эшләүчеләрнең уңышларын да, кимчелекле якларын да ишетеп, белеп торалар. Эстрада жанрында эшләүче артистларның репертуар сайлауда һәм башкару осталыгын күтәрүдә тиешенчә тырышлык күрсәтмәүләре күпләрнең эчен пошыра. Әмма ләкин концерт эшчәнлеге өлкәсендә күзгә бәрелеп торган җитешсезлекләрне бетерү буенча сәнгать белән җитәкчелек итүче оешмалар сүлпәнлек күрсәтәләр дию генә, минемчә, аз булыр кебек. Ә бит татар эстрадасында сүз сәнгате өлкәсендә эшләүчеләрнең 50—80 нче елларда ирешкән уңышлары барыбызның да хәтерендә әле. Ә бүгенге яшь буын тамашачылар, тыңлаучылар шул

елларда эстрададан, радио-телевидениедән еш яңгыраган күренекле әдипләр, шагыйрьләр әсәрләрен, аларны башкаручы артистларны, аларның иҗатларын яхшы беләләрме? Аларны гаепләп сүз әйтүе дә читен. 70 елга якын тарихы булган татар эстрада сәнгате турында, бу өлкәдә эшләгән йөзләрчә артистлар иҗатын яктырткан бер генә тупланма да дөнья күргәне юк. Профессиональ сүз сәнгатенең чишмә башында кемнәр торган соң, сәнгатебездә бу жанрның үсеш юллары нинди?

Эстрада сәнгатендә, белгәнебезчә, төрле жанрлар бар. Әлбәттә, анда музыка, җыр сәнгате халкыбыз тарафыннан яратып кабул ителә торган жанр санала. Сәнгатьле уку жанры да (аны дистәләгән еллар дәвамында «нәфис уку» төшенчәсе белән атап йөрттеләр) — эстрадада төп урыннарның берсен алып торучы, әйтергә кирәк, концерт программаларының төп фикерен аңлатучы, чыгыш ясаучы артистлар белән тамашачыны тыгыз бәйләнештә тотучы, тыңлаучыларга туган телебезнең моңын, ямен аңлатучы жанр ул. Бу жанрны җаны белән яратучы сәнгать әһеле телебезнең милли аһәңен халык күңеленә сеңдерә белүче, тыңлаучыларга туган телне куллланудан ямь һәм тәм табарга өйрәтүче, үзе укый торган әсәрне бөтен нечкәлекләре белән тасвирлап бирә белүче оста булырга тиеш. Димәк, бу жанрны тасвирлап бирә торган сүз сәнгате дип тә атап була торгандыр. Ә бит аңа шушы төшенчәне бөек язучыбыз, тел һәм әдәбият галиме Галимҗан Ибраһимов үзе биргән. Г.Ибраһимов зур мөгаллим дә булган. Аның «Әдәбият дәресләре» дигән хезмәтеннән тыш 1919 елда Казанда басылган «Татар телен ничек укытырга?» исемле китабы да бар. Шул китапның «Тасвири уку (сәнгатьле уку)» дигән бүлегендә түбәндәгеләр бәян ителә: *«Безнең мәктәпләрдә һич әһәмият бирелмәгән эшләрдән берсе «тасвири уку»дыр. Тасвири уку дип хәл вә мәгънәнең эчке хосусиятләре теләвенчә тавышны үзгәртеп укуга әйтәләр. Тавыш белән мәгънә арасында нечкә аһәң бар. Талантлы артистларның сәхнәдәге хәлләре мондый сөйләү төрләренең җыелганына ачык мисал була алыр.*

*Җанлы уку — тасвири уку. Монда укылган әсәрдәге хис-кайгымы, көенеч вә шатлыкмы, башкамы — укучының йөрәгенә керә, йөрәгеннән тавышына килә, аның тавышы күз яшьсез елый, кылычсыз кисә. Икенче төрле әйткәндә, тасвири уку әсәрдән алынган тәэсирнең тавыш белән бирелүе димәктер. Әлбәттә, аңа талант һәм хәзерләнү шарт».* Г.Ибраһимов китабыннан алынган бу цитатадан күренгәнчә, язучы һәм олы педагог кешене мәктәп елларыннан ук сәнгатьле (тасвири) укуның нечкәлекләренә өйрәтүнең әһәмиятен ачып бирә. Аның бу хезмәтен сәхнәдә сүз сәнгате өлкәсендә эшләүче артистларга да укып чыгу һич тә зыян итмәс иде. Шәхсән минем үземә «нәфис сүз сәнгате» төшенчәсенә караганда «тасвири сүз сәнгате» күбрәк ошый төшә. Әмма ул «нәфис сүз», «нәфис сүз остасы» төшенчәсе буларак куллануга кергән инде. Сәнгатьле уку әдәби әсәрне тирәннән аңлауга һәм якыннан тоюга нигезләнә. Укырга керешкәнче, башта әсәр яхшылап өйрәнелергә, анда сүзнең нәрсә турында барганлыгын, әсәрдәге образларның һәм аларның фикерләренең нинди әһәмияткә ия булганлыгын, нинди мәгънә һәм төсмерләрдә бирелгәнлеген яхшылап үзләштерергә кирәк.

Бу яктан караганда, сүз сәнгате жанрында эшләү, уку өчен аерым әсәрләрне сайлап алу, алардагы вакыйгаларны, образларны билгеләп, аларны тыңлаучыга тулы канлы итеп җиткерү эше драма артистларының спектакльдәге аерым образлар өстендә эшләү белән тәңгәл килә.

Фикеребезне гомумиләштеребрәк әйтсәк, сәхнә ул милли әдәбиятыбызны киң катлау тыңлаучылар арасында актив пропагандалауда зур көч булырга тиеш. Ә бүгенге эстрадада башкарыла торган авторларның исемнәрен саный башласаң, бернничә дистә тирәсендә тукталып каласың, күп очракта башкаручыларның үзләре язган, әгәр шулай әйтергә яраса, әдәби яктан «пешеп» тә җитмәгән юмористик әсәрләр авторлары. Татар әдәбиятын бөтен татар галәменә һәм башка халыкларга киң таныткан талантлы язучыларыбыз һәм шагыйрьләребезнең югары зәвыклы әсәрләре бүгенге эстрадабыз сәхнәсеннән ни өчен читләштерелде һәм сүз сәнгатендә эшләүче артистларның репертуарлары, халык теле белән әйткәндә, тузга язмаган, әдәпсез, «чиле-пешле» әсәрләр, мәзәкләр белән тулды? Әлбәттә, моның төп сәбәбе бүгенге көндә сәнгатебездә репертуар сайлауда иреклелек һәм, иң мөһиме, сәнгать оешмалары белән җитәкчелекнең йомшак булуы.

Татар эстрадасының үткәненә әйләнеп карасак, сүз сәнгате жанрының да үз тарихы бар, үз башкаручылары, үз авторлары бар иде.

1950—1980 еллар эстрадасына күз салсак, без чын эстетик ләззәт бирә торган әсәрләр башкарылганлыгын күрербез. Бу әсәрләрнең авторлары беренче нәүбәттә Г.Тукай, Һ.Такташ, Г.Кутуй, Дәрдмәнд, С.Рәмиев, Ш.Бабич иде. Без үзләре белән аралашып яшәгән әдипләребез һәм шагыйрьләребез Х.Туфан, Н.Исәнбәт, Ә.Фәйзи, Ә.Исхак, С.Хәким, Ә.Давыдов, И.Юзеев, Н.Арслан, Ш.Галиев, Р.Фәйзуллин, күренекле язучыларыбыз Г.Бәширов, Ә.Еники, Ф.Хөсни, М.Әмир, М.Мәһдиев һ.б. иде. Әлбәттә, шушындый каләм осталарының әсәрләре зур уңыш белән башкарыла иде, тамашачылар аларны яратып тыңлыйлар, авторларга һәм башкаручыларга тирән рәхмәтләрен әйтәләр иде. Ни өчен яраталар иде дигән сорау куелса, беренче чиратта бу югарыда телгә алынган авторларның халыкчан тел белән язуларында дип кистереп әйтәсе килә.

Бу урында мәшһүр язучыбыз Г.Бәшировтан да бер цитата китереп үтү урынлы булыр дип уйлыйм: *«Халыкның иң зур байлыгы, иң кадерле рухи хәзинәсе, һичшиксез, аның теле. Халык үзенең телен, оста бакчачы кебек, яман җилләрдән, рәхимсез салкыннар куырудан саклап, мең еллар буена үстереп килгән, аны өзлексез баетып, матурлап, иң тирән фикерләрен, иң нечкә хисләрен дә аңлатып бирер дәрәҗәгә җиткергән».*

Бу кыска гына цитатада күпме мәгънә, фикер чагылган. Язучы күрсәткән шушы гаҗәеп хәзинәне кулланганда язучының да, һәм әсәрләрне башкаручы сүз остасының да битарафлыгы, салкын кан белән эш кылуы һич тә мөмкин булмаган хәл бит ул.

Татар сәхнәсендә сүз жанрын үстерүдә һәркайсы аерым хөрмәткә лаеклы, шактый зур хезмәт күрсәткән шәхесләрнең исемнәрен санап китсәк, беренче чиратта татар театры сәхнәсе осталары Г.Кариев, С.Гыйззәтуллина-Волжская, М.Мутин, Х.Сәлимҗанов, Г.Шамуков, Ш.Сарымсаков, Г.Ибраһимова һ.б.ны атап үтәр идек. Татар дәүләт филармониясе артистлары Ф.Йосыпов, Ә.Яһүдин дә татар совет эстрадасында сүз жанрында башлап йөрүчеләр булды. Әлбәттә, «Сәйяр» һәм «Нур» театр труппалары спектакльләр белән гастрольләрдә булганда, концерт программалары да әзерли торган булганнар, ул программаларга җыр, музыка, спектакльләрдән өзекләр белән бергә шагыйрьләр һәм язучыларның әсәрләрен уку да кертелгән. Труппа җитәкчеләре Габдулла Кариев һәм Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская Г.Тукай, С.Рәмиев һ.б. шагыйрьләрнең әсәрләрен яратып башкарганнар.

Г.Кариев белән Орскида беренче очрашуы турында Татарстанның халык артисты Х.Сәлимҗанов сөйли торган иде: *«Үз гомеремдә мин бик күп талантлы артистлар күрдем. Әмма шуңа да карамастан Г.Кариевка көндәш булырлык талант ияләрен очратмадым. Аның иҗатына якын килгән бер генә артист — Мифтах Әпсәләмов кына булды.*

*Г.Кариев гөрләп торган матур баритон тавышка ия иде. Озын буйлы, таза гәүдәле бик сөйкемле кеше иде ул. Гаять мөлаем күзле һәм шул ук вакытта чиксез зур темпераментлы, җитез хәрәкәтле иде...»*

Ф.Бурнаш сүзләре белән әйтсәк, *«менә шундый булган ул «Сәйяр»нең мәгънәви әткәсе — даһи Кари Габдулласы»*. Һәм, әлбәттә, Г.Кариев профессиональ сәхнәдә сәнгатьле уку белән чыккан беренче зур артист булган дип әйтергә тулы хакыбыз бар.

*«Миндә Г.Кариев тавышы язылган граммофон пластинкасы бар. Мин аны 1955 елда Новосибирскида яшәүче бер татар картыннан сорап алган идем,* — дип сөйләгән иде нәфис сүз остасы Әзәл ага Яһүдин. — *Ярылган, кыршылып беткән бу пластинкада Кариев Тукайның «Теләнче» шигырен башкара. Бу пластинкага карап хөкем итсәң, ул, билгеле, бүгенге таләптән чыгып караганда шактый түбән сыйфатлы, уңай тәэсир дә калдырмый...»*

Шунысын да искә алырга кирәк: ул пластинка революциягә кадәр язылган бит, ул вакыттагы пластинкаларның сыйфаты нинди дәрәҗәдә булганлыгын һәм еллар үтү белән тузып бетүен искә алсак, мәсьәлә ачыклана булса кирәк.

Ә.Яһүдингә шул ук Новосибирскида икенче бер өлкән яшьтәге тамашачы кызыклы бер истәлек сөйли. Габдулла Кариев сәхнәдә грим белән теләнче киемендә Г.Тукайның «Теләнче» шигырен башкара. Кул чабу булганмы-юкмы, ә менә шул шигырьне башкаргач, залдан бер адәм, сәхнәгә күтәрелеп, «теләнче» Кариевка садака суза. Бу инде күп нәрсә турында сөйли. Димәк, Г.Кариев бу әсәрне халыкны ышандырырлык итеп, чын теләнчене күз алдына бастыра алырлык итеп башкарган дигән сүз бит.

Г.Кариев Тукайның якын дусты була, алар әле Җаек шәһәрендә укыган елларында дуслашалар. Казанга килгәч, Тукай «Сәйяр» труппасы эше белән бик кызыксына, алар белән дуслаша, труппага һәрьяклап булышлык күрсәтергә тырыша, театрга багышланган шигырьләрен һәм мәкаләләрен яза.

Г.Тукай заманында үзе дә халык алдында әсәрләрен еш укый, аның укуын яраталар. Әлбәттә, Тукай белән якыннан аралашкан Г.Кариев шагыйрьнең күп шигырьләрен укыгандыр, әмма бу турыда, кызганычка каршы, язма истәлекләр сакланмаган.

Г.Тукайның да үз әсәрләрен укуын граммофон тәлинкәсенә язганнар дигән сүзләр дә йөргән иде үз вакытында. Кариев үзе язылгач, Тукайның да тавышы язмада калсын дип кайгыртканнар дигән уй да килә башка. Кызганыч, Тукай тавышы язылган пластинканың әлегә табылганы юк, табылган очракта ул Г.Тукай музееның иң кыйммәтле экспонаты булыр иде.

Менә шулай, әле Октябрь революциясенә кадәр сәнгатьле уку чаткыларын тамашачыларга җиткерү, халыкның бу сәнгать жанрына мәхәббәтен уяту эшен безнең бөек сәхнә осталарыбыз белән мәшһүр шагыйрьләребез башлап җибәргәннәр.

Сүз жанрының үсүе, аның белән сәнгать әһелләренең ныклабрак кызыксына башлавы Октябрь революциясеннән соң театр сәнгатебез ныклап аякка баскан, Казанда мәдәният йорты ачылып, анда концерт программаларында шагыйрьләр, артистлар актив катнаша башлаган елларга туры килә.

Әле революциягә кадәр татар сәхнәсендә эстрада жанрын үстерүгә хезмәт куйган артистлар булганын беләбез. Татарның аерым җырчылары ил буйлап гастрольләрдә йөргән. Шулардан тамашачылар яраткан җырчылар Фәттах Латыйпов, Камил Мотыйгый, Газиз Әлмөхәммәдов һ.б. артист-музыкантларны күрсәтеп үтәсе килә. Алар белән нәфис сүз жанрында эшләүчеләр булганмы? Әлбәттә, булгандыр дип фаразлыйсы килә. Чөнки җырчыларның үзләренә генә концерт программаларын тулысы белән башкарып чыгу сүз жанрыннан башка авырга туры килер иде. Әмма ул башкаручыларның исемнәре безнең өчен нәмәгълүм: истәлекләрне табасы иде.

Гражданнар сугышы елларында беренче фронт бригадалары барлыкка килә. Без ул елларда фронт бригадалары составында татар театрының күренекле драма артистлары булганлыгын төрле истәлекләрдән укып беләбез. Бу артистлар арасында декламаторлар булганмы? Әлбәттә, булган, диясе килә. Чөнки ул ел-

лардагы урыс фронт бригадаларында менә дигән сәнгатьле укучы артистлар булган, һәм алар өчен махсус сценарийлар язучы авторлар — шагыйрьләр булган. Ә татар артистлары — декламаторлар — нинди әсәрләр укыганнар һәм кемнәр алар? Моны да ачыклыйсы бар әле.

20 нче еллардан соң юмор-сатира әсәрләре белән сәхнәгә Мәхмүд Бөдәйли күтәрелә. Аның сәнгатьле укуын ишеткән кешеләрнең берсе — нәфис сүз остасы Әзәл ага Яһүдиннең болай сөйләгәне бар: *«Мәхмүд ага сәхнәдә үзен гаҗәеп иркен тота иде, ул вакыттагы тамашачылар аның чыгышларын бик яратып каршы ала иде. 1928 елда Татар мәдәнияте йортындагы концертта аның пролетар шагыйрь битлеген киеп йөргән эшлексез бәндәләрдән көлеп язган әсәрне зур уңыш белән укуы исемдә калган».*

Шәхсән минем үземнең дә 50 нче еллар азагында сөргеннән кайткан Мәхмүд ага Бөдәйли белән Тукай клубында берничә мәртәбә очрашуым исемдә. Бик үткен сүзле, юморга ифрат бай, әдәбиятны һәм сәнгатьне яратучы шәхес буларак күңелемдә саклана. Димәк, Мәхмүд ага татар эстрада сәнгатендә юмор-сатира кебек авыр жанрны башлап җибәрүчеләрнең берсе булган.

Татар сәнгатендә нәфис уку жанрын үстерүдә драма театры артистларының зур урын тотканлыгы турында әйтеп узган идек инде. 20 нче еллар башында иҗат итә башлаган сәхнә осталарыннан сүз жанры белән ныклап кызыксынган шәхесләрдән кемне күрсәтеп була? Әлбәттә, күренекле актер Мохтар Мутинны. Шәриф Рахманкуловның Мохтар Мутин иҗаты турында язган монографик очеркында түбәндәгеләр язылган: *«Әле Казанга килгәнче, Себер якларыннан гастрольләрдән кайткач, М.Мутин җырчы Фәттах Латыйпов белән берлектә махсус концерт программасы әзерли. Бу программада Мутин беренче булып татар поэзиясенең ялкынлы сүзләрен сәхнәгә алып менә. Ул Г.Тукай, С.Рәмиев шигырьләрен һәм Шекспир, Шиллер әсәрләрендәге геройларның романтик рухтагы монологларын татар телендә башкара.*

*Гомумән, М.Мутин — сәхнәгә татар поэзиясен алып менүче беренче нәфис сүз остасы, татар поэзиясенең беренче пропагандисты».*

Әйе, М.Мутин белемле (беренче буын татар артистлары арасында гимназия белеме алган кеше), киң эрудицияле артист була. Сәхнәдәшләре арасында ул урыс һәм Аурупа театрларының тарихы, мәшһүр сәхнә осталарының уен алымнары, иҗат юллары белән яхшы таныш булуы белән аерылып торган. Татар театры сәхнәсендә М.Мутин тудырган образлар бихисап. Ул татар, урыс, Көнбатыш классик драматурглары әсәрләрендә берничә дистә менә дигән образлар иҗат иткән зур сәхнә остасы була. Аның иҗат диапазонының киңлегенә сокланмыйча мөмкин түгел!

Мохтар Мутин татар сәхнәсенең трагик амплуадагы артисты була. Шушы амплуа аңа мәшһүрлек китерә. Шекспир, Шиллер, Гейне кебек дөнья драматургиясенең классиклары әсәрләренең татар театры сәхнәсендә уйналулары М.Мутин исеменә бәйләнгән. Чөнки ул әсәрләр аның инициативасы белән тәрҗемә ителгән, аның режиссерлыгында куелган һәм аның тарафыннан баш рольләр башкарылган. Татар сәхнәсендә 15 ел буе М.Мутин башкарып килгән Отелло образы өлкән яшьтәге тамашачыларның күңелендә әле дә саклана. М.Мутинның олы таланты алдында баш иючеләрнең берсе мәшһүр шагыйребез Хәсән Туфан була.

Ул көннәрне карлар күмгән инде.
Шулай да ул әле хәзер дә
Мутин түгел, ә Отелло булып,
Гамлет булып яши хәтердә, —

дип яза ул.

М.Мутин дөнья әдәбияты әсәрләре белән яшьтән үк, әле Казанга килгәнче үк яхшы таныш була. Ул Себер якларында булган гастрольләре вакытында татар тамашачылары белән генә чикләнми, урыс сәхнәләре өчен махсус әдәби кичә программасы да әзерли. Урыс тамашачылары өчен бирелгән кичәләрдә шагыйрьләр А.Апухтин, Н.Корецкий әсәрләрен укый. Шулай ук Мутин репертуарында урыс телендә әзерләнгән Шекспир, Гауптман, Шиллер, Ибсен геройларының монологлары була.

Татар сәхнә сәнгатенә нигез салучыларның берсе булган һәм шулай ук нәфис уку жанрын үстерүгә дә зур өлеш керткән М.Мутинның эшчәнлеге олы хөрмәткә лаек. Бу гүзәл актерны үз күзләре белән күргән һәм ишеткән кешеләр аның турында зур соклану хисләре белән сөйлиләр. Ул елларда радиода яшь диктор булып эшләгән, бүгенге көндә мөхтәрәм сәнгать белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Зәйнәп Шәйхулла кызы Хәйруллина искә ала: *«Артист М.Мутинның радиодагы хезмәтен шулай ук аерым билгеләп үтәсе килә. Ул бигрәк тә шагыйрь Сирин әсәрләрен укырга ярата иде. Күрәсең, Сирин шигырьләренең гаҗәеп яңгырашы, ритмик дулкыны аны аеруча җәлеп иткәндер. Мохтар Мутин шулай ук радиода куелган спектакльләрдә истә кала торган рольләр башкара торган иде».*

Әзәл ага Яһүдин дә М.Мутинны бик олылап искә ала, аның иҗатына соклану белдерә иде: *«Кайбер шигырьләр әйтерсең аерым артист өчен генә язылган була һәм аның башкаруында гына яңгырый. Сириннең «Булмый! Булмый!» шигырен укырга чыккан мәһабәт гәүдәле, көр тавышлы Мохтар ага сәхнәгә чыгып «Ашлыгыңны җилгәрәмсең, җилгәр, җилгәр!» дип гөрләтеп бер аваз салуы була, зал алкышларга күмелә иде. Аннан соң бүтән артист авызыннан бу шигырьне мин ишетмәдем дә».*

Шунысы кызганыч: татар сәнгатенең кабатланмас шәхесе Мохтар Исхак улы Мутин 1938 елда репрессия корбаны була, һәм 1941 елның 9 июлендә Колымада аның гомере өзелә.

20 нче еллар башында Казанда Островский урамындагы 10/4 нче йортта (хәзерге Яшь тамашачылар театры бинасы) Мәдәният йорты эшли башлый. Ул чын-чынлап әдәбиятта һәм сәнгатьтә иҗат итүче яшь көчләрнең яраткан йорты булып әверелә. Анда концертлар, әдәби кичәләр, диспутлар үткәрелә. Халык алдында яшь җырчылар, музыкантлар, язучылар, шулай ук нәфис сүз өлкәсендә эшләүче артистлар чыгыш ясый...

Концертларда тамашачылар яраткан җырчылар һәм музыкантлар белән бергә талантлы яшь композитор Салих Сәйдәшев тә үзенең оркестры белән еш катнаша.

Мәдәният йорты сәхнәсеннән ул вакыттагы күренекле шагыйрьләребез үз әсәрләрен укыйлар, драма театры артистлары сәнгатьле уку өлкәсендә уңышлы эшләре белән таныштыралар. Димәк, ул елларда нәфис сүз, сәнгатьле уку жанры музыка белән беррәттән тыңлаучыларның яраткан сәнгать төренә әверелә бара. Мәдәният йортында булган кызыклы очрашулар, концертлар турында өлкән яшьтәге сәнгатькәрләребездән ишеткәли идек, кызганыч, аларның күбесе безнең арабызда юк инде. Ул еллардагы Мәдәният йортының мохитен күз алдына бастыру нияте белән мин күренекле композиторыбыз Җәүдәт ага Фәйзинең истәлекләреннән өзек китерәм:

*«Казанга килгәч, беренче мәртәбә Мәдәният йортына бардым. Эченә керү белән бертөрле уңайлылык, рәхәтлек сизәсең. Халык күп. Күбесе яшьләр. Заманча матур киенгәннәр, тирә-якта тантаналы күтәренкелек хөкем сөрә. Бүген монда зур әдәби-музыкаль кичә булачак. Эре-эре хәрефләр белән язылган исемнәр. Кичә башланды. Сәхнәгә берәм-берәм язучылар, җырчылар чыга. Менә Гадел Кутуй чыкты. Ул үзенең дәртле шигырьләрен бик оста укыды.*

*— Һади Такташ! — дигән исемне ишеткәч, бөтен зал гөр килеп кул чабуларга күмелде. Маңгаена төшкән куе чәчләрен артка сыпыра-сыпыра, шагыйрь килеп чыкты. Аның теле йомшак, башкаларга караганда үзгәрәк. Ул үзенең яңа әсәрләреннән «Урман», «Провокатор» һәм «Никахсызлар» исемле бик җитди әсәрләрен артистларча түгел, әллә ничек үзенә генә хас осталык белән укыды. Аннан соң башкалар да чыгыш ясадылар, хикәя, шигырьләр сөйләделәр. Күбесе үз әсәрләрен яхшылап укый белми икән. Кичәне алып баручы театр техникумы студенты Хәким Сәлимҗанов: «Үз оркестры белән Салих Сәйдәшев!» — дигәч, зал гөрләп кул чапты».*

Җәүдәт Фәйзи юридик факультетта укыган елларында профкомга сайлана һәм культсектор белән җитәкчелек итә. Университетның актлар залында кичәләр, концертлар еш оештырыла. Кичәләрдә Һади Такташ, Гадел Кутуй, Хәсән Туфан кебек танылган шагыйрьләр һәм Хәким Сәлимҗанов, Сәет Булатов кебек артистларның чыгышлары зур уңыш белән үтә торган була. *«Һ. Такташ әдәби-музыкаль кичәләрдә күп әсәрләрен укый иде,* — дип искә ала Җ.Фәйзи, — *«Мокамай»ны да, «Алсу»ны да, «Байрак тегәбез»не дә. Халык соравы буенча «Мәхәббәт тәүбәсе» поэмасын да укырга туры килә иде аңа. Гаҗәеп матур укый иде ул үз әсәрләрен. Сокланып тыңлыйсың. Йомшак тавышы, урынлы кул хәрәкәтләре, ясалма пафосның булмавы, төп фикерне басымлап әйтүе тыңлаучыларга ифрат зур поэтик тәэсир ясыйлар иде».*

Һ.Такташның талантлы шагыйрь һәм оста укучы булуы ул елларда яшь драма актерларына сәхнәдә сәнгатьле уку жанрын үстерү өчен нык этәргеч булгандыр дигән уйга китерә. Драма актерлары һәм студентлар арасында Һ.Такташ һәм башка шагыйрьләр әсәрләрен күбрәк укый башлыйлар. Чыннан да, Такташ ул чорның бөек шагыйре генә түгел, зур трибун шагыйрь була. Ул елларда әдәбият һәм сәнгать даирәләрендә юкка гына Такташны үз әсәрләрен ифрат оста укучы В.Маяковский белән чагыштырмаганнардыр. Үз заманында Такташның сәхнәдә шигырьләрен ничек башкаруы хакында замандашлары, дуслары тарафыннан күп язылган. Ул искә алуларның барысында да «Юк, Такташ шигырьне укымый, нәфис уку осталыгының бөтен шартын китереп башкара иде» дигән фикер ярылып ята. Замандашыбыз — күренекле галим, химия фәннәре докторы Гыйлем Камай — Такташ белән дуслыгын, аның әдәби концертларында еш булуы турында сөйли торган иде. *«Мин бүгенге көнгә чаклы Такташ әсәрләрен шагыйрьнең үзе кебек оста башкаручыны ишеткәнем юк әле»,* — дия торган иде Гыйлем ага.

Күренекле нәфис сүз остасы Әзәл ага Яһүдин дә Такташ турында сүз чыкканда: *«Мин дә бу бөек шагыйрьне тыңлау бәхетенә ирешкән кеше бит. Аның бөтен торышы, кыяфәте, гәүдәсе, киеме, тавышы, хәтта мишәр акценты да «Мокамай»ны яки башка әсәрләрен уку өчен билгеләнгән диярсең. Берәр детальне генә алып кара, ул инде Такташ булмас шикелле иде»,* — дия торган иде.

Һ.Такташның татар әдәби тормышында тоткан урыны, аның башкару осталыгының югары кимәле турында җентеклəбрәк тукталуыбызның сәбәбе нәрсәдә соң? Такташ иҗаты 30 нчы елларда профессиональ сәхнәдә дә, шулай ук үзешчән сәнгатьтә дә нәфис сүз жанры белән ныклабрак кызыксыну уята дигән фикерне ассызыклап әйтәсе килә.

1926 ел. Татар театр техникумын тәмамлаган яшь артистлар театрда эшләү белән бергә нәфис сүз өлкәсендә дә уңышлы эшләрен күрсәтә башлыйлар. Болар Хәким Сәлимҗанов, Зариф Закиров, Галимә Ибраһимова һ.б.

З.Закиров Такташның юморын укый; өлкән артистларыбыз Зариф аганың ул елларда Г.Кутуй әсәрләреннән «Портфель», «Пычкы җыры»н һ.б. әсәрләрен шактый уңышлы башкаруын сөйли торганнар иде.

Театрда эшләгәндә Вәлишин дигән талантлы комик артист булган, ул концертларда да уңышлы чыгышлар ясаган дигән сүзләр ишеткәли идек. Әмма театр тарихында, китапларда бу артистның исеме телгә алынмый. Нинди артист булган ул, кайсы авторларның әсәрләрен башкарган, хәзергәчә мәгълүм түгел.

Артистларыбыз арасында Хәким Йосыф улы Сәлимҗанов — театр һәм эстрада тарихына шәп драма артисты, нәфис уку жанрында гомеренең соңгы елларына кадәр уңышлы эшләп килгән зур оста булып кереп калган талантлы шәхесебез. Хәким Сәлимҗанов заманында сәнгать дөньясына М.Фәйзи кебек олы драматургны, Галиябану образын беренче тудырган сәхнә йолдызы Б.Йосыпова, күренекле артист М.Әпсәләмов, театрыбызның күренекле артисты Г.Нигъмәтуллина, мәшһүр композиторыбыз З.Хәбибуллиннарны биргән Орск шәһәрендә туа. Ул шәһәрдә бөек артистыбыз һәм режиссер Габдулла Кариев та эшләп китә.

Яшь Хәким шәһәрдә эшләүче драма түгәрәкләрендә катнаша, бик яшьли әдәби әсәрләр укый. Театр дөньясы белән кызыксынуда Хәкимгә аның яраткан артисты Мифтах Әпсәләмовның йогынтысы зур була. Шул ук артист аны Казанга алып килә, күп очракларда Хәкимгә зур ярдәм итә, театр техникумында укырга киңәш бирә.

Хәким Сәлимҗанов, укуын тәмамлагач, гомере буе Татар академия театрында эшли. Артистлык хезмәтеннән тыш спектакльләр куя, пьесалар тәрҗемә итә, әсәрләр сәхнәләштерә. Татар театрының танылган артисты һәм эстрадада күренекле нәфис сүз остасы булып җитлегә.

50 нче елларда эстрадада эшли башлаган сүз сәнгатендә хезмәт итүче артистлар өчен Хәким аганың зур иҗаты якты үрнәк булып тора. Шәхсән минем үземне Хәким ага сәнгать мәктәбендә укытмаса да, мин аны үземнең укытучым дип исәплим. Татарстан радиосында аның режиссерлыгында күп спектакль һәм композицияләрдә катнашу, театрда бергә уйнау, күп концертларда бергә катнашу бу зур сәхнә остасының эш алымнарын үзләштерүдә, сәнгатьле уку жанрының нечкәлекләренә төшенүдә, әлбәттә, зур ярдәм иттеләр.

Хәким ага заманында Такташ белән дус була, театр сәхнәсендә аның «Камил» исемле драмасын куя һәм, әлбәттә, шагыйрьнең күп әсәрләрен, шул исәптән нәни шаяруларын гомере буена репертуарыннан төшерми. Аның репертуарында шулай ук Г.Тукай, Ә.Фәйзи, Ф.Әмирхан, Г.Кутуй һ.б. язучыларыбызның әсәрләре зур урын алып тора иде.

Өлкән яшьтәге тамашачылар Х.Сәлимҗанов башкаруында «Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш», «Ысулы кадимче», «Киләчәккә хатлар», «Гасырлар һәм минутлар» кебек күркәм шигъри әсәрләрне, әлбәттә, хәтерлиләрдер.

Х.Сәлимҗановның радиода бара торган программаларында сәнгатьле сүз белән Татар академия театрының күренекле артистлары Г.Ибраһимова, И.Гафуров, Р.Җиһаншиналар актив катнашалар иде. Гомумән, 30 нчы еллардан 80 нче елларга кадәр вакыт татар сәхнәсендә нәфис сүз сәнгатенең ныгып урнашу, камилләшү һәм җитлегү чоры булды, дип горурланып әйтергә була. Казанда 1937 елда Дәүләт филармониясе ачылу республикабызның мәдәни тормышында зур вакыйга була. Эстрада сәнгатенең төрле жанрларында эшләүче тәҗрибәсе булган сәләтле башкаручыларга ихтыяҗ арта. Концерт бригадалары оештырылып, гастрольләр башлангач, әлбәттә инде, сүз жанрында эшләүче кадрлар кирәклеге көн тәртибенә баса.

Шул еллардан нәфис сүз буенча артист Фәйзи Йосыпов Татар дәүләт филармониясенең төп көчләреннән берсе булып китә, бу эшкә ул бөтен гомерен багышлый һәм хаклы рәвештә татар эстрадасында сүз жанрын үстерүдә күп көч куйган сәхнә остасы булып санала. Татар дәүләт филармониясендә 50 нче еллардан бирле лаеклы ялга киткәнче эшләгән нәфис сүз остасы, Татарстанның атказанган артисты Әзәл Яһүдин язмаларына мөрәҗәгать итик: *«Сугыш еллары... Бик күп госпитальләрдәге концертлар... Мин, Татар дәүләт академия театры артисты һәм хәрби шефлык комиссиясе рәисе буларак, артистларны мөмкин кадәр концертларга катнаштырырга тырыштым. Сәет Булатов, Луиза Салиәскәрова, Хәким Сәлимҗанов, Шириягдан Сарымсаков, Галимә Ибраһимова, Рәшидә Җиһаншина һәм башка артистлар нәфис сүз белән уңышлы чыгыш ясыйлар. Минем үземә дә бу жанрда еш чыгарга туры килә. Дөрес, мин сәнгатьле сүз белән 1930 елдан бирле мавыгам. Әстерхан театрында да, Татар дәүләт академия театрында да һәрбер концертта мин сәнгатьле уку белән катнашам. Ниһаять, бу нәфис сүз эшенә булган мәхәббәт үскәннән-үсә барып, ахырда 1950 елда Татар дәүләт филармониясендә нәфис сүз буенча эшли башлавым белән тәмамланды».*

Әзәл Бәдретдин улы Яһүдин 1930 елда Әстерхан татар театрында эшли башлый. 1933—1934 елларда Казанга килеп Татар яшьләр театрында эшен дәвам иттерә, 1935 елдан 1950 елга кадәр Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшли. Бу елларда ул театрда матур-матур сәхнә образлары иҗат итә. Сүз сәнгатен ихластан яратуы Ә.Яһүдинне 1950 елда Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенә эшкә китерә. Ул биредә пенсия яшенә җиткәнче хезмәт итә, күп эстрада бригадаларында нәфис сүз остасы һәм конферансье булып эшли. Аның иҗатының күп өлеше татар халкының бөек җырчысы Рәшит Ваһаповның концерт бригадаларында үтә. Алар Советлар Союзының татарлар яши торган бик күп төбәкләрендә булып, меңләгән концертлар бирә.

Әзәл ага белән татар эстрадасында сүз сәнгатенең башлану еллары, бу жанрның үсүе турында еш кына сөйләшә торган идек. Ул, сүз сәнгатен ихлас яратучы сәнгатькәр буларак, бу жанрга кагылышлы булган

күп материалларны җыйный барган, үзенең дә кызыклы гына язмалары республикабыз вакытлы матбугатында күренгәләп торды. Ул язмаларында артист татар эстрадасында үзе белән бергә эшләгән коллегалары турында, эстрада сәнгатебездә булган уңышларга куанып, кимчелекләргә көенеп, үз мөнәсәбәтен белдерә иде. Әлбәттә, аның язмаларында төп урынны үзенең профессиясе итеп сайлаган сүз сәнгате, бу жанрның үсеше, репертуар мәсьәләсе, язучылар һәм шагыйрьләр белән иҗади дуслыкта торып эшләү, бу дуслыкның сәхнә уңышларына китерүе турындагы фикерләр алып тора иде.

Әзәл ага үз иҗатында төп игътибарны репертуар байлыгын арттыруга юнәлтә иде. Бу мәсьәләдә ул репертуарларында еллар дәвамында берничә генә әсәр башкарып, эшләреннән канәгать булып йөрүче кайбер башкаручылардан, әлбәттә, бик нык аерылып тора иде.

Әзәл Яһүдиннең репертуарында Г.Тукайның лирик һәм сатира әсәрләре дә, аның «Шүрәле»се дә, Һ.Такташның «Мокамай» һәм «Мәхәббәт тәүбәсе» дә, М.Җәлилнең «Моабит дәфтәре»ннән шигырьләре дә, Ә.Фәйзинең «Гармун»ы, Н.Исәнбәтнең «Татарстан сәламе» һәм «Әптери абзый әкияте» дә, Ш.Маннур һәм Ә.Давыдов әсәрләре дә киң урын алып тора иде.

*«Көлке капчыгының иң зурысы — Гамил Афзал кулында,* — дия торган иде Әзәл ага, — *кайсы гына әсәрен алма, барысы да нәкъ безгә атап язылган кебек. Аның «Күрде безнең башлар» шигырен мин сөйләп туя алмыйм, тыңлаучылар тыңлап туя алмый иде».* Х.Туфан иҗаты белән Әзәл ага яшьли таныша башлый. *«Мин Туфан иҗатына 20 нче елларның уртасыннан ук гашыйк. Аның «Соңгы мамонт» поэмасыннан «Башлана башланды» өзеге инде ул елларда ук күңелгә кереп урнашкан иде,* — дип искә ала артист. — *Хәсән ага репрессиядән котылып, яңадан Казанга кайтып, иҗатка чумды. Аның яңа әсәрләрен үземнең әдәби-музыкаль концерт программаларыма керттем».* Яшьрәк буын шагыйрьләреннән Р.Фәйзуллин, Г.Рәхим, Ш.Маннап, Р.Гаташ, Ф.Яруллин һ.б. белән иҗади дуслыкта эшләде Әзәл Яһүдин. Мин бу язмамда Әзәл аганың сәхнәдә укыган барлык авторларын санап чыгуны бурыч итеп куймадым. Исемнәре аталган авторларны күрсәтеп үтү дә артистның репертуар байлыгын, башкару өчен әсәрләр сайлагандагы зәвыгын, җаваплылыгын, татар әдәбияты белән тирән кызыксынуын кирәк кадәр ачыклый булса кирәк.

Һәрбер артистның иҗатында яратып башкарыла торган, тамашачылар тарафыннан еллар дәвамында сагынып искә алына торган аерым әсәрләр була. Әзәл аганың иҗади эшчәнлеген искә алганда да шундый ике әсәрне атап үтмәкче булам. Аларның берсе язучы Г.Әпсәләмовның «Алтын йолдыз» романыннан «Шаһиевның өйләнүе» дип аталган өзек иде. Аны безгә сәхнәдә яки телевидениедә күп тапкырлар ишетергә туры килде, һәр тыңлау үзенә бер рәхәтлек, ләззәт бирә торган иде, артистның осталыгына, җор теллелегенә залдагы халык сокланып, көлә-көлә тыңлый иде. Телгә алынган икенче әсәр — шагыйрь Ф.Кәримнең «Кыңгыраулы яшел гармун»ы иде.

1942 елның җәендә Ф.Кәрим фронттан яраланып кайта, Казан госпиталендә шушы әсәрен яза. Әзәл агага әсәр бик ошый, ул аны репертуарына ала, үзе җырлап, аккордеонда уйнап башкара. Әзәл аганың беренче тыңлаучылары госпитальләрдә дәваланучы сугышчылар була. Артист үзенең бу яңа эшен авторга да укып күрсәтә. Ф.Кәрим артистка тирән рәхмәт хисләрен белдерә. Шулай итеп, «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәре эстрадада озын юлга «путевка» ала. Минемчә, бу әсәр Әзәл ага тарафыннан иң күп укылган әсәрләрнең берсе булгандыр. Әзәл агадан бер концерт вакытында: *«Кыңгыраулы яшел гармун»ны ничә тапкыр башкардыгыз икән?»* — дип сорагач, болай дип җавап биргән иде: *«Бу әсәр 1942 елдан шушы көннәргә чаклы минем тарафтан 4 мең тапкырдан артык башкарылды инде. Хәзер чәчләр дә бәсләнде, битләр дә җыерчыкланды, ә «Кыңгыраулы яшел гармун» мине әле һаман да яшәртә, дәртләндерә, яшәргә, иҗат итәргә өнди. Әле кулымда гармунны сайрата алсам, мин бу яраткан әсәремне алдагы көннәрдә дә яңгырата алачакмын дип уйлыйм...»*

Әйе, өлкән яшьтәге актерның үзе уйнап, үзе җырлап дәртләнеп башкара алуы, әлбәттә, аның сәхнә осталыгына, тәҗрибәсенә, яшьлек рухы белән яши алу сәләтенә бәйле булгандыр.

Татар эстрада сәнгатен үстерүгә күп хезмәт куйган Татарстанның атказанган артисты Әзәл ага Яһүдин исеме милли мәдәниятебез тарихында лаеклы урынын алды.

Югарыда язылганнардан чыгып, укучым, ниһаять, «Нәрсә соң ул нәфис сүз сәнгате, театрда уйнаучы актер сәнгатеннән ул кай ягы белән аерыла?» дигән сөаль бирергә мөмкин.

Нәфис сүз сәнгате — зур, катлаулы һәм авыр сәнгать (әлбәттә, сүз бу сәнгать юлын сайлаган кеше зур әдәби программалар әзерләп, тамашачы алдына үзе генә чыгып эшли алу дәрәҗәсенә ирешкән очрак турында бара). Бу сәнгать асылында, әйтеп үтелгәнчә, шул ук актер сәнгате ята, әмма аларның максатлары һәм ирешү чаралары бераз үзгә. Нәфис сүз белән чыгучы шул ук актер, ләкин ул сәхнәгә аңа ярдәмгә килүче партнерларсыз, декорациясез, театраль костюмсыз һәм гримсыз, бутафория һәм реквизитсыз, ут һәм музыкаль бизәлешсез чыга. Өстәп шуны да әйтәсе килә: драма актеры ул — театрның бер өлеше, спектакльдә тик бер роль генә уйный, нәфис сүз остасы — үзенең барлык рольләре белән тулы бер спектакль. Һәм менә шул «шәрә» кеше аудитория белән йөзгә-йөз калып, аның дикъкатен яулап алырга тиеш. Алай гына да түгел: ул тыңлаучыны дулкынландыра, аны үз артыннан ияртә, аны елата һәм көлдерә, шатландыра һәм нәфрәтләндерә, сөйләгәннәрне кабул итә яки кабул итмәү дәрәҗәсенә җиткерә алырга тиеш. Һәм боларның барысына да сүз остасына бирелгән гади чаралар ярдәмендә ирешелә. Актер бер кичәдә өч роль башкара алмый, ә сүз остасы барлык баш һәм кече рольләрне «уйнап» бирә ала. Ул картларны да, балалар-

ны да, ирләр һәм хатын-кызларны, трагик һәм комикларны «уйнап» бирә ала, хәтта табигать фаҗигаләрен сөйләп бирә, җыр һәм музыканы «уйнап» күрсәтә ала.

Бер мизгелдә тыңлаучыны сүз көче белән чорлар һәм зур киңлекләр аша үткәрә ала. Әгәр тыңлаучыны үзенең иҗади «партнер»ы итә алса — сүз остасы өчен бу югары уңыш дигән сүз. Сәхнәдә уку ул — барыннан да элек фикер һәм образларны бер кешенең икенче кешегә тапшыруы һәм, әлбәттә, бу икенче кеше сөйләгән текстны артист күзләре белән күрә белергә тиеш. Сүз остасының иҗат куәсе һәм җаваплылыгы актерныкына караганда зуррак һәм киңрәк. Менә шуңа күрә, сүз уңаеннан әйткәндә, әгәр театрда начар актер режиссерга кирәк түгел икән, сәнгатьле укуда ул бигрәк тә кирәк түгел, чөнки һәр аерым очракта бу үзе бер театр.

Кыскасы, бу һәр ике сәнгать тә театрдан үсеп чыккан. Әйтеп үткәнебезчә, һәр икесенең аерым үзенчәлекләре бар. Шул үзенчәлекләрне үзләштергән драма актерлары менә дигән беренче сүз осталарыбыз (урыс театры тарихындагы кебек) беренче татар театрлары труппаларында барлыкка килүен язып үткән идек. Әгәр реалистик сәнгатьле укуны нигезләүдә һәм үстерүдә урыслардан артистлар М.Щепкин, В.Горбунов, М.Садовский, М.Ермолова, К.Станиславский, А.Закушняк, В.Качалов, В.Яхонтов, И.Москвин кебек сәхнә даһилары зур роль уйнаган булса, татарлардан Г.Тукай, Г.Камал, Һ.Такташ, Г.Кариев, С.Волжская, Мәкәрим Мәһдиев, Х.Сәлимҗанов, Г.Шамуков, Ш.Сарымсаков, Г.Ибраһимова кебек һәркайсы аерым хөрмәткә лаеклы шәхесләр зур хезмәт күрсәттеләр.

Шулар арасыннан театрыбызның икенче бер бөек шәхесе — СССРның халык артисты Габдулла Шамуков турында тәфсилләбрәк язып үтәм.

Габдулла Рухулла улы Шамуков мәшһүр драма артисты булу белән бергә сүз сәнгате өлкәсендә үзен зур оста итеп күрсәтте, театр училищесында сәхнә телен укытып, үз шәкертләрен булдырды. Ул чыннан да күпкырлы талант иде. Язучы Мөхәммәт Мәһдиев үзенең бер язмасында: *«Шамуков — актер, Шамуков — әдәбият белгече, мәсәлче, тәрҗемәче, тәнкыйтьче... Боларның барысында да аның көче-таланты тигез түгел, бер юнәлештә аның хезмәтләре күбрәк, нәтиҗәлерәк, икенче бер тармакта ул ничектер узышлый гына, эш арасында гына кереп чыккан сыман, ләкин барысы да кызыклы, үзенчәлекле»,* — дип, аңа бик дөрес бәя бирде.

Шәхсән үзем Габдулла аганы әле балачак елларымда, Башкортстанның Балтач районында Башкорт академия театры гастрольгә килгән вакытлардан күреп беләм. Без, мәктәп укучылары, кайбер спектакльләргә «эләгә» торган идек. Габдулла аганың кайбер рольләре бүгенгедәй хәтеремдә. Театр биргән концертларда ул Тукай, Такташ әсәрләрен укыды. Район радиоузелыннан аның башкаруында Такташның «Мәхәббәт тәүбәсе»н тыңлаган идек. Ә 1946 елны, без Казанда театр мәктәбендә укыганда, Габдулла ага Шамуковның Татар дәүләт академия театрына эшкә килгәнен ишеттек. Ул шулай ук театр мәктәбендә сәхнә теленнән укыта башлады. Мин аңарда укымадым, ләкин аның белән очрашу вакытларында кызыклы әңгәмәләр була иде. Ул үзе язган һәм Крыловтан тәрҗемә иткән мәсәлләр алып килеп, безне мәсәл укырга өйрәтә иде. Ә 1956 елда мин Габдулла ага белән Академия театрында бергә эшли башладым, аның белән күп кенә спектакльләрдә бергә уйнадым. *«Мин театр сәнгатенә әдәбият аша килдем,* — дия торган иде Габдулла ага. — *Хәреф таный башлау белән кулга төшкән һәр китапны укырга тырыша идем. Бабай китапларыннан мин укый алырлык берничәсе табылды: «Көйле иман», «Мөхәммәдия», «Фәзанлешиеһүр», Габделҗаббар Кандалый шигырьләрен аеруча яратып укыйм — аңлаешлы да, кызыклы да. Инде Мәләкәс шәһәрендә укый башлагач, андагы татар китапханәсенең байлыгына исем китте. Мин китаплар дөньясына чумдым. Мәктәптә үткәрелә торган кичәләрнең һәрберсендә шигырь, поэма яки хикәя белән сәхнәгә тамашачы каршына чыга башладым. Әдип язган әсәрне җанландырып тамашачы күз алдына бастыру, шуның аша әсәрдәге гүзәл фикерне пропагандалау минем өчен фарызга — изге бурычка әверелеп китте. Шулай итеп, гомеремне сәхнәгә багышлау нияте белән Уфадагы театр мәктәбенә барып кердем. Аны тәмамлаган көннән башлап бүгенгәчә театр сәнгатенә хезмәт итеп киләм»,* — дип сүзен тәмамлый иде Габдулла ага. Әйткәнебезчә, ул 1946 елдан гомеренең ахырына кадәр Татар дәүләт академия театрында эшләде. Сәхнә эшчәнлеге белән бергә пьесалар тәрҗемә итә, әдәби иҗат белән дә шөгыльләнә. Ул татар теленә дөнья әдәбияты классиклары Шекспир, Шиллер, Эсхил, Бомарше, Золя әсәрләрен, урыс классикасыннан Грибоедов, Пушкин, Островский, Гоголь һәм Чеховны тәрҗемә итә.

Г.Шамуков татар шигырь төзелешенә кагылышлы теоретик хезмәт, кайбер язучыларның иҗат портретларын сурәтләгән тикшеренүләр дә яза. Әлбәттә, актерның төп эше — сәхнә; 50 ел иҗат гомерендә ул йөзләгән сәхнә образлары тудыра. Драма һәм комедияләрдә төп рольләрне башкара. Үзләренең эчке дөньялары һәм тышкы яктан да мәгънәле пластик сурәтләү чаралары белән аерылып торучы чын сәнгать образлары иҗат иткән зур сәнгать остасы иде Габдулла ага.

Миңа Габдулла ага Шамуков белән Казанның күп сәхнәләрендә, Мәскәү, Алма-Ата, Ташкент, Уфа, Свердловск, Нукус кебек шәһәрләрнең концерт залларында төрле концертларда, әдәби кичәләрдә бергә катнашырга туры килде. Аның чыгышлары һәрвакыт уңыш казана иде, актер авторның фикерен төгәл җиткерү ягыннан үрнәк булды. Аның репертуары ифрат бай иде, анда Тукай, Такташ, Туфан да, Ш.Бабич, Г.Кандалый, Акмулла да, безнең замандаш шагыйрьләребез әсәрләре дә зур урын алып торды. Радио фондында аның башкаруында язмалар, грампластинкалар бар. Ләкин аның башкару осталыгы видеофильм-

нарга төшерелмәве генә бик кызганыч, аның спектакльләрдә уйнавы бераз тасмага төшерелгән, шулар өстенә концертлардагы чыгышлары да язылган булса, нур өстенә нур булган булыр иде.

Әйе, Габдулла ага Шамуков күпкырлы талант иясе, тормышта гади, тыйнак, күркәм кеше иде. СССРның халык артисты, халкыбызның яраткан артисты, кабатланмас шәхес белән бергә эшләгән көннәребез һәрберебезнең күңелендә озак сакланыр.

Мин сүз жанры турындагы бу язмамда татар сәнгатендә нәфис сүзнең кайчан башланып китүе, аны үстерүдә кемнәр катнашуы, бу жанрның сәнгатебездә тоткан урыны турында кыскача гына булса да ретроспектив күзәтү ясарга теләдем. Безне кызыксындырган сораулар: нәфис сүз сәнгате рус сәнгатендәге әлеге жанрның үсеш дәрәҗәсе белән чагыштырганда канәгатьләнерлекме, сәнгатебезнең вокаль һәм музыкаль жанрларында эшләүчеләр саны көннән-көн арта барганда, сүз сәнгатендә иҗат итүчеләр саны элеккеге еллар белән чагыштырганда нилектән бик күпкә азайды, бу жанрда эшләүче режиссерларыбызның юклыгын ничек аңлатырга, ни өчен бүгенге тамашачыны эстрадабызның, шул исәптән сүз жанрының хәзерге хәле канәгатьләндереп бетерми һ.б., һ.б. Сораулар, әлбәттә, күп. Кабатлап булса да шуны әйтәсе килә. Нәфис сүз сәнгате — зур, җитди һәм авыр сәнгать. Үзенең үсеш юлында уку сәнгате зур һәм катлаулы юл үтә. Тамырлары белән халык мәдәниятенең еракта калган үсеш юлларына кайтып, авторлык укуларыннан күп нәрсә алып, үзенең иҗат юлын драма театры юллары белән бәйләп, нәфис сүз Октябрь революциясеннән соң гына бөтенхалык яклавын таба һәм үзенә аерым сәнгать булып формалаша башлый.

Илебез язучыларының иң яхшы әсәрләренә таянып, рус һәм дөнья классикасының үрнәкләреннән файдаланып, нәфис сүз сәнгате халыкны тәрбияләү эшенә актив катнашу хокукын яулый. Заманыбызның бөек режиссеры К.С.Станиславскийның: *«Гади һәм матур сөйләү — бөтен бер фән ул; аның үз законнары булырга тиеш»,* — дигән сүзләре кабат искә төшә. Бу, әлбәттә, театр сәнгатенә дә, шул ук вакытта сүз сәнгатенә дә бик тәңгәл килә торган гыйбарә. Театр сәнгате бөтенләе белән драматургиягә, сүзгә бәйле булган кебек, нәфис сүз дә дөнья әдәбиятының зур байлыгына таянып эш итә. Актерлык сәләте төрле булган кебек, нәфис сүз осталарының индивидуаль иҗат алымнары да төрлечә, һәм, әйтергә кирәк, аларның кайберләре эстрададагы чыгышларын телевидениедә, кинода, театрда яки радиода эшләү белән бергә бәйләп алып бара, ә башкалары иҗат гомерен фәкать концерт эшчәнлегенә багышлый.

90 нчы елларга кадәр Мәскәү һәм Ленинград филармонияләрендә илебез сәхнәләрендә киң танылган, популярлык алган күренекле нәфис сүз осталарының саны берничә йөзләп иде, алар илебезнең барлык өлкәләрендә һәм шәһәрләрендә зур гастроль эшчәнлеге алып бардылар. Казанның концерт залларында чыгышлар ясаган сүз сәнгатенең зур осталары С.Кочарян, Я.Смоленский, Э.Каминка, В.Токарев, С.Юрский, В.Маратов, В.Рецептер, А.Кутепов, Ю.Мышкин, А.Виноградова, А.Шварц, П.Вишняков һәм башкаларны өлкәнрәк яшьтәге тыңлаучылар бүген дә яхшы хәтерли. Аларның иҗатларында һәрвакыт камиллек һәм төрлелекне сизә идек без. Бу артистларның чыгышларын филармония оештырганлыктан, без алар белән яхшы таныш, аларның әдәби концертларын бик күп карадык.

Русиянең һәм Әрмәнстанның халык артисты, Дәүләт бүләге лауреаты С.А.Кочарянның күп әдәби концертларын мин Казанда тыңладым, тагын берничәсен, шул исәптән «Давид Сасунский» һәм «Витязь в тигровой шкуре» исемле композицияләре белән Мәскәүдә танышкан идем. С.А.Кочарян белән Казан Актерлар йортында үткәрелгән очрашулар хәтердә саклана, ул очрашуларда оста үзенең иҗат алымнары белән тәфсилләп таныштыра иде. Ул елларда илебезнең башка шәһәрләре филармонияләрендә дә сүз сәнгате өлкәсендә эшләүче артистлар күп иде. Вакыт-вакыт Мәскәүнең үзәк Актерлар йортында нәфис сүз жанрында эшләүче артистларның Бөтенрусия күләмендәге конкурслары үткәрелә иде, ул конкурсларга төрле өлкәләрдән йөзләгән башкаручылар килә иде. Минем үземә дә шундый конкурсларның икесендә лауреат, берсендә дипломант исемен яулау бәхете насыйп булды. Билгеле, ул конкурслар һәр башкаручыга үзе бер иҗат лабораториясе иде. С.Кочарян күп җәмәгать эшләре алып бару өстенә Бөтенрусия театр җәмгыяте каршында эшли торган нәфис сүз өлкәсендә эшләүче артистлар секциясенә озак еллар рәислек итте. Мәскәүдә гастрольләр вакытында бу секция эшендә мин дә еш катнаша идем, күп нәрсә яңа ягы белән ачыла һәм иҗатыма эшемдә зур этәргеч бирә иде. Сурен Акимович ике әдәби композициямә режиссер буларак та ярдәм иткән иде. Сүз сәнгате өлкәсендә 40 елдан артык эшләү дәверендә мин үземнең остазларым итеп ике кешене санyйм. Аларның берсе, Казандагысы — Хәким ага Сәлимҗанов булса, Мәскәүгә барганда үземне С.Кочарян шәкерте итеп тоя идем. Әлбәттә, аның зур осталыгы алдында баш иеп, остаздан күп нәрсәгә өйрәнү мөмкинлеге бар иде, С.Кочарянның һәрбер әдәби кичәсен тыңлау үзе бер иҗат мәктәбенә тиң иде.

Мәскәүдә сүз сәнгатендә эшләүче тагын бер дустым — режиссер, Вахтангов театр училищесының сәхнә теле кафедрасы мөдире профессор Яков Михайлович Смоленский иде. 1957 елдагы конкурста без аның белән СССР Язучылар союзының поэзия буенча бүләген бүлешкән идек. Әлеге конкурс безне күп еллар буена дуслаштырды. Кызганыч, Мәскәүдәге бу дусларым (сүз өлкәсендә эшләүче артистлар арасында андыйлар тагын бар иде) һәм остазым хәзер якты дөньядан кичтеләр, аларны сагынып сөйләргә генә калды.

90 нчы еллардан бирле Казанга Мәскәүдән сүз осталарының килүе дә туктады, рус һәм дөнья әдәбиятын тере сүз ярдәмендә дулкынланып тыңлау бәхетеннән мәхрүм калдык. Әдәби концертлар булмаудан мәдәни мохитебездә ни дә булса югалттыкмы? Әлбәттә, югалттык. Әдәби әсәрне китаптан уку бер нәрсә, ә

сүз остасы үзенең осталыгы, интеллекты, мәдәнилеге белән «терелткән» әсәрне колагың белән «уку», башкаручының партнеры булу, аның белән бергә кайгыра, шатлана, нәфрәтләнә, горурлана белү тыңлаучы өчен (әгәр ул әдәбиятны чынлап ярата белсә) үзе бер бәхетле мизгел түгелмени?!

Казанда да сүз сәнгатендә эшләүче артистларны бергә туплап торучы Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясендә эстрадада һәм әдәби-музыкаль лекторий бүлегендә сүз өлкәсендә эшләүче егермеләп артистны, кем әйтмешли, бер селтәнү белән эшсез калдырдылар. Аларның кайсы кая эш эзләп китте. Ә бит ул кадрларны күп еллар буена (филармония директоры булып башка милләт кешеләре эшләгәндә дә) берәмтекләп җыйганнар, аларга иҗади яктан үсәр өчен шартлар тудырганнар иде. Нишлисең бит, «ни чыкса, үз татарыңнан чыга» дигән халык әйтеме бик дөрес шул. Әгәр Г.Тукай шул хәлләрне үзе күрсә дип фаразлыйк, 300 гә якын язучысы булган татар әдәбиятын пропагандаларга тиеш булган, үз исемен йөрткән филармония җитәкчеләренә бүгенге көнне нәфис сүз өлкәсендә эшләүчеләр юклыгын күреп, нәрсә әйтер иде икән? Сәнгать белән «җитәкчелек» итеп ятучы мондый түрәләрне «Ялт-йолт»та «селкетеп» алыр иде, мөгаен. Әле ярый, шөкер, бу кадерсез көннәр килеп җиткәнче, җиң сызганып дигәндәй, эшләп калдык, татар әдәбиятының җәүһәрләре саналган әсәрләрне ул чактагы киң илебезнең бик күп республика, өлкәләрендә татар һәм рус телләрендә яңгырата алдык.

Шәхсән мин үзем Союзыбызның бик күп республика, өлкә, шәһәр һәм районнарында, шулай ук чит илләрдә дә гастрольләрдә булуым белән бик горурланам. Һәркайда да татар әдәбияты үрнәкләрен бик теләп һәм зур кызыксыну белән тыңлауларын, югары бәя бирүләрен исемә төшерәм, язучылар һәм башкаручылар өчен тагын бер кат шатланып һәм горурланып куям. Сәхнәдән башкару өчен татар әдәбиятында тыңлаучының йөрәгенә барып җитә торган менә дигән әсәрләр бар бит!

Сүз сәнгате өлкәсендә күп еллар эшләү дәверендә берничә мең концерт бирелгән, әдәбиятыбызның берничә буын шагыйрьләре һәм язучылары белән тыгыз бәйләнештә торып, чын иҗади эш алып барылган, эстрадада, радио һәм телевидениедә әдәби мирасыбызны пропагандалау буенча актив эшчәнлек күрсәтелгән. Башкаручы актер өчен бу үзе бәхет түгелмени?!

Милләттәшләребез яши торган ерак төбәкләргә гастрольләр бетте диярлек, еракка түгел, үз республикабыз районнарына барулар да кимеде. Мин үз вакытында күп район мәктәпләренә һәм Мәдәният йортларына әдәби концерт программалары белән йөрдем. Ул эшләрне филармониянең әдәби-музыкаль лекторие бик төгәл рәвештә алып бара иде. Яшьләрне тәрбияләү эше итеп карап, бу концертларны үткәрү буенча безгә район культура бүлекләре һәм мәктәп дирекцияләре зур ярдәм күрсәтәләр иде. Хәзер инде, кем әйтмешли, үз Казаныбызда гына «кайнарга» калды. Төрле эстрада төркемнәре эшләп, йөреп тора, хәзер кайсы төркем кайсы оешма аркылы концертлар биргәнен дә белмәссең. Мин алар турында әйтмим, ә тулы канлы сүз сәнгатенә бәйле эшчәнлек турында сүз алып барам.

Әдипләребезнең, шагыйрьләребезнең Казанда республика масштабында үткәрелә торган зур юбилей кичәләре, Язучылар берлеге оештырган (алар республикабызда һәм чит өлкәләрдә соңгы берничә елда күп үткәрелә) әдәби кичәләр, очрашулар, яңа чыккан китапларны укучыларга тәкъдир итү кичәләре һ.б. чаралар еш булып тора. Республика радиосы әдәбиятыбыз һәм мәдәниятебез яңалыклары, татар әдәбиятының классик мирасы һәм яңа язылган әсәрләр белән җөмһүриятебездә һәм бездән еракта яшәүче милләттәшләребезне яхшылап таныштырып бара. Бу эшләрнең күбесендә катнашырга тырышабыз, үтә дә кирәкле эш дип саныйбыз. Язылганнарны кабатлап булса да, шуны әйтәсе килә: бу эшләрнең барысында да бүгенге көндә театр эшлекләләре зур хезмәт күрсәтә. Татар сәнгатенең төрле дәверләрендә театр артистлары сүз сәнгатен халыкка җиткерүдә зур роль уйнады. Бүгенге көндә сәхнәдән булсын, радио аша булсын, сүз сәнгатен тыңлаучыларга җиткерүдә актив эшләүче могтәбәр артистларыбыз Ш.Биктимеров, Р.Шәрәфи, П.Исәнбәт, Р.Таҗетдинов, И.Баһман, Д.Нурлы, И.Әхмәтҗанов, Х.Җәләй, Н.Ихсанова, яшь буын артистлардан Ф.Җиһаншин, Р.Вәҗиев һ.б. исемнәрне мактап телгә аласы килә. Филармониядә күп еллар эшләгән Р.Сабировның иҗади эшчәнлеге аеруча хөрмәткә һәм мактауга лаек.

Һәммәбезне дә татар театры яшәгәндә сүз сәнгатенә әһәмият кимемәс дигән уй өметләндерә һәм шатландыра. Шулай ук республикада актив эшләп килүче үзешчән сәнгатьтә, төрле конкурсларда, фестивальләрдә, мәктәп һәм гимназия укучылары чыгышларыннан күренгәнчә, сүз сәнгатенә игътибар арту сәнгатебезнең халык ярата торган бу төре әле киләчәктә яңа күтәрелешкә барачак дигән якты өметләр уята.

Язылганнарга йомгак ясап, шуны әйтәсе килә: сәхнәдән әйтелгән сүз үткен фикерле булырга, кешеләрнең күңелләренә тәэсир итәргә тиеш. Моның өчен эстрадага чыгучы үз репертуарына ялкынлы публицистика элементларын да кертә белергә тиеш. Сәнгатьнең башка төрләрендәге кебек, эстрадада гаять мөһим компонент бар, ул да булса — башкаручының үзенә генә хас булган сыйфатларга ия булуы, индивидуальлеге, үзенчә иҗат иткән характеры, образ. Башкаручының шәхси сәләтен ачуга ярдәм итә торган сәхнә характерын тудыру — төп бурычларның берсе. Сәхнәдә төрле пландагы образлар тудыру өчен башкаручыга сәхнә теленең түбәндәге элементларының гармоник берләшүе зарури: интонация ягыннан төрлелек, бай, дөрес куелган тавыш, яхшы дикция, дөрес сулыш алу, ачык, логик яктан мәгънәле сөйләм, тойгы һәм фикерләрне дөрес белдерү өчен сүз сөйләүгә ярдәм итә торган мәгънәле сөйләү палитрасын баетуга менә шулар ярдәм итәләр.

«Сүз гаме» дигән бу язмамны узган гасырда яшәгән методист В.П.Острогорский сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

*«Әдәбиятны яратмаган, бала вакыттан ук аның белән махсус мавыкмаган һәм аннан ләззәт тапмаган, эстетик зәвыгы һәм сәнгатьле укуга аз гына да сәләте, һичьюгы, көчле һәм сыгылмалы тавышы һәм сүз куәсе булмаган кеше, әгәр дә ул намуслы булырга теләсә, бу төр профессия турында уйлауны ук башыннан чыгарып ташларга тиеш».*

*2000*

**АЙРАТ АРСЛАНОВ**

## Сәнгать-әдәбият

## әһелләрен сагынып...

Мин ярты гасырдан артыграк татар мәдәниятен үстерү өлкәсендә, татар сәнгатендә, татар сәхнәсендә хезмәт итәм.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә, Татарстан дәүләт радио һәм телевидение компаниясендә эшләгән елларымда мин беренче нәүбәттә сәхнә теле аша олы әдәбиятыбызны пропагандалаучылар сафында булдым, тамашачыларыма, тыңлаучыларыма туган телебезнең матурлыгын, моңлылыгын, сыгылмалылыгын һәм, иң әһәмиятлесе, татар теленең төрки телләр арасында олпат телләрнең берсе булуын күрсәтүне бурычым итеп санадым.

Бу урында бөек язучы һәм галим Галимҗан Ибраһимовның бер мәкаләсеннән өзек китереп үтәсем килә: *«Дөнья безне татар дип атый... Татар дигән сүздән качарга асла урын юк. Ул безнеке. Ул моңарчы килде һәм хәзергәчә безнең илә барачак. Һәм ул безнең төрек милләтеннән булуымызга каршы түгел. Без тормышта «татар» аталып бара бирәбез. Эшләремезне татар эше дип атыймыз, үземез — татар, телемез — татар теле. Әдәбиятымыз — татар әдәбияты, эшләгән һәммә эшемез — татар эшләре, туачак мәдәниятемез татар мәдәнияте булачак».*

Галимнәребез күрсәткәнчә, татар әдәби теле — гасырлар дәвамында халык тарафыннан иҗат ителгән олы хәзинәләрнең берсе. Ул үзенең тарихы белән борынгы чорларга барып тоташа. Татар теле төрки кабилә һәм халыкларның билгеле бер үсеш баскычында үзенә хас үзенчәлекләре белән аерылып чыккан борынгы язулы бай телләрнең берсе булып санала.

Сүз — кешеләр аралашуы өчен иң кирәкле чараларның берсе. Мин татар эстрада сәнгатенә 50 нче елларда аяк бастым. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе һәм Татар дәүләт опера һәм балет театры концертларында катнашып, илебезнең төрле өлкәләрендә булырга туры килә иде. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында актер булып эшләгән елларда да сәнгатьле уку жанры белән кызыксыну кимемәде, бәлки тагын да көчәйде дисәм, ялгыш булмас.

Бу елларда миңа радиода укыла торган әдәби тапшыруларда татар, рус һәм дөнья әдәбиятыннан бик күп авторлар белән очрашырга туры килде. Радио актерга аның көндәлек эшен таләпчән рәвештә күзәтеп баручы миллионлаган кешелек аудитория бирә, шул аудиториянең зәвыгына туры килерлек күпсанлы әсәрләр өстендә эшләү мөмкинлеге тудыра. Ә бит радио аша уңышлы укылган әсәрләр башкаручының һәм тыңлаучыларның исендә озак сакланалар. Әсәрләрен яратып укыган һәм тыңлаучыларның да хәтерендә калырлык тапшырулар ясауга ярдәм иткән язучылар һәм шагыйрьләрнең исемнәрен санап чыгу да күп вакыт алыр иде.

Сөйләмебезнең мәдәнилеге никадәр югары булса, безнең тарафтан язма һәм яңгырашлы сүзне үзләштерү дә шул дәрәҗәдә җиңел булачак. Безнең белән фән, сәнгать һәм әдәбият туган телебездә сөйләшәләр. Әгәр дә без үз халкыбыз телен кадерли беләбез икән, безгә туган телебездә гәүдәләндерелә торган һәрнәрсә якын һәм аңлаешлы булачак. Сөйләм культурасы, әлбәттә, әдәби тел нормаларын төгәл үтәүгә бәйләнгән. Оратор сәнгатен, язучы, артист осталыгын дөрес үзләштерү нәкъ менә шуларга бәйле.

Татар сәнгате дөньясында, төгәлрәк әйткәндә, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә эстрадада, радио һәм телевидениедә озак еллар эшләвем дәверендә миңа күп кенә күренекле сәнгать һәм әдәбият әһелләре — артистлар, режиссерлар, композиторлар, рәссамнар, әдипләр һәм шагыйрьләр белән аралашырга туры килде. Шул язмаларның аз өлешен булса да укучыларга тәкъдим итәргә булдым. Ул язмалардагы мәшһүр шәхесләрнең күбесе безнең арабызда юк инде, ә аларның сәнгать-әдәбият дөньясында кылган изге гамәлләре барыбызның да күңелләрендә озак сакланачак. Бөек грек галиме һәм фәйләсүфе Гиппократ әйткәнчә: *«Гомер кыска, сәнгать — мәңгелек».*

## Сәнгать әһелләрен үз күрде

Әгәр миннән: «Әдәбиятыбызда иң нечкә лирик шагыйребез кем?» — дип сорасалар, «Әлбәттә, Сибгат Хәким», — дияр идем. Сибгат ага белән озак еллар дәвамында иҗади дуслыкта булуымны горурланып әйтә алам. Татар сәхнәсендә С.Хәкимнең шигъри әсәрләре дә, җырлары да үз вакытында бик еш яңгырадылар һәм бик уңышлы башкарылдылар. Хәзерге эстрадабыз, бигрәк тә аның сүз жанры ниндидер торгынлык чоры кичерә. Сәхнәдән Тукай да, Такташ та, Туфан, Сибгат Хәким дә сирәк ишетелә. Хәзер нигәдер, зәвыксыз язылган, буш эчтәлекле әсәрләр күбрәк яңгырый. Бик кызганыч хәл бу! Ә бит өлкәнрәк яшьтәге кайбер тамашачыларыбыз матбугатта бу турыда бик ачынып язалар.

Ләкин мондый хәл бер килеп үзгәрер әле дигән уйда без, әдәбият җәүһәрләребез яңадан үз кыйммәтләренә кайтырлар, сәхнәләребездә лаеклы урыннарын алырлар. Моңа иманым камил! Сибгат Хәким — әдәби мирасыбызга берничә том лирика һәм күпсанлы матур поэмалар калдырган автор. Аларны укыган саен укыйсы килеп тора. Шуңадырмы ул поэмаларның дистәгә якыны безнең тарафтан радио фондына язылды. Шулар арасында «Кырыгынчы бүлмә», «Дәверләр капкасы», «Васыятьләр» , «Эзлиләр Европа буйлап» һәм соңгы поэмасы «Күги» дә бар. Н.Беляев тәрҗемә иткән берничә поэмасын урыс телендә дә язып калдырган идек.

Сибгат Хәким әсәрләрен миңа сәхнәдә, радио һәм телевидение тапшыруларында бик күп укырга туры килде.

Сибгат аганың үзе белән дә республикабызның һәм ул вакыттагы Союзның кайбер төбәкләрендә булдык.

Аның бер язмасында мондый юллар бар: «*Артистлар, җырчылар белән кайда очрашасың? Юлда. Алар турында язасың килсә, бергә юлга чык. Алар гел юлда. Юл үзеннән-үзе күп нәрсәне искә төшерер.*

*Менә Питрәчкә очрашуга чакырдылар. Автобуста шагыйрьләрнең аерылгысыз дусты Айрат Арсланов, шагыйрь һәм тәрҗемәче Николай Беляев, җырчы Вафирә Гыйззәтуллина һәм баянчы егет... Юл. Безнең филармония артистлары узган юлны кемнең дә булса исәпләгәне бар микән? Авыллар, шәһәрләр, төрле кешеләр... Кызыгып куям: көндәлек алып барасы иде. Кем белә, бәлки, арадан берсе юл көндәлеген күптән дәвам иттерә торгандыр».*

Әйе, Сибгат ага сәнгатьтә һәм әдәбиятта эшләүче күбебез турында җан җылысы белән язылган матур-матур язмаларын калдырды. Язучылар, шагыйрьләр, артистлар, композиторлар, җырчылар турында Сибгат агадан күбрәк язучы шагыйрь булдымы икән? Юк, булмагандыр. Сибгат ага безне, сәнгать өлкәсендә эшләүче барыбызны да, яшьтән үк күзәтеп, уңышларыбызга, иҗади үсешебезгә сөенеп яшәде кебек тоела миңа, кирәк чакта үзенең төпле киңәшләрен бирде, һәрбер яшь иҗат кешесенә ярдәмгә килергә әзер торды. Сәнгатьнең төрле жанрларында эшләүчеләр, шагыйрь һәм язучылар турында истәлек язмалары гына да тулы бер томны тәшкил итә бит. Бу яктан алганда Сибгат ага Хәким үзенең кешелекле кеше, әдәбиятыбыз һәм сәнгатебезнең киләчәге өчен кайгыртып яшәүче олы җанлы шәхес буларак кереп калды әдәбиятыбыз, мәдәниятебез тарихына.

Сибгат ага белән беренче танышуым 50 нче елларның башында язучыларның Тукай клубында булды. Ул кичә яшь иҗат көчләренә багышланган иде. Концерт тәмамлангач, сәхнә артына өлкән язучыларыбыз Нәкый Исәнбәт, Нури Арсланов, Сибгат Хәким, Фатих Хөсни күтәрелделәр, һәммәбез белән танышып, иҗат эшебездә уңышлар теләделәр. Шунда мин Сибгат агага: «Радиода миңа сезнең «Пар ат» исемле поэмагызны әзерләргә куштылар, тиздән аны магнитофонга яздырачакмын», — дидем. Сибгат ага минем белән бик игътибар биреп сөйләште. «Ул минем 1938 елда язган беренче поэмам, шуңадырмы үзем өчен бик кадерле әсәрем...» — диде. Аннан: «Сез аны матур итеп укый алырсыз, мин сезнең берничә чыгышыгызны яратып тыңладым, уңышлар телим үзегезгә», — дип өстәде.

Бераз вакыт узгач, Сибгат ага миңа, телефоннан шылтыратып, поэманы радиодан яратып тыңлавы турында әйтте.

Әйе, Тукай темасы Сибгат аганың иң яраткан темасы иде. «Тукай бөтен рухы белән милли шагыйрь, Тукай кебек татар халкына якын башка бер генә шагыйрь дә юк», — дип язды ул.

Сибгат ага белән очрашулар вакытында Тукай турында күп сөйләшүләр була иде. Ул мине кышкы көннәрнең берсендә Тукай яшәгән «Болгар» кунакханәсенең 40 нчы бүлмәсен күрсәтергә дә алып барды. Ләкин ни сәбәптәндер без «Болгар» номерларының эченә үталмадык. Матур, җылы көн иде, хәзерге Камал театры урынында бик озак басып тордык, Сибгат ага Тукай турында сөйләде дә сөйләде...

«Тукайны туктаусыз укый алам. Нигә туйдырмый, үзем дә аңламыйм, — ди торган иде Сибгат ага. — Шигырьләре генә түгел, мәкалә, фельетоннары да шулай. Оста язылудамы хикмәт? Юктыр. Тукайның җене бар, усал җен, язмыш җене кагылган. Шул усал иткән. Эчке бер көч. Тукай мәкаләләрен бер утыруда язган. Бер яну белән. Күп тапкырлар төзәткән мәкаләләр андый булмый, гадәттә, шомарган, сүлпән була. Тукайда, киресе».

Миндә Сибгат аганың дистәләгән хаты саклана, ул хатларда да күбрәк иҗат турында, иҗатыбызда Тукай темасы белән яшәгән мизгелләр турында фикерләр чагыла. Менә аның 1986 елның февралендә язган зур булмаган хаты. Ул аны вафатына берничә ай кала язган.

*«Хөрмәтле Айрат! Сезгә вәгъдә иткән шигырьләрне салам. Татарча һәм русча. Бәлки, тәрҗемәсе дә кирәк булыр.*

*Тукай турындагы тапшыруыгызны карадык* (сүз телевизион тапшыру турында бара. — *А.А.). Сездә хисләр тагы да көчәйде. Бу минем фикер генә түгел. Димәк, Сезнең иҗатны туктаусыз күзәтеп киләләр. Мин дә шул исәптән. Мин бик шат. Осталык тиз генә бирелми. Тукай тапшыруында бигрәк тә «Пар ат» җанымны тетрәтте. Мин үзем дә туган яктан елап аерылам. Аерылу газабы белән тулган шигырьләрем, җырларым күп. Берсе — «Минем таныш өянкеләр».*

*Сезгә иҗади уңышлар, сәламәтлек теләп Сибгат Хәким. 21/II. 86».*

Шагыйрьнең хатлары белән килгән күп шигырьләре, Тукай, Җәлил турында язылган кечкенә-кечкенә парчалары саклана минем архивымда. Тукайга багышланганнары арасында күңелемә хуш килгәне «Тукай арбасы» дип атала.

*«Каенсар Әтнә белән Киме арасында. Кимегә ике генә чакрым. Ул авылда Зиннәтулла кызы Саҗидә апа яшәде. Сугышка чаклы Саҗидә апа өендә кунганым бар. 1907 ел көзендә Тукай Әтнәгә солдатка каралырга кайта һәм Каенсарга апасы янына килә. Ара ике генә чакрым бит, их, Кимегә дә сугылган булса шунда. Әздән генә калган бит. Каенсарга китергән юл Кимегә менеп китә, үргә. Киме басулары барыбер аны күргән. Мин шуңа да шат. Безнең кырларда Тукай рухы калган. Мин Кимегә кайтышлый Каенсарга карап узам. Басу капкасыннан ат күренсә, Тукай китеп барадыр кебек. Шул чакта Тукайлы арбага күчеп утырасы килә...»*

Мин бу парчаны шигырь укыган кебек укыйм. Күпме фикер, шагыйрьне ярату хисе анда.

Сибгат аганың тирән лирик шагыйрь икәнлеге аның проза әсәрләрендә дә, тормышта бер-бер вакыйга яки күренеш турында сөйләгәндә дә чагыла иде. Әйе, иҗаты әдәбиятыбызда, мәдәниятебездә киң урын алган, фәлсәфи тирән фикер, үтә дә нечкә лирик хисләр иясе Сибгат Таҗи улы Хәким — күптән Тукайлы арбага күчеп утырган олы шәхесебез. Тукай турында поэзиябездә аңардан да күбрәк язучы булдымы икән?!

Мин бөтенләй башка чор шагыйре,
Яңа иман миндә, ден яңа...
Ике катлы тәрәзәдән карыйм,
Тукай аша карыйм дөньяга, —

дип язуы очраклы гына түгелдер.

Шагыйрь күп язды, аның шигырьләре һәм поэмалары Казан, Мәскәү нәшриятларында татар һәм рус телләрендә, шулай ук башка халыклар телләрендә дөнья күрде. Поэмаларында фикер байлыгы, психологик тирәнлек... Аларны кайта-кайта укырга, уйланырга кирәк, ул әсәрләр, әгәр син аларны сәхнәдән яки радиодан укырга әзерләнәсең икән, озак вакыт «кесәңдә», күңелеңдә йөрергә тиеш, текстны яңадан укыган саен, яңа фикерләр килә. Күп вакытларда, фикер тирәнлеген бөтен дәреслеге белән җиткерү өчен, мин авторның үзе белән бәйләнешкә керә идем, шулай итеп әсәрнең тулы канлы яңгырашына ирешелә иде.

Сибгат ага, үз поэмалары турында уйланып: «Поэмаларым Ватан сугышыннан соң бер чорда, бер тирәдәрәк язылганнар икән. Мин ашыктым. Моңа чаклы күргәннәрем ничектер бер тар арага килеп тыгылдылар. Яңгыр алдыннан борчуга төшкән игенче кебек, кырда төрле урында урыласы, җыеласы игене котелмәгән хәвефтән югалудан куркып калган игенче кебек, мине дә курку алды, мин дә ашыктым. Урыласы кишәрлекләр күп иде. Тормыш биографиясе ашыктырды, язылачак поэмаларымның берсе бетүгә, икенчеләрен күреп тордым: өлгерсәм ярар иде...» — дип язган иде.

Әйе, укучы аңлый, бу поэмаларда шагыйрьнең заманы белән күзгә-күз карап, ачыктан-ачык сөйләшүе, бәхәсе. Укыйсың да уйга каласың: шундый күп персонажлар галереясы, сюжетлар борылышы, фәлсәфи тирәнлек белән чор турында, гомумкешелек турында фикер йөртү автордан күпме ихтыяр көче, язу осталыгы, йокысыз төннәр таләп иткән. Ә бит әсәрләрнең кайберләре чагыштырмача җиңелрәк бирелгән кебек, кайбере шагыйрьдән ифрат күп көч, күңел бәргәләнүен таләп иткәндер. Сибгат аганың менә бу кечкенә хатында да шул фикер чагыла:

*«Айрат!*

*Сезгә әйткән шигырьне җибәрәм, басылмаган, яңа. Машинкада бастырырга вакытым юк, китәм. Бик яратып яздым, бер көндә яздым, күтәренке рух белән. Аннан соң Муса турында бер шигырьгә тотынган идем, монысы кебек тиз генә язып ташларга дип. Юк, энем, һәрвакыт алай булмый икән. Бер атна маташтым, кул селтәдем. Табылса табыла, табылмаса, берни эшләп булмый, хет ярыл.*

*Сезгә тапшырам хәзер. Сәлам белән Сибгат Хәким. 8 октябрь, 1980».*

Миңа Сибгат аганың җитмеш яшьлеге уңаеннан Мәскәүнең Язучылар йортында үткәрелгән зур кичәдә катнашу насыйп булды. Шагыйрьнең үзе белән бергә зур төркем артистлар да барды анда. Кичәгә Мәскәүдән һәм илнең төрле өлкәләреннән килгән күренекле шагыйрьләр һәм язучылар катнашты. Шунда без тагын бер кат укучыларның шагыйрьгә булган мәхәббәтен, ә илебез язучыларының аңа карата булган хөрмәтен күреп сөенгән идек. Кичә зур уңыш белән узды. Сибгат ага барлык катнашучыларны аерым-аерым тәбрикләп, рәхмәт сүзләрен белдерде.

Гомумән, ул һәр әдәби кичә яки концерттан соң башкаручыларга ниндидер аерым җылы сүз таба белә иде (шагыйрьнең «Җылы сүз» исемле әсәре дә, шул исемдәге китабы да бар).

Бервакыт ул миңа шылтыратып: «Айрат, сүз жанры турында бездә бик аз һәм бик саран язалар, Мәскәү матбугатында зур әдәбиятны пропагандалаучылар турында мин кызыклы, төпле мәкаләләр укыганым бар. Уйладым да татарда сүз сәнгатенең торышы турында язарга кирәк дигән фикергә килдем. Шунда Сезнең иҗат турында да тулырак әйтеп булыр иде, ничек уйлыйсыз?» — диде.

Әлбәттә, мин шагыйрьнең вакыт табып, сәнгать белгече сыйфатында шундый кайгыртучанлык күрсәтергә теләге барлыгына бик сөендем һәм рәхмәтемне белдердем. Ләкин бу 1985 елның урталары иде, шагыйрьнең сәламәтлеге шактый какшый башлаганы сизелә иде. Әмма ул оптимистик рухта язган хатларын җибәрә торды. Шул елның декабрь башында Сибгат аганың иҗат кичәсе үткәннән соң, мин мондый хат алдым:

*«Айрат! Зәйнәп шылтыратты* (Зәйнәп Шәйхулла кызы Хәйруллина. — *А.А.). Айрат икеләтә үскән, ди. Мин әйтәм: ул болай да озын. Юк, иҗатта, ди. Әйбәт номер Сезгә эләккән. Теш врачына барган идем, Мәдинә исемле туташ. Ул да шул сүзләрне кабатлады. Бигрәк тә ике әсәр: «Уналты йорт безнең тыкрыкта» һәм «Бер йотым су». «Татар гармуны»н да Сезгә калдырам, үзем башка сөйләмим. Сезнең белән тулы булды кичә. Шулай осталык, еллар үтү белән, арта бара шул. Инде Тукайның йөз еллыгына үзем өчен генә язып барган парчаларны Сезгә тәкъдим итәм. Миндә бер зур дәфтәр алар. Бөтенесен әле бирмим, бераз вакыт үтсен, кемнәргәдер ошамас та кебек. Яткан малда бәрәкәт, ди.*

*Сезнең кәеф яхшыруга мин бик шатмын. Эшлик әле, языйк әле. Сибгат абый сүзендә тормый дип уйламагыз. Мин әйтсәм, эшлим. Настроение күтәп йөрим. Язгач-язгач, хуҗасына лаек булсын. Бераз көч керсен әле. Үзем звонокка басармын.*

*Уңышлар теләп, сәламәтлек теләп, сәлам белән Сибгат Хәким. 5/XII. 1985».*

Шул ук декабрь аеның ахырларында язган хаты эчендә Сибгат ага миңа сигезьюллык шигырен дә салган иде. Бу шигырендә шагыйрьнең фронтта булган елларыннан алып саулыкка туя алмавы чагылган. Аның башка хатлары гел оптимистик рухта языла иде, ул һаман безнең сәламәтлекне кайгыртып яза, һәрвакыт күңелне күтәреп җибәрә торган җылы сүзләр таба белә иде. Ә менә бу сигезьюллык шагыйрьнең эчке халәтен ачып биргән кебек булды, үзе белән очрашканда бер «серен» дә чишмәүче Сибгат аганың сәламәтлеге турында тирән уйландырды. Бу юллар моңа кадәр беркайда да басылмады кебек, шуңа күрә мин аларны мәкаләмә кертергә булдым:

**Айратка**

Калинин сазлыкларыннан
Чыга хәзер үткәннәр,
Гармун мехлары шикелле
Хәзер минем үпкәләр.
Суласам, сулышым җитми,
Дәваларга ысул тап.
Пәке тыккан мехлар кебек
Ябылалар пышылдап.

*1985. С.Х.*

Әле 1986 ел башында язган ике хатында да гел иҗат мәсьәләләре турында сүз алып бара, миңа яңа әсәрләрен җибәрә, минем сәламәтлегем яхшыра баруга үзенең шатлык хисләрен белдерә иде.

Ләкин бу ел аның соңгы елы булыр дигән уй башыбызга да килмәде. Җәй аенда Сибгат ага хастаханәгә кергәч, аның янында булдым, шулай ук «сер бирмичәрәк» гел елмаеп сөйләште, эшләрем белән кызыксынды. «Сибгат абый, ай ярымга Кырымга барам» дигәч, «Бар, бар, сиңа анда бару бик кирәк, көч җыеп кайт...» диде.

Иң яраткан шагыйрем, иҗатташ олы дустым һәм остазым белән соңгы очрашу дип һич кенә дә уйламаган идем. Мин Ялтада ялда вакытта өйдән июль башында Сибгат ага вафат булды дигән кайгылы хәбәр алдым. Бик авыр кичердем, якын туганыңны югалту белән бер иде бу югалту. Менә шуннан бирле Сибгат аганы гел сагынып яшибез. Шагыйрь 1970 елда минем иҗатым турындагы мәкаләсендә болай дип язды: *«Халыклар, культуралар аралашты, масштаблар зурайды, таләпләр үсте. Хәзер үзеңә бик нык ышанган хәлдә генә зур аудиторияләр каршына чыгып басарга мөмкин. А.Арсланов күп төбәкләрдә татар поэзиясен яңгыратып йөргәндә миңа да бик күңелле...»*

Сибгат Хәкимнең талантлы, гуманизм белән сугарылган олы поэзиясен без әле яңгыратырга тиешбез, ул бездән соң да озак яңгыраячак!

*2001*

Моң тулы язмыш

Халкыбыз композитор Сара ханым Садыйкованы сихри авазлар тудыра белүче тылсым иясе буларак ярата һәм олылый.

Аның композиторлык иҗаты республикабызда, илебездә һәм чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез тарафыннан югары бәяләнде. Ул үз гомерендә бик күп җырлар иҗат итте, аларның саны берничә йөзгә җитә. Җырчыларыбыз, үз зәвыкларына карап, репертуарларына композиторның лирик җырларын да, гражданлык хисләре ташып торган, Ватан, хезмәт, тынычлык темасына язылганнарын да, Бөек Ватан сугышы турындагы җырларын, кеше язмышы һәм мәхәббәт темасына язылганнарын да бик теләп сайлап алалар. Сара Садыйкова җырлары эстрада сәхнәсендә иң күп башкарыла торган әсәрләрдән саналалар.

Сара ханым тамашачыларның зур хөрмәтен яулаган җырчы һәм драма артисты да була. 30 нчы елларда ук Татар драма театрында куелган «Зәңгәр шәл», «Кандыр буе», «Ил», «Галиябану», «Сүнгән йолдызлар» кебек сәхнә әсәрләрендә, «Сания», «Эшче» опералары, Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында оешкан Татар опера студиясен тәмамлагач, «Качкын» һәм башка операларда ул тудырган образларны өлкән яшьтәге тамашачылар әле дә зур хөрмәт белән искә алалар. Кыскасы, Татар дәүләт опера һәм балет театры тарихында да Сара Садыйкованың мактаулы үз урыны бар.

Композитор республикабыздагы һәм күрше өлкәләрдәге күп кенә шәһәр һәм районнарның, авылларның да үз, хөрмәтле кешесе иде. Ул авыл хезмәтчәннәре алдында яратып чыгышлар ясый һәм аларны эшкә дәртләндерүче җырлар иҗат итә иде. Арча, Минзәлә, Актаныш һәм башка районнарга багышланган җырлары фәкать киң аралашу нәтиҗәсендә дөньяга килгән әсәрләр дип беләбез. «Арча кичләре», «Актаныш таңнары», «Балкый Шәйморза утлары», «Балтачым» һ.б. тыңлаучыларның яраткан җырларына әверелделәр. Шулай ук төрле авылларга багышланган «Уразай», «Тутай», «Мөслим тугайлары», «Чынлы» һ.б. җырлары — композиторның авыл халкына тирән мәхәббәт хисләре белән язылган әсәрләре.

Композиторны КамАЗ төзелешендә дә еш очрата торган идек. Аның белән бергә Чаллының концерт залларында чыгыш ясауларыбыз истә калган. КамАЗ төзүчеләре Сара ханымның чыгышларын яратып каршы алалар һәм аның иҗаты белән тирән кызыксыналар иде. Аның милли сәнгатебезне үстерүдә күрсәткән хезмәтләре барлык сәнгать әһелләре, бигрәк тә яшьләр өчен, иҗатта батырлык үрнәге булып торды.

Сара ханым белән беренче танышуым Татарстан радиосында эшли башлаган вакытларда булды. Мин әле Казанда театр мәктәбендә укыган вакытта, 1948 елда, радиога диктор булып эшкә кердем. Беркөнне радиокомитет коридорында дикторыбыз Васфикамал Саттарова белән сөйләшеп торганда, кайсыдыр редакциядән пөхтә генә киенгән бер ханым килеп чыкты, ул Васфикамал белән бик матур елмаеп исәнләште, туктап бераз сөйләшеп торды. Шунда В.Саттарова: «Ә бу безнең яңа яшь дикторыбыз Айрат Арсланов була», — дип, минем белән дә таныштырды. Театр мәктәбендә укуымны белгәч, Сара апа бик ачык йөз белән педагогларым турында сорашты, Казанга кайсы яклардан килүем белән кызыксынды.

— Тавышыгыз матур ишетелә, радио өчен мондый тавыш бик кирәк, тырышып эшләгез. Без Васфикамалны бик яратып тыңлыйбыз, моннан соң сезне дә игътибар беләнрәк тыңлармын, эшегездә уңышлар телим... — диде.

Без аның белән радиокомитетта сирәк кенә булса да очраша торган идек. Ләкин аның радиоконцертларга килеп җырлаганы ничектер исемдә калмаган. Ул вакытларда магнитофоннар юк иде әле, артистлар яки музыкантлар үзләре студиягә килеп чыгышлар ясыйлар иде. Ә инде күп кенә музыкаль әсәрләр, җырлар тонфильм язмасында саклана иде.

Шулай бервакыт Сара апаның радиокомитеттан күңелсез генә чыгып килгәнен күрдем, аның белән исәнләшеп, хәлен сораштым. Ул: «Менә радио хуҗаларына килгән идем әле, бераз әйтешеп чыгып киләм, соңгы вакытларда минем язмаларымны радиодан бирми башладылар. Ә бит минем тонфильмга язылган күп язмаларым саклана. Менә шул хәлләр бик эчемне пошыра, заманында бит мин халкымның яраткан җырчысы идем...» — диде.

Сара апа белән шушы сөйләшүдән соң мин тонфильмда аның нинди язмалары барлыгы белән кызыксына башладым. Баксаң, аның дистәләрчә язмасы бар икән, шулар арасында «Салкын чишмә», «Зөлхиҗҗә», «Уел», «Ашказар», «Айһайлүк», «Эрбет», «Карабай» һ.б. җырлары саклана икән. Эштән бушаган вакытларда мин операторлардан аларның кайберләрен уйнатып караганым булды. Ул язмалар яшь матур тавыш белән бик яңгырашлы итеп язылганнар иде. Ул вакытларда мин язмаларны эфирга бирмәүнең сәбәбен, әлбәттә, төшенеп тә бетмәгәнмен. Вакытлар үтү белән Сара ханымның җыр сәнгатенә, аның композиторлык иҗатына кирәкле, дөресрәге, тиешле бәя бирелмәүнең, алай гына да түгел, аның иҗади эшенә аяк чалучылар барлыгын ишетеп белгәннән соң гына бу хәлләрне аңлый башладым. Дөресен әйткәндә, «торгынлык еллары»нда кайбер талантларга ярдәм итү, аларны иҗат эшләренә рухландыру бик чамалы иде шул. Киресенчә, аларга җиң сызганып эшләргә комачаулаучы көчләр барлыгына күпләребез шаһит иде. Сара ханым Садыйкова композитор исемен алуга озак еллар буе фидакарьләрчә, төшенкелеккә бирелмичә, тынгысыз хезмәт нәтиҗәсендә генә ирешә алды. Бүгенге көндә татар радиосында заманында Татар драма театрының һәм операсының күренекле җырчысы булган С.Садыйкованың үзе башкаруында бер генә әсәре дә яңгырамавы, әлбәттә, шул «торгынлык еллары» дип аталган чорның бер тискәре күренеше ул. Әгәр ул башкарган әсәрләр тонфильмнан магнитофон тасмаларына язып алынып, киләчәк буын тыңлаучылары

өчен дә саклансалар, мәдәни байлыгыбыз тагын да зуррак булыр иде бит. Бер С.Садыйкова башкарган әсәрләр генә түгел, башка танылган башкаручыларның әсәрләре белән дә шундый саксыз эш итүләр ул чорның ямьсез яклары булып истә калды.

50—60 нчы елларда Казанның Бауман урамындагы Матбугат йортында урнашкан Г.Тукай клубына иҗат кешеләре, әдәбиятка, сәнгатькә гашыйк яшьләр йөриләр иде. Тукай клубын ул чакларда татар зыялыларының кәгъбәсе дип тә атыйлар иде. Безгә, яшь артистларга да, еш кына анда төрле кичәләрдә катнашырга туры килде. Сара апа белән сәхнәдә беренче очрашуым шул клубта булды. Соңрак С.Садыйкованың шунда ук үткәрелә торган иҗат кичәләрендә дә булырга туры килә иде. Ул кичәләргә халык шулчаклы күп килә иде, залга сыеша алмыйча, коридорда басып торып тыңлаучылар да бихисап була иде.

Сара ханым белән Казан дәүләт университеты һәм педагогия институтының актлар залларында бергә куйган концертлар да хәтеремдә. Бу кичәләрдә, әлбәттә, Сара ханымның якын дуслары шагыйрь Сибгат Хәким, җырчы Фәхри Насретдинов, композиторлар Заһид Хәбибуллин, Александр Ключарев та булалар иде. Сәхнәгә чыгар алдыннан Александр Сергеевич: «Саруш, ты сегодня покороче говори, а то концерт затянется...» — дип шаярта торган иде. Сара ханым аңа елмаеп баш кага, ә сәхнәгә чыгу белән, дөньясын онытып дигәндәй сөйли, аудитория белән аралаша, аңа төрле яктан сораулар ява башлый, һәм Сара ханым үз «стихиясе»нә чума иде. Ул Солтан Габәши хорында беренче башлап җырлавын, ничек итеп Мәскәү консерваториясенә укырга китүен, Мәскәүнең Эшче театрында эшләүләрен, Казанда Татар академия театрында, ә консерваториядән соң Татар опера һәм балет театры ачылу белән опера спектакльләрендә җырлавын бик кызык һәм мавыктыргыч итеп сөйли торган иде. Ә залдан сораулар һаман ява тора, аның композиторлык иҗаты турында, нинди яңа әсәрләр язуы, җырларның ничек тууы турында сөйләвен үтенәләр, ә Сара ханым бер дә армый, елмаеп-көлеп сорауларга җавап бирә...

Сара ханым концертларда үзе белән бергә чыгыш ясаучыларның һәрберсе белән бик җылы мөгамәләдә була, һәрбер артистның, бигрәк тә үзенең әсәрләрен башкаручыларның чыгышларын игътибар белән тыңлый, кирәк чакта үзенең кайбер киңәшләрен бирә торган иде. Минем сәхнәдә башкарган әсәрләр турында да Сара апа үз фикерләрен әйтми калмый иде. Ул, гомумән, яшьләр иҗатына һәм шул җөмләдән минем сәхнә эшчәнлегемә дә хәерхаһ кеше иде, мин аңа моның өчен гомерем буе рәхмәтле булдым.

Әйе, Сара ханым кебек телебезне камил белүче сәнгатькәр, шигъри сүзнең, туган телнең тәмен тоеп, аның белән үз иҗатында игътибарлы, сак эш итүче кешеләр сирәгрәк очрый шул сәнгатьтә. Телебезнең бөтен нечкәлекләрен белеп бетермәгән, аның яңгырашына, моңына гашыйк булмаган сәнгать кешесенең тыңлаучыларның дикъкатен җәлеп итәрлек әсәрләр тудыра алуына ышанып бетеп булмый. Шуңа күрәдер татар һәм башкорт шагыйрьләреннән Сара ханымның дуслары күп булгандыр да.

Аның дусты һәм иҗатташы Сибгат ага Хәким болай ди торган иде: *«Әле бу көннәрдә тагын Сара Садыйковада булган идек, үзебезнең яңа язылган җырларыбыз турында озак кына сөйләшеп утырдык. Ул миңа тагын берничә яңа әсәрен башкарып күрсәтте. Аның бу кадәр армый-талмый эшләү сәләтенә таң калам».*

Чыннан да, Сара ханым һәрвакыт туктаусыз хәрәкәттә иде.

*«Бүген Казан опера театрында яңа әсәрен әзерләсә, бер атнадан ул башкорт драматургы язган әсәргә көе белән булышырга Уфага ашыга...* — ди торган иде Сара ханым турында Сибгат Хәким. — *Менә кайдан ул җырдагы романтика, эшкә, хезмәткә дәртләндергән якты рух, илһам!»*

Чыннан да, Сара ханымның эш процессында булсын, тормышта булсын, дуслары ифрат күп иде. Аның фатирыннан кеше беркайчан да өзелеп тормады. Ул үзенең бәхетен кешеләр белән аралашып, иҗат ялкыны белән яшәүдә тапты.

Сара Гариф кызы Садыйкованың җиңел булмаган, шул ук вакытта сокландыргыч иҗат гомере милли сәнгатебездә эшләүчеләрнең һәркайсына зур батырлык үрнәге булып тора. Аның язмышы — моң тулы язмыш.

*2004*

## Татар моңының кәккүге

Афәтләрдән тартып ал да
Асылыма кайтар мине —
Халык кадәр халыкны син
Яшәртәсең, татар җыры!

*Харрас Әюп*

Һәр халыкның үзенең илаһи моңы, гасырлар буена җырланган халык җырлары була. Һәр халык үзенең акыннары, ашуглары, чичән-шагыйрьләре авызыннан үз тарихын, эпосларын, моңлы җыр-бәетләрен борын-борыннан яратып тыңлаган. Без, телләрен аңламасак та, ни өчен грузиннарның хор белән җырлана торган йөрәкләргә үтеп керүче моңлы җырларын, азәрбайҗаннарның ашуглары башкаруында тирән моң

тулы мәкамнәрен, һинд халыкларының йөрәкләрне айкый торган моңнарын ишетеп тын калабыз, бирелеп тыңлыйбыз, һәм һәр халыкның тирән моңы безне дулкынландыра, төрле уйларга чумдыра... Татар халкының да борынгыдан килгән үз моңы, үз аһәңе, халык күңеленең төпкеленнән туган тирән мәгънәле, һәр тыңлаучыны дулкынландыра торган җырлары, бәетләре, озын көйләре бар. Бездән еш кына бигрәк тә башка милләт кешеләре «Нәрсә соң ул моң?» дип сорыйлар. Без булдыра алган хәтле аларга бу төшенчәне аңлатырга тырышабыз. Бу төшенчә турында күренекле язучыбыз Гомәр ага Бәшировтан да остарак итеп аңлатма биреп булыр микән? Язучы бу турыда бик төгәл һәм ачык итеп:

*«Моң, моңаю, моңсу дигән сүзләрнең үзләрен аңлауга килгәндә, моң бит ул зарлану да, кайгы-хәсрәт чигү дә, өзгәләнү, иңрәү дә түгел. Мәгълүм ки, табигатьнең гүзәллеген аңлаучы һәм аны сөюче нечкә күңелле кешене сандугач сайравы белән күке кычкыруы да, челтерәп аккан чишмә тавышы да, алсуланып таң беленеп килүе дә, хәтта кызгылт-сары япанчасын бөркәнгән көзге урман да моңландыра. Әйе, кеше моңая, бер мәлгә аның тел белән әйтеп булмастай иң нечкә күңел кыллары тибрәнеп ала, йөрәге сулкылдап куя, хәтта кайберәүләрнең керфек төпләре дә дымланып өлгерә. Ләкин бу зарлану да, елаклык та, кайгы-хәсрәт тә, кайберәүләр уйлаганча төшенкелеккә бирелү дә түгел. Юк. Бу кешенең гадәти бер кичереше, көяшлы яңгыр кебегрәк бер күренеш. Бу — туган якларыңа, халкыңа, үзеңне әйләндереп алган табигатькә, якын кешеңә булган зур мәхәббәтнең аеруча бер нечкәреп, дулкынланып алу моменты. Мондый минутларда кешенең күңеле, вак-төяк тормыш ыгы-зыгысыннан арынып, үзенә бертөрле пакьләнеп һәм сафланып кала түгелме соң?! Әгәр дөньяда берничә дә күңеле нечкәрми, беркайчан да дулкынланмый һәм моңаймый торган таш бәгырьле кешеләр генә калса, тормыш ифрат та җансыз һәм күңелсез булыр иде»,* — дип әйтте.

Әле Октябрь революциясенә кадәр татар сәхнәсендә эстрада жанрын үстерүгә хезмәт куйган артистлар булган. Татарның аерым җырчылары ил буйлап гастрольләргә чыга торган булганнар. Шулардан тамашачылар яраткан җырчылар Фәттах Латыйпов, Газиз Әлмөхәммәтов, Камил Мотыйгыйлар була. 1911—1912 елларда сәхнәгә чыгып халык көйләрен җырлап танылган Абруй ханым да заманында популяр башкаручы була. Халкыбызның талантлы уллары — гармунчы Фәйзулла Туишев, пианист Заһидулла Яруллин, скрипка осталары Хәбибулла Әхмәдуллин, Мөхәммәт Яушевлар — татар эстрада концертларында халык көйләрен оста башкарулары белән танылалар. Шулай акрынлап еллар үткән саен, сәхнәгә яңа башкаручылар, җырчылар килә. Югарыда исемнәре аталып үткән җырчылар һәм музыкантларны бик бирелеп тыңлап, алар башкарган көйләрне ишетеп, өйрәнеп, үзе дә җыр дөньясына атлап керүчеләр арасында Гөлсем Нурмөхәммәт кызы Сөләйманова да була. Татар җырына булган зур мәхәббәте Гөлсемне 13—14 яшеннән үк халык арасында таныта башлый. Үзенең үзенчәлекле моңлы тавышы белән күпләрне җәлеп иткән яшь җырчы татар җыр сәнгатендә тора-бара үзе бер дәвер тәшкил итә.

Бу талантлы, халык яратып «татар җыры фәрештәсе» дип атаган моң иясенең тавышын беренче тапкыр кайчан ишеттем икән дип уйланып утырам. Үткән гасырның 40 нчы еллары... Башкортстанның Балтач районында урта мәктәптә укыган вакытлар. Өйдә диварда кара катыргы тәлинкәләр эленеп тора. Шул радионокталар аша Мәскәүне, Өфене, Казанны тыңлыйбыз. Безнең район саф татар районы булганлыктан, әлбәттә, Казан тапшыруларын халык көтеп ала. Менә шул тапшырулар аркылы яраткан җырчыларыбыз Г.Сөләйманова, Р.Ваһапов, Ф.Насретдинов, М.Рахманкулова, У.Әлмиев һ.б. җырчылар иҗаты белән таныштык. Гөлсем апа Сөләймper Сөләйманованың затлы моңын беренче тапкыр Татарстан радиосы ирештергән икән. Ул башкарган «Гөлҗамал», «Әллүки», «Сәгать чылбыры», «Аппакай-алмакай», «Уел», «Илче бага», «Хафизәләм иркәм» һ.б. җырлар белән сихерләнгән еллар бит ул. Гөлсем апаны бигрәк тә өлкәнрәк яшьтәгеләр бик яратып тыңлыйлар иде, аның радиоконцертларын күрше хатын-кызларның бергә җыелып тыңлаганнары да истә калган. Әнкәем дә Гөлсем апаның җырлавына мөкиббән кеше иде. «Кайлардан гына килә икән бу Гөлсем Сөләймановага моң, сагыш, биргән икән Ходай үзенә тавышны-моңны...» — дия торган иде. Аннары: «Эх, шул Гөлсемне бер барып күрәсе иде, кулын кысып рәхмәт әйтәсе иде. Кая инде ул Казаннарга барып аны күрүләр...» — дип өстәп тә куя иде.

Еллар үтеп, 40 нчы еллар ахырында үзем дә Татарстан радиосында Гөлсем ханым Сөләйманова белән бергә эшли башлагач, әнкәйнең бу хыялы тормышка ашар дип ул елларда башыбызга да килмәгән. 50 нче еллар башында әнкәйне дәваланыр өчен Казанга алып килдек, аны һәр көнне диярлек Горький урамы буйлап ГИДУВка алып барам, юлыбыз радиокомитет турысыннан үтә. Көннәрдән бер көн радионың ачык тәрәзәсеннән Гөлсем Сөләйманованың җырлавы ишетелә, әнкәм барган җиреннән туктап калды.

— Гөлсем җырлый түгелме соң? — дип сорап куйды.

— Әйе, — мин әйтәм, — аларның репетиция вакыты хәзер, тиздән алар бушаячаклар, әйдә, әнкәй, мин сине Гөлсем апа белән таныштырам, — дим.

Әнкәмнең шатлыгы йөзенә чыкты, бу очрашу турында күпме хыялланган иде бит ул. Кердек, репетиция беткәнен бераз көтеп тордык. Гөлсем ханым радионың концертмейстеры Екатерина Александровна Соколова белән безне бик җылы каршыладылар. Аларны әнкәм белән таныштырдым.

— Мәрьям апа сез буласызмыни? — дип, Гөлсем апа әнкәйне кочаклап алды, — Айратның сезнең турыда сөйләгәне бар.

Алар бик тәмләп, ашыкмыйча гына сөйләшеп алдылар, әнкәйнең бу очрашудан бик тә канәгать булуы күзләреннән күренеп тора иде.

Хушлашып чыгып барганда, Гөлсем ханым:

— Мәрьям апаны безгә дә алып кил, чәй янында рәхәтләнеп сөйләшербез, — дип калды.

Әнкәй бу очрашудан бик мәмнүн булды.

Гөлсем апа Сөләйманова, эшендә булсын, тормышта булсын, үтә дә гади, кечелекле, кешеләргә ярдәмгә килергә әзер торучы шәхес иде.

Гөлсем апа белән бергә эшли башлаган елларда радиода магнитофоннар юк иде әле (алар соңрак, 1952 елда пәйда булдылар), һәр көнне концертка җырчылар һәм музыкантлар иртәнге сәгать алтыга килеп җитәләр иде. Концертка иң беренче булып килүче Гөлсем апа була иде. Соңга калып килүчеләрдән концертмейстер, баянчы Мохтар Әхмәдиевне бераз яклагандай итеп, Гөлсем апа: «Зинһар, борчылмагыз, Мохтар кичә районнан концерттан кайтты, хәзер килеп җитәр», — ди торган иде. Чыннан да, берничә минуттан ашыга-ашыга Мохтар килеп җитә, һәм бераздан концерт башлана иде. Гөлсем ханым катнашкан концертларны без барыбыз да көтеп ала идек. Җырчыдагы тирән моң, табигать тарафыннан бирелгән, бик сирәк очрый торган матур аһәңле тавыш, соклангыч ачык дикция татар һәм башкорт халыкларының җыр хәзинәсеннән иң асыл, үтә дә гүзәл үрнәкләрен уңышлы башкарырга мөмкинлек бирә.

Республикабызда радио 1927 елның ноябрендә татар телендә сөйли башлый, ә 1928 елдан радиода әдәби-музыкаль һәм сәяси тапшырулар редакцияләре даими эшли башлый. Менә шул елдан алып 1958 елга кадәр, утыз ел дәвамында, Гөлсем Сөләйманова Татарстан радиосының беренче солисткасы була.

Аның репертуарында халык җырлары һәм композиторларыбыз әсәрләре бихисап иде. Һәр тыңлаучыда бу гүзәл һәм тирән хисле җырларны җырчы кай арада өйрәнеп бетерә икән дигән уй тугандыр. Гөлсем Сөләйманова репертуарында татар халык җырлары һәм композиторлар әсәрләре белән бергә башкорт халык көйләренең дә зур урын алуын әйтеп китәсе килә. Ул башкарган «Таштугай», «Карабай», «Эскадрон», «Сибай кантон», «Җуача», «Шәл бәйләдем», «Баек» һ.б. күп җырлар радиотыңлаучылар һәм эстрада концертларына килүче тамашачылар тарафыннан бик җылы каршылана, кайнар алкышларга күмелә иде. Гөлсем ханым Сөләйманова белән миңа радио концертларыннан тыш эстрада концертларында, Татарстан радиосы төрле районнарда, шәһәрнең югары уку йортларында, мәктәпләрдә үткәрә торган радиотыңлаучылар конференцияләрендә еш кына бергә чыгышлар ясарга туры килгәне бар. Гөлсем Сөләйманованың исеме җырчы үзе исән вакытта ук легендар исемгә әйләнгән иде, аның чыгышлары һәрчак, һәркайда зур уңыш белән үтә иде.

Гөлсем Сөләйманованы күрергә дип радиога еш кына Казан кешеләре яки авыл кешеләре килеп керә иде. Гөлсем ханым үзе радиода булса, алар белән бик теләп очраша торган иде. Шулай ук радиога җырчыга адресланган күпсанлы хатлар килә иде. Язучыларыбыз, композиторларыбыз, журналистлар үзләренең мәкалә-язмаларында җырчының татар җыр сәнгатен үстерүдә куйган хезмәтләренә югары бәя бирәләр. *«Бүген радиодан Гөлсем Сөләйманова җырлаганны тыңладык,* — дип яза үзенең «Көзге ачы җилләрдә» дигән повесть-истәлегендә халык язучысы Гомәр Бәширов. — *Аның тавышы, минемчә, татар халык көйләрен җырларга, аның моңын бирүгә иң лаек тавыш. Ул халыкның моңын гына түгел, психологиясен, көнкүрешен, тарихын, нинди халык булуын, кыскасы, аның эчке дөньясын тирәнтен сизеп, аңлап, кичереп җырлый. Тагын бер үзенчәлеге бар: ул сүзләрен музыкага буйсындырып, дөрес итеп әйтергә тырыша, кайбер башка җырчылар кебек, көйнең дөрес агылышын саклыйм дип, сүзләрне тегеләй дә, болай да гарипләндереп ташламый. Шунлыктан без аны чын күңелдән яратып, сокланып тыңлыйбыз».* Гомәр ага Бәширов үз гомерендә сәнгать кешеләренә мондый җылы сүз әйтүгә бер дә саранланмады.

Гөлсем ханым белән әңгәмә вакытларында аңардан «Сәнгатьтә беренче укытучыларыгыз кем иде?» дип сорый торган идек. Ул болай дип җавап бирә иде: «Минем язмышымда, тормыш юлымны ачыклауда, сәнгатьтә үз урынымны табуда зур ярдәм иткән шәхес — оста музыкант һәм композитор Солтан Габәши булды. Мин башлангыч мәктәптән соң педагогия техникумында укыдым. Музыкаль сәләтемне ачуда, әлбәттә, музыка укытучыбыз, оста пианист Солтан Габәши зур ярдәм итте, мин аңа бурычлымын. Берничә елдан соң мин аның тәкъдиме белән Казан музыка техникумында укый башладым, ул вакытта Габәши техникумда уку-укыту бүлеге җитәкчесе булып эшли иде, без аңардан музыка теориясеннән дәресләр алдык. Ә җыр-вокал дәресләрен оста җырчы-педагог Е.К.Ковельковадан алдым. Ул заманында мәшһүр рус җырчысы Ф.И.Шаляпин белән бергә җырлаган билгеле опера җырчысы була. Минем озын иҗат юлымда очраган булышчан, мәрхәмәтле затлар — композиторлар, музыкантлар, артистлар күп булды. Мин аларны һәрвакыт зур рәхмәт хисләре белән искә алам». Композиторлар М.Мозаффаров, А.Ключаревлар белән берлектә Г.Сөләйманова татар халык җырларын, фольклор әсәрләрен җыйнап альбомнар чыгаруда да зур хезмәт күрсәтә. Аны А.Ключарев: *«Гөлсем Сөләйманова — татар музыкасының җәүһәре»,* — дип олылый.

Г.Сөләйманова тырыш хезмәте, югары дәрәҗәдәге сәнгать осталыгы өчен 1939 елда Татарстанның атказанган, ә 1957 елда республикабызның халык артисты дигән дәрәҗәле исемнәр алды, 1950 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде. Аның белән бергә эшләгән кешеләр барысы да Гөлсем ханымны тырыш хезмәте, югары профессиональлеге, тормышта самими кешелек сыйфатлары өчен яраталар һәм хөрмәт итә иделәр. Татарстан радиосында аның белән бергә озак еллар эшләгән, Татарстанның атказанган

сәнгать эшлеклесе З.Ш.Хәйруллина җырчы иҗатына югары бәя бирә: *«Г.Сөләйм登ованың хезмәте зур. Татар җыр сәнгатендә ул үзенә бер дәвер. XX гасыр башында сәхнәгә күтәрелгән җырчы-музыкантлар, халык талантлары белән бергә ул профессиональ музыкага нигез салучылар белән бер сафта торучы күркәм зат. Милли музыкабыз казанышларын киң мәйданга чыгаруга, сәнгатебезнең төрле милләт халыкларының мәхәббәтен яулавына да ул бик зур өлеш кертте».*

С.Габәши үзенең «Кәккүк» җырын беренче башкару өчен Г.Сөләймановага бирә, җырчы аны искиткеч оста башкарып, татар җыр сәнгатенең энҗесенә әйләндерде, һәм үзе дә татар моңының кәккүге булып мәңгегә халык күңеленә кереп калды.

*2006*

## Шагыйрьне сагыну

Минем кулымда Хәсән Туфанның Татарстан китап нәшриятында 1958 елда чыккан шигырьләр җыентыгы. Китап Хәсән аганың яраткан төсе — яшел тышлыкта чыгарылган. Аның беренче битендә шагыйрьнең үз кулы белән язып биргән автографы: *«Кадерле Айрат Арсланга. Казанда икенче кат яшәгән көннәремдә бер истәлек. Х.Туфан. 19.VII.58».* Автографын да Хәсән ага яшел кара белән язган... Аның китапларын киштәдән бик еш алам мин. Шигырьләрен барысын да яхшы беләсең, алар барысы да сиңа яхшы таныш кебек. Ләкин тагын, тагын бер кат укыйсы килә. Чын поэзия алдында адәм баласы көчсез шул...

Бу уй башыма Х.Туфан шигырьләрен укыганда килде. Күптән инде. Һәм менә шуннан бирле мин чын шигърият алдында көчсезлегемне сизәм. Рухи көчсезлек тә түгел бу, физик көчсезлек тә түгел, нәрсәдер инде шунда, исем дә табалмыйм аңа. Шагыйрь сине буйсындыра, үзе белән синең уй-күңелеңне әллә кайларга алып китә йә синең күзләреңне дымландыра, йә тирән уйга сала, яки елмайта, яки рәхәтләндереп көлдерә. Син, синең акылың ирексез бу чакта. Юк, дисең, укымыйм, кирәкми, дисең, ләкин ирексездән китап битләрен актарасың, кулларың сиңа буйсынмый, һәм менә шушы буйсынмаудан син тәм, ләззәт тапкандай буласың.

Менә шундый чакларда шигърияткә тагын бер мәртәбә баш иям мин. Бер дә гаепсезгә хөкем ителеп төрмә, сөрген газапларын кичергән кеше бар дөньяга үпкәле булырга тиеш иде югыйсә. Язарга ихтыяр көче тапса да әле, бары моң-зарын язарга тиеш сыман иде адәм баласы. Әмма шагыйрь рухы көчле шул! Хәсән ага белән күп еллар иҗади хезмәттәшлек итәргә, күп очрашуларда булырга туры килде, әмма аның беркайчан да төрмәдә күргән газап-михнәтләре турында исенә төшергәне булмады. Ләкин бер мәртәбә тар даирәдә шагыйрьнең моңланып үз башыннан кичергән кайбер хәлләр турында сөйләгәнен ишеттем. Болай булды ул. 70 нче еллар башында татар язучылары һәм сәнгать әһелләре Мәскәүдә язучыларның үзәк йортында уздырыла торган зур кичәгә бардык. Поездда мин Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Шәйхи Маннур белән бер купега туры килдем. Юл ярыйсы гына озын, вакыт бар, чәй өстәле янында озак кына сөйләшеп бардык. Әңгәмәдәшләремнең барысы да әдәбиятыбызның аксакаллары, ә мин алар янында яшь кеше, күбрәк аларны тыңлап, кайбер сорауларымны гына биреп утырдым.

Менә шул чакта Хәсән ага, иелә төшеп утырган хәлдә, акрын гына тавыш белән, үзенең төрмә тормышыннан бер эпизод сөйләгән иде. Аны тыңлаганда, тамакка төер утырып, күзләрдән яшь килгәне әле дә хәтеремдә.

— Бервакыт ялгызымны гына аерым камерага яптылар, — дип тартынып кына, болай сүз арасында гына әйтеп киткәндәй сөйли башлады Хәсән ага. — Утырам ялгыз башым моңаеп, шулхәтле эч поша, бер генә җан иясе дә юк, хәтта надзирательләр дә ишектәге «күз» янына килеп караганда, тоткын тереклек тавышын тоймасын өчен итекләрен салып, оекбашчан йөриләр, шулай тавыш-тынсыз гына килеп, бу нишләп утыра икән дип кызыксыналар. Нишләп утырыйм ди инде? Моңланам, эч поша, йөрәк яна, җан сызлый, тагын әллә нәрсәләр инде...

Шунда ачык тәрәзәдән камерага чебен очып керде. Шатлыгымнан елап җибәрдем. Чебен генә булса да, җан иясе бит. Чебен әрле-бирле очып йөрде дә, ай-һай, монда бигрәк шыксыз икән дигәндәй, очып чыгып китте. Рәхмәт аңа, ташламады ул мине, көн саен дигәндәй кергәләп, дөньялыкны исемә төшереп торды. Чебен озак яшәми бит, беркөнне ул да керми башлады. Рәхмәт төшкере, чебен артыннан ук камерага бер тычкан ияләште, каяндыр чыгып йөри-йөри дә аннары тагын кереп югала, ә мин рәхәтләнеп аны күзәтеп утырам, киткәндә, тагын килсә ярар иде, дип борчылып калам. Җан иясе шул, кәефләр күтәрелеп китә иде.

Менә шуларны сөйләгән иде безгә Хәсән ага.

Хәсән Туфанның хатыны Луиза Салиәскәрова соңгы көненә кадәр иренә тугрылыклы була, аның кайтканын көтә. Донор булып канын тапшырып, паеклар ала һәм аларны төрмәгә иренә ташый. 16 ел буена көтә ул Туфанның кайтканын һәм, ире Казанга кайтыр алдыннан гына, көтә-көтә үзе вафат була. Менә Туфан кайтып төшә, ә Луизасы юк, бердәнбере — Лу юк инде дөньяда.

Мин Луиза апаны яхшы белә идем, ул безне театр мәктәбендә сүз техникасы фәненнән укытты. Ул вакытларда Туфанның исемен телгә алырга да ярамый иде. Аның иҗатын бөтенләй белмибез. Көннәрдән бер көнне без Луиза апаның Х.Туфанның хатыны икәнен белеп алгач, дәресләр бетүгә аның янына килеп, Туфан белән кызыксына башладык. Ләкин Луиза апа безгә ире турында берни дә сөйләмәде. Тиз генә пальтосын кия иде дә ашыга-ашыга театрга эшкә юнәлә иде. Без яшьләрнең бәлагә таруыннан курыккандыр ул.

Ниһаять, партиянең XX съезды шәхес культы чоры томаннарын таратып җибәрде. Мәхбүсләрнең исән-сау калганнары иреккә чыгарыла башлады. 16 елдан соң Хәсән Туфан да Казанга кайта. Нинди генә газаплар күрергә туры килмәсен, Туфан йөрәгендәге иҗат утын сүндерми, олы шигърияткә тугрылыклы булып кала.

60—70 нче елларда Хәсән ага бик зур дәрт белән иҗат итте, яңадан-яңа әсәрләрен бастырды. Хәсән ага Казанда, башка шәһәр һәм районнарда, төрле өлкәләрдә халык алдында очрашуларда катнашты, күп йөрде. Миңа да күп кенә концерт залларында, югары уку йортларында, мәктәпләрдә Хәсән аганың юбилей кичәләрендә, аның белән очрашуларда еш катнашырга туры килде. Х.Туфан әсәрләреннән Мәскәүнең «Мелодия» фирмасында граммофон пластинкасы чыгардым, Татарстан радио һәм телевидение фондында шагыйрь иҗатына багышланган әдәби программаларым саклана. Туфанның 100 еллыгын үткәргән көннәрдә алар эфирда да яңгырады. Гомумән, Хәсән Туфан иҗатын пропагандалауга кулымнан килгәнчә өлеш кертә алуым белән мин үземне бәхетле санаийм.

*2000*

## Бакый Урманче

Быел февраль аенда милли сәнгатебезнең якты йолдызларыннан берсе, күренекле рәссам Бакый ага Урманченың тууына 97 ел тула.

«Шәһри Казан» гәзитенең бер санында язучы Шамил Рәкыйповның «Яктырак йолдыз янадыр төн кара булган саен» дип исемләнгән мәкаләсе басылып чыккан иде. Ул мәкаләдәге Б.Урманче турында әйтелгән сүзләр исемдә калган: *«Милли сәнгатебезнең ничә төрен еллар дәвамында үз җилкәсендә күтәргән бөек олпат-оста Бакый ага Урманче бар иде,* — дип яза автор, — *ул һәртөрле эзәрлекләүләргә, биниһая авырлыкларга түзеп, Шәрекътагы кардәшләребез мәдәниятен үстерде, үз иленә кайткач, җырлый-җырлый иҗат итте. Бу олпат Рәсәйдә яшәсә, билләһи, әллә ничә Академиянең гамәли әгъзасы булыр иде».*

Француз рәссамы Поль Гоген «һәр милләтнең мәдәни йөзен рәссамнар билгели» ди. Бу мәшһүр рәссамның француз милли мәдәни йөзен әдәбиятта Бальзак, Золя, Гюго, Мопассан, җыр сәнгатендә Эдит Пиаф, Мирей Матье, Джо Дассен, Шарль Азнавур, рәсем сәнгатендә Роден, Ренуар, Ван Гог, Делакруа билгели диюендә дә хакыйкать юк түгелдер.

Без хәзер искә алып сөйләргә теләгән гали зат — моннан дүрт кенә ел элек вафат халык рәссамы Бакый ага Урманче. Ул үзе нинди дә булса чагыштырулар, аеруча сәнгать әһелләрен рангларга бүлүне өнәп бетерми иде. Үлмәс рухы алдында гафу сорарга мәҗбүрбез ки, чөнки гавам халкына аның урынын аңлатуны үзе яраткан импрессионизм илен телгә алудан башларга җөрьәт итәбез.

Әйе, сәнгатьтә Бакый ага Урманче импрессионизм, ягъни хис, фикер ачыклыгын алга сөргән юнәлеш яклы иде. Урманче әлеге юнәлеш белән танышуын, мөгаен, 20 нче елларда Мәскәүдә, ВХУТЕМАСта укыган вакытында башлагандыр. Мәскәү музейларында ул XIX — XX гасырларда иҗат ителгән сынлы сәнгать әсәрләрен төп нөсхәсендә күрү бәхетенә ирешә. Ленинградтагы Эрмитажда һәм Рус сынлы сәнгать музеенда бик еш булып, андагы экспонатлар белән танышу да Бакый аганың импрессионизм юнәлеше белән кызыксынуын арттыргандыр дип уйларга нигез бар.

Бакый ага белән мин Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында эшләгән елларда таныштым. 1960 елда К.Тинчуринның «Беренче чәчәкләр» драмасы сәхнәгә куелган иде. Аны бизәүне Казанга Урта Азиядән шул елларда гына кайткан рәссам Бакый Урманчега тапшырдылар. Драмада төп рольне — Хәмит ролен — Ш.Биктимеров башкарды, миңа Хәйдәр ролен бирделәр. Безгә, яшь актерларга, Бакый аганың матур-матур киңәшләр биргәне хәтердә. Ул сынлы сәнгатьне генә түгел, гомумән, әдәбиятны, театрны, халык авыз иҗатын, аның этнографиясен тирән белүе белән бездә соклану тудырган иде. Менә шул вакытлардан бирле миңа күп мәртәбәләр аның өендә, остаханәсендә, театрларда, концерт залларында, сынлы сәнгать күргәзмәләрендә очрашып, төрле темаларга сөйләшүләр, әңгәмә корулар насыйп булды. Аны барысы да кызыксындыра: әдәбият-сәнгать тә, сәнгатьнең аерым жанрлары да, хәтта радио-телевидение тапшыруларының ни дәрәҗәдә эшләнүләре дә аның дикъкатеннән читтә калмады.

Бакый ага рәссам, сынчы, график, архитектор, шагыйрь, җырчы, музыкант иде. Шушы сәнгать өлкәләренең һәммәсендә аңа хөр фикер, көчле хиссият, тирән акыл, якты, кояшлы төсләр хас иде. Әйтик, «Күл Черкене — су буенда атлар коендыру», «Кече Салтык болынында печән өсте», «Уралтау эргәсендә», «Сабантуй», «Ибн Фадланның Болгарга килүе», «Сак-Сок» һәм башка әсәрләрендә кояш җылысы, хыял көче

ургый. Шул ук вакытта документальлек, типаж, тарихи дөреслек! Яисә соры гипста гына калу сәбәпле, менә-менә уалып юкка чыгу куркынычы янаган Мәрҗани хәзрәт җәнапларының ироник күз карашын гәүдәләндерүче тылсымга игътибар итегез. Ак мәрмәргә кереп сыенган Фатих Әмирхан, Габдулла Кариев, Гыйлем Камай, Гыйниятулла Терегулов һәм башка сыннардан да сизелер-сизелмәс кенә ал нур балкый сыман. Опера һәм балет театры бинасын бизәүче мәрмәр Җәлилдә корыч ныклыгы, ә Дәүләт музеендагы ак мәрмәр Тукай күзләрендә нихәтле моң, сагыш вә көч! Аны күрүгә, күңелгә үзеннән-үзе шагыйрьнең:

Кайтмады үч, бетте көч, сынды кылыч — шул булды эш:
Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым... —

дигән үлмәс юллары килә.

Тукай әсәрләрен Бакый ага кебек яраткан кешене мин башка белмим. Шуңа күрәдер Тукай тематикасы аның күп әсәрләрендә чагылыш тапты. Шул ук вакытта Бакый аганың Тукайдан гайре яраткан шагыйрьләре дә күпме иде?! Дистәләрчә татар шагыйре үз иҗатларында Бакый ага Урманче исемен телгә ала, аңа багышлап шигырьләр, балладалар иҗат итә. Аның үзенең күңеленә хуш килгән әсәрләрнең берсе татар халык шагыйре Гамил ага Афзал иҗат иткән «Сагыш» иде. Бу шигырь рәссамның 30 елдан соң Идел иленә кайтып, армут агачы тамырыннан автопортретка охшаш «Сагыш» әсәрен тудыруга бәйле. *«Килер бер вакыт, «Сагыш» әсәре нигезендә татар халкы тарихы язылыр, һәм ул һәр чын татарны әсир итеп елатыр да, җырлатыр да, яңа үрләргә дә өндәр»,* — дип инглизчә язганнар Бакый аганың күргәзмә дәфтәренә Америка татарлары. Бакый ага Урманченың күпкырлы иҗаты Җир шарының һәммә кыйтгаларында яшәүче татарларга да таныш һәм газиз. «Сагыш»тагы шикелле үк музыкаль аһәң чыңлап торган «Язгы моңнар», «Нәфисә» скульптураларын карагач, аңа телефоннан берәү: «Карт башың белән ялангач кызлар сынын ясап утырмасаң!» — дип тә шылтыраткан.

Юк-юкта матбугатта әле дә ислам илләрендә һәйкәл-сыннар кую ярамый дигән кебегрәк фикерләр чагылгалап китә. Бәгъзеләр исә, ислам сәнгатьне тыйган, дип расларга тырышалар. 1986 елның көзендә сәнгать сөючеләр белән очрашу кичәләренең берсендә рәссам, әлеге мәсьәләгә тукталып, болай дигән иде: *«Ислам дине сәнгатьне тыямы?» дигән сорауга җавап эзләп, мин Коръән Кәримне махсус ике тапкыр укып чыктым, бер тыйган сүз дә күрмәдем. Тик соңарып тикшергәнмен: мөфти Риза казый Фәхретдин хәзрәтләре исламның сәнгатьне тыймавы хакында әллә кайчан зур фәнни хезмәт язган булган».*

Азиядән бигрәк Аурупага авышкан Татарстан җөмһүрияте ислам мәмләкәте булган тәкъдирдә дә, иншалла, һәйкәлләрен кырып бетерү түгел, иң затлы, иң моңлы вә гүзәлләрен кую эшенә керешер дип өметләнәбез. Ә рәссам Урманче иң динле кешеләрнең берсе булып калгандыр, мөгаен. Бакый ага гомерен 30 еллыклар белән исәпләргә ярата иде. Шунысы игътибарга лаек, гомеренең беренче һәм өченче 30 еллыгында аңа Ходай Тәгалә ике тапкыр дин һәм сәнгать арасында җитди сынау куя. 1913 елда рәсем ясарга, балчыктан атлар, арбалар, кошлар «укмаштырырга» яраткан «Мөхәммәдия» шәкерте Урманче Казан сәнгать мәктәбенә керергә исәпләп йөри. «Закон божий»дан имтихан тотса, ягъни чукынып караса, Эрьзя-Нефедовлар шикелле мәшһүрлек казанган рәссам да чыккан булыр иде үзеннән. Әмма мөмкинме соң?! Бу турыда уйларга да куркыныч! Иптәше Әхәт Багданов та шул рәвешле рәссам була алмый кала. Ә Урманче инкыйлаб каһарманнары Шамил Госманов, Давыт Яналиев һәм башкалар ярдәме белән профессиональ рәссамлыкка уку бәхетенә ирешә.

60 елдан соң, ягъни гомеренең өченче 30 еллыгында, 70 яшьне узган көр тавышлы, матур мәкамле, дини гыйлемле халык рәссамы Урманчега Петербург мәчете имамы булырга тәкъдим итәләр. Башка илдә булса, таштан сыннар кисүен, кәгазьдә чәчәкләр, киндердә портретлар ясавын да дәвам итеп, Питер каласы мәчете мөнбәреннән акыллы хөтбәләр сөйләп, моңлы азанын да әйтеп, Вәли Карый мәкаме белән өйрәнгән Коръән Кәримен дә укыган булыр иде, мөгаен. Тик бездә түгел. Моңлы сүрәләр, көр тавыш та өйдә, мәҗлесләрдә генә яңгырап, дусларын ләззәтләндерә, рухларын сафландыра. Бакый Урманченың татар җирендә, мөселман илендә, Идел куенында салынган таза, ифрат ныклы шәхеслек нигезләрен гомеренең икенче 30 еллык дәверендәге Боз диңгезе концлагерьлары да, Урта Азия, Балхаш буйларындагы сөрген дә какшата алмый. Иделен-илен, Казанын бер минут сагынмый тормаган 60 яшьлек остага туган иленә кайту мөмкинлеге бирелгәч, ул дәртләнеп, рухланып, бар булган көчен куеп, тагы 33 ел бәхет-сәгадәт, иҗади эш тулы гомер кичерде.

1987 елның 23 февралендә Г.Камал исемендәге театрда 90 яшьлек юбилеен үткәргәндә гаҗәеп көчле, ачык баритональ теноры белән башкарган «Ончы Фәхри»дән дә кайбер агай-эне риваять ясый башламасынмы: имеш, чит илләрдә йөреп гыйбрәт алучы маэстроның шәһәр саен ярлары юкмы?

Юк! Гомеренең давыллы көннәре тыела төшеп, гаилә тынычлыгы лязим булган ике 30 еллыкта аңа хәләл, ягъни законлы рәвештә ике тапкыр өйләнергә туры килә. Берсе Пенза, икенчесе Себер ягыннан ике - ханымга гаилә бүләк итеп, үзе дә алар белән бәхетле гомер кичерә. Татар сынлы сәнгатен 30—50 нче елларда «Сара ханым» һәм «Илдар» темасына, 60—80 нче елларда «Флора ханым» һәм «Айдар» исемнәре белән бәйле нәкыш һәм график әсәрләре белән баета.

Берсе Пензаның 1 нче гильдияле сәүдәгәре Хәсән Баишев кызы Сара ханым, икенчесе дарелмөгаллимин «Вазифа»ны тәмамлаган укытучы Ваһап Әхмәтов кызы, фольклорчы-галимә Г.Тукай бүләге лауреаты Флора ханым. Алар рәссамның рухи канатлары, җан азыгы.

Бакый ага иҗат кешеләрен — артистларны, композиторларны, язучыларны, музыкантларны ифрат ярата иде. Шуңадырмы аны төрле концертларда, юбилей, иҗат кичәләрендә, спектакльләрдә еш очрата идек. Бакый ага күңеле белән үзе дә артист иде. Башкаручыларны канатландырып җибәрә торган җылы сүзләр таба, сәнгатьтәге һәр яңа ачышка, уңышка ихлас күңелдән сөенә белә. Бакый аганың үз иҗатына багышланган кичәләрдә, юбилей көннәрендә без артистлар да бик теләп катнаша идек.

Шундый концертларның берсе аеруча хәтердә уелып калган. Бу кичә 1982 елның 27 апрелендә Татарстан Рәссамнар берлегенең күргәзмә залында булып үтте. Зур күргәзмә залының бөтен бер катын Бакый ага Урманче эшләре алып тора иде. Татар халкы өчен бу күргәзмә зур бәйрәм булды.

Күргәзмәгә төрле шәһәрләрдән кайтарылган бик күп скульптуралар һәм нәкыш, график әсәрләре куелган иде. Бу күргәзмәне күз алдыңа китереп уйлана башлауга, Сибгат ага Хәкимнең рәссамга багышлап язган шигыре искә төшә:

Бүген монда Бакый күргәзмәсе,
Бүген монда хуҗа — Урманче.
Йөрдем олы сәнгать дөньясында,
Йөрдем тәмам күңелем булганчы.
Калын тарих урманнары аша
Атлап бара кебек Урманче.
Шунда туган бөек «Сагыш»ларын
Шигъри җаным саклар үлгәнче.

Нур өстенә нур дигәндәй, күргәзмә барган залның үзендә Татарстан сәнгать осталарының Бакый абыйга багышланган зур концерты булды. Бу концертка Казанның бик күп зыялылары җыелган иде. Алар арасында композиторлардан Н.Җиһанов, Р.Яхин, язучылар Ә.Еники, Р.Ишморат, Н.Арсланов, сәхнә эшчәннәреннән Ш.Сарымсаков, Г.Булатова, галимнәр, рәссамнар, артистлар бар иде.

Казанда Бакый ага Урманченың күптән көтелгән музее ачылса, әнә шундый кичәләрне, аңа багышланган күргәзмәләрне без ешрак күрә алыр идек. Ашыгасы иде шул музей белән! Бакый аганың иҗатын күзалларга мөмкинлек бирер иде ул. Ә ул иҗат искиткеч күпкырлы. Аны җыр сәнгате, борынгы язма культура, халык декоратив сәнгате белән бәйләп карау зарур. Бакый Урманче — профессиональ сынлы сәнгатькә нигез салган рәссам. 200 гә якын скульптура әсәре, 300 ләп чын милли график эш калдыруын да әйтсәк, әлбәттә, аны татар милли мәдәни йөзен билгеләүче дә дип әйтергә тулы хакыбыз бар.

*1994*

## Уйландыра торган бәйрәм

1997 елның октябрендә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең 60 еллыгына багышланган кичәгә җыйналган идек. Күптән күрешмәгән сәхнәдәшләр белән очрашу барыбызның да күңелләрендә якты хатирә булып калгандыр. Халкыбызның яраткан эстрада артистлары, филармониянең әдәби-музыкаль лекторие солистлары, күп еллар буе филармониядә җитәкчелек иткән кайбер аксакалларыбыз җыйналган иде бу көнне.

Соңгы биш елда безнең арабыздан күп еллар бергә эшләгән сәхнәдәш дусларыбыз — Г.Рәхимкулов, Ф.Йосыпов, В.Гыйззәтуллина, Т.Якупов, Г.Ильясов, К.Басыйров, Р.Аббасов, Р.Ахманов, Р.Волкова, И.Алексеева, Д.Сиражетдинова, М.Садыйков, Э.Дробот, Ф.Садыйковлар мәңгелеккә китеп бардылар. Алар белән бергә күпме концертлар үткәрелгән, күпме юллар үтелгән, кайсы гына төбәкләргә сәяхәт кылынмаган... Бу талант ияләре бик вакытсыз дөнья куйдылар, әле иҗат планнары корып йөргән мәлләрендә, һич уйламаганда, бакый дөньяга күчтеләр, күпме җырланмаган җырлар, эшкә ашырылмаган иҗат планнары калды... Аларның һәркайсы халкыбызның олы мәхәббәтен казанган, үзенчәлекле, талантлы артистлар, үз эшләренең осталары иде. Ярый әле, Ходайга шөкер, радиода һәм телевидениедә күпләгән язмалары калды, шуларны тыңлаганда искә алабыз, алар белән бергә үткән гастрольләрне, аларның шаян сүзләрен, мөлаем елмаюларын хәтергә төшерәбез, ә колакта моңлы җырлары яңгырый...

Казанда Татар дәүләт филармониясе артистлары концертлары белән мин 40 нчы елларның ахырында, театр мәктәбендә укыганда ныклап кызыксына башладым. Зур сәхнәләрдә эстрада сәхнәсенең төрле жанрларын эченә алган, берсеннән-берсе гүзәлрәк җырчыларны һәм музыкантларны берләштергән бай эчтәлекле концертлар була торган иде. Анда катнашу өчен филармония солистларыннан тыш опера җырчылары да, драма артистлары, консерватория музыкантлары да, шулай ук күренекле композиторларыбыз да чакырыла иде. Ул чакларда безнең яратып тыңлаган җырчылар Р.Ваһапов, Ф.Насретдинов, У.Әлмиев, З.Басыйрова, М.Рахманкулова, Ш.Котдусова, Г.Сөләйманова, Җ.Сәләхова; оста музыкантлар З.Хәбибуллин,

А.Ключарев, Ф.Туишев, Ф.Биккинин, М.Батталов; сүз жанрында эшләүче Ф.Йосыпов, Х.Сәлимҗанов, Ә.Яһүдин, Г.Шамуков; Җыр һәм бию ансамбле, Опера һәм балет театры биючеләре А.Гацулина, Ә.Нарыков, Б.Әхтәмов, Г.Калашниковлар эстрада концертларына иң яхшы номерлар белән киләләр иде.

Ул чакта концерт программаларын төзүгә филармониянең сәнгать җитәкчелеге җитди карады, ә программалар ул вакыттагы сәнгать эшләре идарәсенең махсус репертуар комиссиясе раслагач кына тамашачыга тәкъдим ителде. Шуңа күрә концертка профессиональ композиторларыбызның иң яхшы җырлары һәм музыкаль әсәрләре генә алынды. Ул елларда эстрада сәхнәсендә чын олы сәнгать күрсәтелде дип уйлыйм. Өлкән яшьтәге тамашачылар ни өчен ул еллардагы концертларны әле дә сагынып искә алалар соң? Күрәсең, бүгенге эстрада сәнгатенең күп яклары белән килешеп бетә алмый торганнардыр алар. Әлбәттә, хәзер дә талантлы сәхнә осталары бар. Ләкин аларны талантсызларның күмеп китүе зыялы тамашачыларның эчен пошыра. Бу зур проблеманы — халкыбыз зәвыгын олы сәнгать аша дөрес тәрбияләү мәсьәләсен — югары оешмалар белән берлектә музыка, сәнгать белгечләребез күтәреп чыксын иде. Аларга бу өлкәдә язучылар, композиторлар, рәссамнарның иҗат берлекләре ярдәм итәргә тиеш. Шулай булмаганда, яшь буынның олы сәнгатебез белән кызыксынуы кимеячәге көн кебек ачык.

1937 елда Казанда Дәүләт филармониясе ачылу республикабызның мәдәни тормышында зур вакыйга була. Эстрада сәнгатенең төрле жанрларында эшләүче тәҗрибәле, сәләтле башкаручыларга ихтыяҗ арта. Җырчылар, музыкантлар, бию осталары Татар дәүләт филармониясендә эшләп, иҗатлары белән халыкка хезмәт итүне үзләренең вөҗдан эше итеп тоя башлый. Концерт бригадалары оештырылып гастрольләр башлангач, әлбәттә, сүз жанрында эшләүче артистлар мәсьәләсе дә көн тәртибенә баса.

Әмма филармония оешып, тыныч тормышта эшләү озакка бармый, Бөек Ватан сугышы башлана. Артистларыбызның күбесе фронтка китә. Шулай да эш тукталмый, Казанда калган артистлар икеләтә көч белән эшләрен дәвам иттерәләр. Сугыш елларында авылларга концертлар белән чыгу тагын да кыенлаша. Юл йөрергә атлар юк, булганы да хәлсез, авылдан авылга барып җитә алмый, артистлар, йөк күтәреп, җәяү дә атлыйлар. Әлбәттә, ашау яклары да начар була. Шул еллардагы гастрольләр авырлыгын җырчыларыбыз Р.Тимерханова, Р.Ваһапов, Җ.Сәләхова, артистка З.Ваһапова һ.б. бик ачынып сөйлиләр иде.

Филармония артистлары авыр сугыш шартларында да, фронттан фронтка күчеп, сугышчыларга мәдәният хезмәте күрсәттеләр, Бөек Җиңү көнен якынайту өчен иҗат көчләрен керттеләр. Сугыштан соң филармония артистлары да Казанга кайтып яраткан эшләрен дәвам иттерделәр. Шунысы кызганыч: Татар дәүләт филармониясенең оешкан көненнән алып бүгенге көнгә кадәр үткән иҗат юлы турында кечкенә генә китап булса да басылганы юк. Шушы 65 ел эчендә филармониядә кемнәр генә эшләмәгән, иҗат көчләре республика күләмендәге нинди генә мәдәни чараларда катнашмаган, коллективлар нинди генә уңышларга ирешмәгән! Ә ташка басылган язмалар юк, димәк, болай булгач, аның тарихы да юк диярләр кайберәүләр. Әмма, филармониянең төрле еллардагы җитәкчеләренең ваемсызлыгы аркасында килеп чыккан мондый җитешсезлекләргә карамастан, Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең бай тарихы бар, аның төрле коллективларында эшләгән йөзләрчә талантлы иҗат кешеләре бар, алар сәнгатьнең төрле жанрларында халкыбызга төрле елларда фидакарь хезмәт иттеләр. Вакытлы матбугатта юбилейлар уңаеннан филармониянең күп булса 5—6 кешесе турында языла, һәр юбилей саен ул кабатлана. Ә безнең матбугат битләренә эләкми калган күпме артистларыбыз, музыкантларыбыз бар. Алар турында кем язарга тиеш?

Матбугатта шулай ук филармонияне оештыруда башлап йөргән җитәкчеләр турында да бернәрсә дә язылмый. Шундыйларның берсе — филармониянең беренче көннәреннән барлык оештыру эшләрен алып барган, шулай ук 1937 елда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленә кадрлар туплап, ансамбльнең эшли башлавын тәртипкә салган күренекле хор дирижеры, ансамбльгә консерватория белемле дирижер кадрлар әзерләүдә күп тырышлык күрсәткән Зөләйха Әхмәтова. Филармония һәм ансамбль оешуга ике ел тулганда, 1939 елны аңа «Татарстанның атказанган артисткасы» дигән мактаулы исем бирелә. Зөләйха Әхмәтова җитәкчелек иткән ансамбль концертларына без бик яратып йөри торган идек. Репертуарларындагы бик күп җырлар озак еллар нәкъ Зөләйха ханым куйганча башкарылып килде. Дәһшәтле сугыш башлангач, филармониянең директоры һәм сәнгать җитәкчесе вазифаларын башкару да Зөләйха ханым Әхмәтовага ышанып тапшырыла. Җыр һәм бию ансамблен чын профессиональ коллектив итеп тәрбияләүдә аның роле зур. Ул 1988 елны Мәскәүдә вафат булды һәм шунда җирләнде. Филармония һәм ансамбль тарихына Зөләйха Әхмәтованың исеме алтын хәрефләр белән язылырга тиеш. Әлбәттә, биредә төрле елларда актив эш алып барган күренекле шәхесләрнең исемнәрен санап бетерү мөмкин түгел. Шәхсән мин үзем эстрада концертларында 50 нче елларның башында катнаша башладым, төрле шәһәрләргә гастрольләргә дә чыга идем.

Опера солистлары һәм филармониянең музыкаль әзерлекле җырчыларының вокаль осталыгы, аларның зур зәвык белән төзелгән репертуарлары концертларның уңышын тәэмин иткәндер дип уйлыйм.

Бүгенге көндә профессиональ сәнгать белән бергә үзешчән сәнгатебез дә алга бара. Яңа коллективлар барлыкка килә, ансамбльләр оеша, аерым башкаручылар үсеп чыга, әмма аларга сәнгатьтә дөрес юнәлеш бирүдә, башкару осталыгын күтәрүдә ярдәм итүнең җитәрлек булмавы күзгә ташлана. Казан урамнарында еш кына төрле афишалар күрәбез, аларда фәлән җирдән килгән фәлән сәхнә йолдызы — җыр остасы, фәлән нәфис сүз остасы һ.б. шундый сүзләрне укыйбыз. Ә баксаң, бу «осталар» берничә үзешчән композитор

әсәрен яки берничә юмореска башкаручы, вокаль осталыклары түбән, сәнгатьле укуның әлифбасын да үзләштермәгән үзешчән артистлар булып чыга. Ә бит «нәфис сүз остасы» дигән исем ул «халык артисты» исеме белән тәңгәл тора торган, сүз сәнгате фәнен тәмам үзләштергән, сөйләм техникасын күп еллар дәвамында чарлаган, репертуарын даими баетучы чын сәнгать кешесенә генә бирелә торган исем. Без яшьрәк вакытларда бу исемгә лаек өч кенә башкаручы бар иде: Х.Сәлимҗанов, Ш.Сарымсаков, Г.Шамуков. Без алар белән горурлана идек.

Әгәр башкаручы, сүз техникасын бөтен нечкәлекләре белән үзләштермичә, сәнгатьле уку кануннарын белмичә укый икән, һәм, иң аянычлысы, үз репертуарын әдәбиятыбыз байлыгына якын да тормаучы «чүпчар» әсәрләр белән «баета» икән, нинди генә мактаулы исемнәр йөртсә дә, ул «нәфис сүз остасы» дигән исемгә лаек була алмый торгандыр. Сәхнәгә чыккач, ул әсәрнең идея тирәнлеген ача белмәсә, жанрның бөтен нечкәлекләрен бирә алмаса һәм, иң әһәмиятлесе, телебезнең аһәңен, матурлыгын, тәмен тыңлаучының күңеленә иңдерә белмәсә, ул нинди сүз остасы була инде?

Эстрадабызда яшь җырчылар саны көннән-көн арта бара. Алар арасында консерватория, музыка училищесында белем алган яшьләргә караганда, беркайда да укымаган, үзешчән сәнгатьтән килгәннәре күбрәк сыман, һәм шушы башкаручыларның соңгылары «мәшһүр», «популяр», «танылган» кебек сүзләрне яратарак төшәләр. Ирексездән шундый сорау туа: үзләре үзешчән, үзләре яшь тә булгач, кай арада шундый осталар булып җиткәннәр соң алар? Үзешчән сәнгатьтә эшләүчеләр арасында (яшь профессиональ сәнгать вәкилләренә дә кагыла бу) «күренекле», «мәшһүр», «оста» һ.б. төшенчәләр белән сак эш итү кирәклеген күрсәтүче бер генә факт бу. Тамашачының зәвыгын бозуга китерә торган бүгенге «чирләрнең» берсе — кибетләрдә һәм киоскларда сатыла торган аудио һәм видеокассеталар. Анда профессиональ җырчыларның язмалары 30—40 процент тәшкил итсә, калган өлешен акча табып, теләсә нинди төр кассеталар чыгаручылар алып тора. Шундый чорда яшибез, акчаң гына булсын, теләсә нинди китап бастырырга, теләсә нинди язма чыгарырга була. Һәм шулай әйтергә яраса, «ширпотреб» продукцияне укучылар, тыңлаучылар алалар. Чын профессиональ башкаручылар үз язмаларын чыгара алмый интегә. Шушындый шартларда кая ул югары зәвык турында сүз алып бару, кая ул профессиональ сәнгать, һәм ул сәнгатьнең эчтәлеген, сыйфатын яхшырту турында кайгырту?

Ә инде татар дәүләт филармониясенең 65 еллыгы турында яза башлагач, татар эстрада сәнгатенең безнең барыбызны да борчыган кайбер якларына тукталмыйча булдыра алмадым. Ул турыда без язмасак, без борчылмасак, битараф булсак, сәнгатебез чүпләнә барачак бит. Сәхнә ветераннары бу жанрның яңаруына һәм үсеш алуына зур өмет баглый. Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе концертларында Ф.Мансуров кебек зур оста җитәкчелегендәге симфоник оркестр, профессор А.Шутиков җитәкчелек иткән халык уен кораллары оркестры, эстрадабызда бүгенге көндә өметле саналган җырчыларыбыз Резеда Галимова, Рөстәм Маликов, Уфадан еш килеп тамашачыларны зур концерт программалары белән сокландырып торучы Идрис Газиев кебек артистларыбыз бар. Алар эстрада сәнгатькәрләренә зур үрнәк булып тора.

*2002*

## Сәхнәбезнең йөзек кашы

Ал гөле Сез безнең сәхнәбезнең,
Сезнең талант мәңге чәчәкле,
Тукай әйткән дәртле халыкның Сез
Үзе төсле һаман яшь әле.

*Х.Туфан*

Бу мәкаләнең исемен «Сәхнәбезнең йөзек кашы» дип куюымның үзенә күрә бер традицион сере бар. Фатыйма ханым Ильская кулында татар театры сәнгатенең эстафета йөзеге йөрде.

Бенефис спектакле вакытында татар халкы исеменнән Габдулла Кариевка алтын йөзек кидертәләр. Бөек артистыбыз вафатыннан соң бу йөзек Кәрим Тинчуринга бирелә. Татар халкының сәнгатенә, үз театрына булган олы хөрмәте рәвешендә йөргән бу йөзекне соңрак Заһидә ханым Тинчурина Фатыйма Ильская кулына тапшыра.

Фатыйма ханымның 80 еллык юбилееның банкетында аның үзенең авызыннан Г.Кариевтан калган бу эстафета йөзеген Г.Камал театрын үстерүгә зур көч куйган шәхес, театрның баш режиссеры Марсель Сәлимҗановның кулына кидерүе турында әйтелгән сүзләрне ишеткән идек.

Димәк, бу йөзек театрыбызның башлангыч чорыннан алып бүгенге театрның йөзьеллыгы якынлашкан көннәрне чагылдырган, чыннан да, асыл эстафета йөзеге, гүзәл традицияләрне күрсәтүче йөзек икән.

Фатыйма Салих кызы Ильскаяның тууына йөз ел тулган бу көннәрдә шәһәребезнең музейларында, Г.Камал исемендәге Академия театрында чорыбызның бөек актрисасын олылап искә алу кичәләре үткәрелә. Миңа М.Җәлил музей-фатирында үткәрелгән шундый кичәләрнең берсендә катнашырга туры килде. Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының музей директоры Татарстанның атказанган сәнгать

эшлеклесе Л.Шакирҗанова кичәгә килүчеләрне Фатыйма Ильскаяның тормыш һәм иҗат юлы белән таныштырды, Татарстанның халык артисткасы Р.Хәйретдинова белән мин Фатыйма ханым белән бергә эшләгән еллар турында истәлекләр белән уртаклаштык. Фатыйма Ильскаяның Татарстан дәүләт музееннан китерелгән күпсанлы фоторәсемнәре һәм аның кайбер шәхси әйберләре кичәгә килүчеләрдә зур кызыксыну тудырды. Кичәгә килгән корреспондентларның һәм укучы яшьләрнең берничәсен Фатыйма ханымның Ильская псевдонимын ничек алуы кызыксындырды.

Ә ул менә болай була. 1916 елның 21 октябрендә «Сәйяр» труппасы артистлары Казанның Зур театрында «Шәфкать туташы» исемле драма куялар. Бу драмага чыгарылган афишада «Яңа артистка Фатыйма Ильскаяның иштираке берлә...» дигән юллар да була. Бу — Фатыйма Салих кызы Хуҗасәетованың Казан тамашачылары алдында беренче чыгышы. Шушы чыгышы белән ул профессиональ артистлык юлына баса. Аңа, Урал буеннан килгән кызга, бу фамилияне Г.Кариев һәм К.Тинчурин бирәләр.

— Җәмәгать, Фатыйма беренче мәртәбә сәхнәгә чыга, аңа сәхнә өчен бу үз фамилиясе ярамый, ул бит халык арасыннан чыккан ил кызы! — ди Тинчурин.

— Әйе, ил кызы. Менә шуңа күрә аның фамилиясе Ильская булсын, — ди Кариев.

Ф.Ильская «Шәфкать туташы»нда Юлечка ролен башкара һәм, сәхнәгә яңа гына аяк баскан булуына карамастан, шактый осталык күрсәтә.

1902 елда Оренбург шәһәрендә эшче гаиләсендә туган Фатыйма Хуҗасәетова 13—14 яшьлек яшүсмер вакытында Оренбург яшьләренең үзешчән спектакльләрендә катнаша башлый, шулай ук Казан һәм Уфа труппаларының спектакльләрендә дә бик теләп катнаша. Үтә дә сәләтле кызны 1916 елны танылган артист һәм режиссер Г.Кариев үзенең «Сәйяр» труппасына чакыра. Бу труппада яшь актрисаның таланты ачыла, аңа еш кына зуррак рольләр тапшыралар, ә инде 17 яше тулган вакытта Ф.Ильскаяны татар театры күгендә кабынып килүче яңа йолдыз дип атыйлар. Гражданнар сугышы елларында Ф.Ильская, татар театрының күренекле артистлары белән берлектә, Идел буе укчы полк составындагы фронт театры труппасының артисткасы буларак Кызыл Армия сугышчылары һәм командирлары өчен концертлар бирүдә актив катнаша.

1923 елда Ф.Ильская Татар дәүләт театрына (хәзерге Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры) чакырыла. Ул бу театр сәхнәсендә уйнаган елларында татар, рус һәм дөнья драматургиясе әсәрләре буенча куелган йөзләгән спектакльләрдә гүзәл сәхнә образлары галереясын тудыра.

Ф.Ильская театр сәхнәсендә С.Гыйззәтуллина-Волжская башлаган романтик традицияләрне дәвам иттерә. Үз вакытында татар театрының күренекле артисты һәм режиссеры Зәйни Солтанов: *«Татар халкына онытылмаслык иң югары һәм гаҗәеп үтемле рухи азык бирүче артисткаларның берсе — Фатыйма Ильская»,* — дип язып калдыра.

Табигать Ф.Ильскаяга ачык йөзлелек, гадилек сыйфатлары белән бергә искиткеч иҗади сәләт һәм гаҗәеп интеллектуаль талант биргән.

*«Фатыйма ханым Ильская — татар сәхнәсенә табигатьнең үзе тарафыннан бүләк ителгән артистка,* — дип язды үзенең «Фатыйма Ильская» дип исемләнгән иҗат портретында Шәриф Рахманкулов, — *күркәм грация, коеп куйган сын, гүзәл кыяфәт, күңелләрне эретә торган ягымлы тембрлы тавыш. Фатыйма ханымга табигать тарафыннан челтерәп аккан чишмә суыдай саф, ягымлы, һәр интонациясе тамаша залының иң ерак почмагына барып җитә ала торган көр, ачык тавыш бирелгән. Әгәр дә халык, күзне җанның көзгесе дип атаса, без Фатыйма ханымның күзләрен иҗат көзгесенең бер детале дип танырга мәҗбүрбез».*

Безгә, Татар дәүләт театр училищесында укыган яшьләргә, 40 нчы еллар уртасыннан бирле Фатыйма Ильская башкарган рольләрнең байтагын күреп, аның башкару осталыгына соклану бәхете насыйп булды. Мин Татарстан радиосында эшләгәндә, 1954 елны Академия театры К.Нәҗминең «Язгы җилләр» романы буенча эшләнгән «Сәүбановлар» спектаклен сәхнәгә куйды. Спектакльнең режиссеры Ш.Сарымсаков мине большевик Халявин ролен башкарырга чакырды. Спектакльдә большевикларның шәһәр үзәге белән элемтәдә торучы фабрика эшчесе Ксения ролен Фатыйма ханым Ильская башкара иде. Шулай итеп, минем театрда беренче «чирканчык алуым», беренче ролем Фатыйма ханым белән бергә уйнаган спектакльдә булды. Әлбәттә, ул образны әзерләгәндә миңа, әле тәҗрибәсез яшь актерга, Ильская кебек олы актрисаның ярдәме ифрат зур булды. Ә инде театр труппасында эшләгәндә миңа Фатыйма ханым Ильская белән М.Әмирнең «Тормыш җыры», Э.Золяның «Рабурден варислары», К.Тинчуринның «Зәңгәр шәл», Шекспирның «Король Лир» спектакльләрендә бергә уйнау бәхете насыйп булды.

Ф.Ильская иҗаты турында язучылар еш кына: *«Ильская сәхнәгә яшьлек кертә»,* — дип кабатлыйлар. Бу сүзләрнең дөреслегенә без актриса олыгайгач уйнаган рольләрен күреп тә инана идек. Ф.Ильскаяның сәнгать осталыгын бик күп татар актрисалары үзләренә үрнәк итеп санадылар.

*2002*

## Операбызның сүнмәс йолдызы

Быелның 23 сентябрендә мәшһүр җырчыбыз һәм опера режиссеры, профессор, Татарстанның һәм Россиянең халык артисты, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Нияз Даутовның тууына 90 ел тулды.

Нияз Курамша улының фанилыктан бакый дөньяга күчкәненә менә инде 17 ел үтеп киткән. Ләкин ул М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет академия театры коллективы һәм меңләгән опера сөючеләр өчен һаман безнең арабызда сыман. Театрда аны гел искә алалар, Казанның Актерлар йортында Нияз Даутовның туган көнендә һәр елны аны искә алу кичәләре үткәрелә, бу кичәләргә Опера театрыбызның күп җырчылары, музыкантлары, шулай ук опера сәнгатен сөючеләр һәм, әлбәттә, күп еллар буена маэстро белән бергә эшләгән укучылары — җырчылар җыела.

Радиодан аның магнитофон язмасына алып калынган җырлары, романслары һәм опералардан арияләр яңгырый; театр сәхнәсендә ул тәрбияләп үстергән җырчылар җырлый; ниһаять, соңгы елларга кадәр ул сәхнәләштергән опера спектакльләре куела.

Театрның кайсы гына цехына кереп, Нияз Даутов турында сөйләүләрен сорыйсың икән, барысы да беравыздан аның искиткеч кешелеклелеген, игътибарлылыгын, ярдәмчеллеген, зур талант иясе — мәшһүр җырчы, режиссер һәм яшьләр өчен ару-талуны белмәгән олы педагог, остаз булуын яратып искә алалар. Чыннан да, Опера театрында бүгенге көнгә чаклы артистлар арасында Нияз Курамша улы турында легендалар сөйләнә.

Нияз Даутов Казанда туа. 1938 елны Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясен тәмамлый һәм 1943 елга чаклы Мәскәү консерваториясендә үзенең җыр сәнгатен камилләштерә. 50 нче елларда ун елга якын Свердловск опера театрының солисты һәм режиссеры булып эшли. 60 нчы еллар уртасы һәм 70 нче еллар башында Нияз Даутов Чиләбе опера һәм балет театрында баш режиссер була. 1975 елдан ул Татар опера һәм балет театрында солист һәм баш режиссер булып эшли.

Нияз Даутов илебезнең музыка-театр сәнгатенең зур вәкиле иде. Ул күп театрлар сәхнәләренә классик һәм хәзерге заман операларында гүзәл лирик образлар иҗат иткән мәшһүр җырчы һәм берничә дистә күренекле спектакльләр куйган режиссер, киң белемле музыкаль эшлекле, зур эрудициягә ия булган, театр культурасын бөтен тирәнлеге белән белгән олы шәхес иде. Шуның өстенә ул консерваториядә укытучы-педагог, олы тәрбияче дә иде. Чыннан да, Нияз Даутов татар операсында, беренчедән, тамашачылар яраткан гүзәл спектакльләр тудырган оста режиссер булган булса, икенчедән, татар опера сәхнәсендә оста башкаручылар труппасы төзегән олуг театр эшлеклесе дә иде, ә бу эш бик сирәк художниклар кулыннан килә. Н.Даутов — безнең операда ул вакытларда эшләгән оста җырчыларыбыз (аларның күпләгән сәхнә образларыннан берәрсен генә санап китсәң дә) Зилә Сөнгатуллинага — Виолетта, Рафаэль Сәхәбиевкә — Онегин, Венера Ганиевага — Розина, Хәйдәр Бигичевка — Хозе, Эдуард Трескинга Фигароны калдырган оста.

Н.Даутов эшләгән елларда операбызда Лариса Башкирова, Юрий Борисенко һәм башка яшь артистларның таланты ачыла.

Нияз Даутов үзе дә операда күп партияләр башкарган оста җырчы була. Операда аның беренче башкарган партиясе «Евгений Онегин» да Ленский партиясе була.

Аннан соң ул «Снегурочка»да — Берендей, «Травиата»да — Альфред, «Риголетто»да — Герцог, «Дубровский»да — Владимир Дубровский, «Фауст» операсында — Фауст, «Севилья чәч алучысы»нда — Альмавива, «Демон»да — Синодал, «Отелло»да — Кассио, «Богема»да — Рудольф һ.б. партияләрне башкара.

Нияз Даутов үзе дә татар композиторларының кайбер операларында матур-матур образлар иҗат итә. Өлкән яшьтәге опера сөючеләр аның башкаруында Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында — Җик Мәргән, «Җәлил» операсында — Муса Җәлил, Х.Вәлиуллинның «Самат» операсында Самат партияләрен оста башкарганын хәтерләрендә саклыйлар. Бу партияләр арасында тамашачылар аеруча яратып тыңлаган Җик Мәргән партиясенә тукталып үтәсе килә. Бу образга җырчы әкияти-эпик сыйфатлар бирә. Аның герое мәһабәт табигать баласын хәтерләтә, аның хәрәкәтләре сыгылмалы, йөрүе сиздермәстән урман эченнән килеп чыгучы батыр егет йөрешен хәтерләтә. Образның шушындый тышкы күренеше, җырчының зур вокал осталыгы белән берләшеп, тамашачылар тарафыннан җылы кабул ителгән Җик Мәргәнне күз алдына китереп бастыра.

Татарстан радиосы фондында сакланган «Алтынчәч» операсыннан арияләр хәзер дә радиотапшыруларда еш яңгырыйлар. Алар арасында күңелгә аеруча хуш килә торганы — Нияз ага Даутов башкаруындагы Җик Мәргәннең «Урман» ариясе.

50 нче еллар башында Нияз аганың Свердловскидан Казанга гастрольләргә килгәне хәтеребездә саклана. Аның гастроль спектакльләренең барысын да карарга тырыша идек. Ул елларда барган спектакльләрдән яратып каралганнары Нияз ага Даутов башкаруында «Риголетто» операсында — Герцог, «Травиата»да — Альфред, «Богема» операсында Рудольф образлары бигрәк тә хәтердә уелып калганнар. Нияз ага катнашкан спектакльләргә тамашачылар билетларны күпкә алдан алып куя иде, спектакль көннәрендә театр алдында билет сорап торучылар бихисап була иде. Нияз Даутовның һәрбер гастроле зур уңыш белән үтә иде.

Талантлы режиссер буларак Нияз Даутов илебезнең төрле шәһәрләрендә 30 га якын спектакль куя. Алар арасында дөнья опера классикасының күренекле әсәрләре була. Ул куйган спектакльләр һәркайда зур уңыш казаналар. Казан опера сәхнәсендә дә Н.Даутов дөнья классикасы, рус классик композиторлары әсәрләрен уңышлы сәхнәләштерә, шулар белән беррәттән татар композиторлары операларын да куя. Алар арасыннан «Алтынчәч» һәм «Самат» опералары белән бергә Р.Гобәйдуллинның «Җиһангир», Бату Мөлековның «Кара йөзләр» операларын күрсәтеп китәргә була. Бу спектакльләрне тамашачылар яратып каршы алганнар иде. «Алтынчәч» операсы бүген дә театрның алтын фондында саклана торган сәхнә әсәре.

Нияз Даутовны театрда артистларның образлар иҗат итү-эшләүләре генә түгел, гомумән, спектакльне тудыруда катнашучы төрле цехларның эше кызыксындыра иде. Ул хорның матур яңгырашына да, оркестрның ятышлы уйнавына да зур әһәмият бирә, артистларны киендерүче һәм грим салучының эше белән дә кызыксына, спектакльнең рәссамы белән дә тыгыз элемтәдә тора.

Театрда, эш вакытында булсын, гомумән, тормышта булсын, Нияз Курамша улының бик тыйнак табигатьле, кешеләр белән уртак тел таба белүче, игътибарлы, мөлаем кеше булуы турында аны белгән күпләр сөйли; шул ук вакытта ул эштә булган җитешсезлекләргә түзеп тормаучан, үтә дә таләпчән режиссер була.

Россиянең халык артисты профессор Нияз Даутовның исеме үз вакытында безнең Опера театрыбызның визит карточкасы кебек санала иде. Тавышы Мәскәү, Ленинград, Свердловск һ.б. күп шәһәрләрнең сәхнәләрендә яңгыраган мәшһүр җырчыны ул чактагы илебез опера йолдызлары белән бер рәткә куялар иде. Әле 40 нчы елларда режиссер Александр Ивановский «Сильва» кинофильмын куйганда, Эдвин роленә күп җырчылар арасыннан Нияз Даутовны сайлап алуы да шул турыда сөйли булса кирәк. Өлкән яшьтәге тамашачылар бу фильмның зур уңыш белән барган вакытын хәтерли торганнардыр. «Сильва» фильмы Мәскәү телевидениесе каналлары аша сирәк булса да безнең көннәрдә дә күрсәтелә. Нияз Даутов катнашкан опералар пленкага төшерелеп алынмаганнар, чөнки ул елларда андый техник мөмкинлекләр юк иде. Ә «Сильва» фильмында без «тере» җырчы һәм актерның уенын, вокаль осталыгын күрәбез. Бу фильм үз заманында безнең киң илебез экраннарында зур уңыш белән барды. Режиссер Нияз Даутовның эстрада сәнгатенә дә мәдәниятебезнең зур көчкә ия булган бер тармагы итеп каравы, бу өлкәдә эшләүче артистларны, музыкантларны бик ихтирам итүе исебездә калган. Ул поэзияне ярата, күп халыкларның шагыйрьләрен белә иде. Аны сәнгатьтә илһамландырып торучы олуг шагыйрь Г.Тукай булды. Г.Тукайның 80 еллыгына багышланган юбилей концерты М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында нәкъ менә Нияз ага Даутов режиссерлыгында үткәрелгән иде. Аның Тукай иҗатына зур мәхәббәт күрсәтеп, концерт программасын зәвыклы, эчтәлекле итеп куюы күңелебезгә хуш килгән иде.

Театр үткәрә торган олы юбилейларга багышланган кайбер концертларны зур осталык һәм зәвык белән Нияз Даутов үзе алып бара торган иде. Шундый концертларның берсе «Музыкаль мозаика» дип аталды. Бу программада ул концертны алып баручы һәм лектор — музыка белгече сыйфатында чыккан иде. Театр сәхнәсендә Нияз Даутов куйган операларның соңгысы, илебездә беренче тапкыр башкарылган Б.Гибалинның «Федор Протасов» операсы булды.

Нияз Курамша улы Даутовның сәнгате һәрвакыт гражданлык хисләре белән сугарылган иде; аның сәнгате кешеләрне шатландыра, горурландыра, фикерле белергә өйрәтә торган олуг сәнгать иде.

*2003*

## Күренекле балерина, режиссер һәм педагог

М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының мәшһүр балеринасы, бүгенге көндә Казан хореография училищесының сәнгать җитәкчесе, Россиянең, Татарстанның һәм Башкортстанның халык артисты, хореография профессоры Нинель Даут кызы Юлтыевага 80 яшь тулды.

Н.Юлтыева — Ленинград хореография училищесында М.Ф.Романова-Уланова классында белем алган балерина. Үзенең иҗат эшчәнлеген ул 1941 елда Уфада Башкорт опера һәм балет театрында башлый.

1946 елдан бөтен иҗат гомерен М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрына хезмәт итүгә багышлый.

Нинель Юлтыева — илебезнең балет сәнгатендә киң танылу алган шәхес. Аның татар сәхнәсендә башкарган балет партияләрен өлкән буын тамашачыларыбыз һәм аның сәхнәдәш коллегалары әле бүген дә сагынып һәм яратып искә алалар. Шул партияләр арасыннан аеруча истә калганнарын атап үтәсем килә: Мария («Бахчасарай фонтаны»), Китри («Дон Кихот»), Тао Хоа («Кызыл мәк»), Сари (Кара-Караевның «Күкрәү сукмагы буйлап» балеты), Одетта-Одиллия һәм Аврора (Чайковскийның «Аккош күле» балеты) һ.б.

Н.Җиһановның «Зөһрә» балетында — Зөһрә, З.Хәбибуллинның «Раушан» балетында — Раушан, Ф.Яруллинның «Шүрәле»сендә Сөембикә партияләре дә балерина тарафыннан аеруча нечкә психологик һәм драматизм алымнары кулланып иҗат ителгән сәхнә образлары.

Нинель Юлтыева илебезнең күп шәһәрләрендә һәм Кытай, Бирма, Вьетнам илләрендә гастрольләрдә була.

Атаклы балерина бер үк вакытта педагоглык эшчәнлеге дә алып бара. 50 нче еллар азагында М.Җәлил театрында аның балетмейстер буларак куйган «Шәһрезадә» (Римский-Корсаков музыкасы), «Аккош күле» балетлары зур уңыш белән бардылар.

Без Нинель Юлтыеваның һәр премьерасын карап бара һәм аның осталыгына сокланып, аны театрыбызның прима-балеринасы дип атый идек. Аның зур осталык белән башкарган соло биюләре һәм төрле балетлардагы дуэтлары бүгенгедәй күз алдымда. Бу чыгышлар һәрвакыт тамашачыларның көчле алкышларына күмелә иде.

М.Җәлил исемендәге Опера һәм балет театрының концерт төркемнәрен Мәскәүнең Чайковский исемендәге концерт залы администрациясе дә еш чакыра торган иде. Һәм ул концертлар тулы аншлаглар белән үтә иде. Анда Н.Юлтыева белән Р.Сафинның «Шүрәле» балетыннан Сөембикә һәм Былтыр партияләрен зур уңыш белән башкарулары истә калган.

Гастрольләр белән йөргәндә балеринаның үзеннән аның балачагындагы ачы язмышы турында сөйләгәннәрен ишеткәнебез булды.

Нинель ханым — күренекле башкорт язучысы Даут Юлтый кызы. (Заманында Д.Юлтыйның «Карагол» спектакле белән Уфада башкорт драма театры ачыла.)

Кечкенәдән биюгә хирыс Нинельне Ленинградның хореография училищесына укырга урнаштыралар. Сәләтле кызны профессор А.Ширяев укыта башлый. Әмма бәхетле уку еллары озакка бармый. 1937 елны Даут Юлтыйны «халык дошманы» дип кулга алалар һәм бер елдан атып үтерәләр. Бераз вакыттан соң әнисе Фатыйма ханым да кулга алына. 1941 елның язында үзен укыткан, туганыдай якын күргән укытучысы А.Ширяев та вафат була. Нинель боларның барысын да бик авыр кичерә. Аннан сугыш башлана. Укуын тәмамламыйча, Нинель туган ягы Башкортстанга кайта һәм 15 яшеннән Опера һәм балет театрында биюче булып эшли башлый. «Саңгырау торна» балетында башкарган партиясе яшь биючегә зур уңыш китерә. Шулай итеп, балеринаның балет сәхнәсендә иҗат эстафетасы башлана.

Театр дирижеры Хәсби Фазлуллин белән гаилә кору да Нинель Даут кызының тормышында зур вакыйга була. Шулай итеп, олы сәнгатьтә эшләүче бу гүзәл пар 1946 елны Казанга күчеп килә һәм алар Татар дәүләт опера һәм балет театрында эшли башлыйлар. Нинель ханым зур иҗади тырышлык белән берсеннән-берсе гүзәл балет партияләрен үзләштерсә, Хәсби Вәлиулла улы театрда бара торган барлык балет һәм кайбер опералар белән дирижерлык итүче зур остага әверелә, Россиянең һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, халык артисты исемнәренә лаек була. 1957 елда Мәскәүдә узган сәнгать декадасыннан соң Н.Юлтыевага «Россиянең халык артисты» дигән мактаулы исем бирелә. Балерина театр сәхнәсендә 40 яшенә кадәр бии. Аннан соң режиссурада камилләшү һәм балет спектакльләре өстендә эшләү, педагоглык хезмәте башлана.

Н.Юлтыеваны чит илләр дә балет труппаларына җитәкчелек итүгә чакыралар. Ул Каһирәгә балет төркемен өйрәтүгә бик теләп бара. Шулай ук Венесуэла, Америка театрларында да яшь көчләрне балет серләренә өйрәтә һәм һәрчак туган илен сагынып кайта. Тынгысыз педагог һәм балет остасын Казанда яраткан эше көтә. Нинель Юлтыева — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында баш балетмейстер, Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетында үзе оештырган балет бүлегендә кафедра мөдире. 1998 елдан бүгенге көнгәчә ул Казан хореография училищесының сәнгать җитәкчесе, балет сәнгате өчен яшь кадрлар әзерләүдә зур активлык белән эшли. Консерваториядә балет педагоглары әзерли торган төркемнең ачылуында да аның роле зур була.

Балет сәнгатенә бөтен җаны белән бирелеп, олы хезмәт юлы үткән оста биюче, режиссер, педагог Нинель Даут кызының иҗат юлына күз салу да һәркемдә соклану һәм горурлану хисләре уята.

*2006*

## Зәңгәр томаннар артында калган мизгелләр

Минем архивымда бик күп фоторәсемнәр саклана. 50 нче еллар ахырында мин «Зенит» маркалы фотоаппарат сатып алган идем. Гастрольләргә чыкканда яки җәйге яллар вакытында мин һәрвакыт фотоаппаратны үзем белән ала торган идем. Берничә дистә ел эчендә аларда минем иҗат юлымда очраган дусларым, коллегаларымның матур-матур рәсемнәре сакланып калган. Ул рәсемнәрне актарганда, төрле еллар, төрле кичерешләр искә төшә, аерым спектакльләрдә яки концертларда бергә катнашкан артистлар, режиссерлар, композиторлар, алар белән кулга-кул тотынып иҗат иткән вакытлар күз алдына килә. Фотоаппарат ярдәмендә, тормышның бер мизгелендә аерым шәхесләрне фотопленкага төшереп ала, еллар, дистәләгән еллар үтә, үз архивыңнан алып рәсемнәрне карау сине кабаттан үткән елларны, инде онытылып та барган аерым мизгелләрне, сәхнәдәге иҗатташларны, дусларны, якыннарны яңадан күз алдына бастыра. Сагыну, сагышланып алу халәтен дә кичерәсең кебек... Ни кызганыч, ул рәсемнәрдә сиңа елмаеп карап торучыларның кайберләре бүген безнең арабызда юк инде. Менә шунысы күңелне моңсуландыра. Вакыт узу белән һәр кеше олыгая бара, олыгайган саен кешенең күңеле дә нечкәрә бара сыман. Шуңа микән кешеләр буш-

рак вакытларында үзләрендә сакланган рәсемнәрне актарырга ярата башлыйлар. Бөек Такташыбыз да: «...Өстәленнән альбом кебеген алып рәсемнәрен карый башлыйсың», — дип язганмы әле?!

Үткән елның ахырында мәшһүр композиторыбыз Рөстәм Яхинның тууына 75 ел тулу көне республикабызда киң билгеләп үтелгән иде. Шул уңай белән Казанда зур музыкаль кичәләр уздырылды, композиторга багышланган истәлекләр китабы дөнья күрде. Күп кешеләрдә сакланган, Р.Яхин белән бергә төшкән рәсемнәр барланды. Минем архивымда да Рөстәм дустыбыз белән гастрольләр вакытында төрле шәһәрләрдә, чит илләрдә концертлар уңае белән яки ял вакытларында төшкән иллегә якын рәсем саклана.

Инде дистәгә якын еллар үткән, рәсемнәрдәге кешеләр дә азрак үзгәреп киткәннәрдер. Рәсемнәргә карыйм да, шул мизгелләр, минә үзе берничә ел безнең арабызда булмаса да, Рөстәм дустыбыз Яхинны күз алдыма тере көенчә китереп бастыра...

Рөстәм Яхин белән беренче очрашуым һәм танышуым мин Татарстан радиосында эшли башлаган 50 нче елларның башында булды.

Радиода еш була торган композиторыбыз Мансур ага Мозаффаров, Заһид Хәбибуллин, Җәүдәт Фәйзиләр белән инде мин таныш идем. Мәскәү консерваториясендә укучы Рөстәм Яхин турында да ишетеп белсәм дә, үзен күргәнем юк иде.

Беркөнне радионың репетицияләр бүлмәсенә керсәм, анда концертмейстер Екатерина Александровна Соколова янында мөлаем гына бер кешене һәм җырчыларыбызны күрдем. Шунда Екатерина Александровна мине Рөстәм белән таныштырды. Бераздан Р.Яхин консерваторияне тәмамлап Казанга кайтты.

Ул елларда Г.Камал театры бинасында еш кына Татарстан радиосы оештырган концертлар уздырыла иде. Ул концертларда, әлбәттә, радио аша тыңлаучыларга яхшы таныш булган мәшһүр артистлар, җырчылар, музыкантлар чыгыш ясыйлар иде. Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова, Фәхри Насретдинов, Заһид Хәбибуллин, Фәйзи Биккинин, Александр Ключарев, Шәфыйка Котдусова, Сәгыйть Алиев, Исмәгыйль Илалов — аларның чыгышларын тамашачылар бик яратып тыңлыйлар иде.

Минә шундый концертларның берсендә Рөстәм Яхинның да катнашканы хәтеремдә калган. Концертта мин беренче тапкыр Рөстәмнең фортепиано өчен язган пьесаларын башкаруын ишетеп сокланган идем.

Үзем дә Г.Тукайның берничә әсәрен укыдым, минә шул концерт Рөстәм Яхин белән бергә эшләгән беренче концерт булгандыр, мөгаен.

Аннан соң төрле елларда, төрле концертларда Рөстәм Яхин белән бергә Казанда, республикабыз шәһәрләрендә, Мәскәү һәм Ленинградның концерт залларында, илебезнең кайбер шәһәрләрендә, хәтта чит илләрдә дә чыгышлар ясарга туры килде.

Рөстәм Яхин исеме күпләргә таныш, шуның өчен аның җырларын бар төбәкләрдә дә яратып башкаралар, аның яңа әсәрләрен көтеп алалар иде. Кайда гына булмасын, Рөстәмнең концертларда үзе дә катнашуы бик күп тамашачыларны, җыр яратучыларны җәлеп итә, аның чыгышлары һәркайда зур уңыш казана иде. Бу беренче нәүбәттә Рөстәм Яхин җырларының халыкчан, моңга бай булуы белән аңлатылса, шулай ук аның оста пианист һәм һәр җырчының бөтен мөмкинлекләрен ачуга булышлык итүче оста аккомпаниатор булуы да ярдәм иткәндер дип беләм. Рөстәмнең фортепиано һәм оркестр өчен концертын һәм фортепиано өчен махсус язылган әсәрләрен үзе башкаруда тыңлау күңелгә чиксез ләззәт бирә иде.

Рөстәм Яхин тормышта искиткеч гади, кешелекле шәхес иде. Ул сәнгать һәм әдәбият әһелләренә дә самими, җылы мөгамәләдә булды, бу өлкәләрдә эшләүчеләргә хөрмәте ифрат зур иде, шуңа күрәдер Рөстәмнең үзенә дә артистлар, язучы һәм шагыйрьләр зур хөрмәт күрсәтәләр, аны олылый беләләр иде.

Ул сәнгатьнең һәр төренә бик җитди карый торган, үзенә дә, музыкант, җырчыларга да башкару осталыгын үстерүдә ярдәм итәргә әзер торучы, шул ук вакытта бик таләпчән чын профессионал иде.

Әлбәттә, ул еллардан бирле күпме сулар акты, күпме вакыйгалар булып үтте, әмма сәнгать юлыннан киткән күп шәхесләр арасында Рөстәм Яхин талантлы композитор, оста пианист, чын сәнгать кешесе буларак аерым урын алып тора.

Кайда гына чыгышлар ясарга туры килмәсен: Казанның Опера театрындамы, Мәскәүнең Чайковский исемендәге концерт залындамы, Ленинградның капелла залындамы, шәһәребез мәктәпләрендә яки махсус музыка мәктәпләрендәме — һәркайда Рөстәм Яхин концертларга нык әзерләнеп, зур иҗади рухлану һәм дулкынлану хисләре белән чыга торган иде.

Кайвакыт концерт башлануны сәхнә артында көтеп торганда, Рөстәм: «Ничек син бер дә дулкынланмыйча сәхнәгә чыга аласың?» — дип сорап та куйгалый иде.

Мин көлеп кенә: «Концертларда катнаша-катнаша дулкынланудан туйдым инде, шуңа хәзер дулкынланмый башладым», — дия идем.

Кайда гына эшләсәк тә, Рөстәмне сәхнәдә зур уңыш көтә иде. Бу яктан алганда Рөстәм бәхетле артист һәм үз әсәренең уңышын тоючы бәхетле композитор булды.

Иҗат эшендә һәм сәхнәдә башкару осталыгы буенча ул үзенең коллегаларына үрнәк булып торучы профессионал иде.

1968 елның май аенда миңа Рөстәм Яхин белән бергә чит илгә гастрольгә дә барырга насыйп булды. Финляндиядә яшәүче галим, профессор Гомәр Таһир чакыруы буенча бер төркем артистлар һәм музыкантлар фин татарларына концерт бирү өчен Хельсинки шәһәренә бардык.

Концертларыбыз Хельсинки һәм Тампере шәһәрләрендә үтте. Программага Рөстәм Яхинның дистәләгән җырлары һәм романслары, авторның үзе башкаруында фортепиано өчен пьесалары кертелгән иде. Һәркайда тыңлаучылар Рөстәмнең әсәрләрен аеруча яратып тыңладылар һәм авторны чәчәкләргә күмделәр. Баксаң, аның күп әсәрләре белән Финляндия татарлары граммофон пластинкалары аша яхшы таныш икән инде. Бу хәл, әлбәттә, авторның күңеленә бик хуш килгәндер, андагы концертларда ул зур рухлану белән катнашты.

Рөстәм Яхинның тормышта гаять гади, кешелекле булуы турында әйтеп үткән идем инде. Дүрт-биш еллар безгә Рөстәм белән бер тирәдә — Казанның ул вакыттагы Ленин районында яшәргә туры килде. Ул — Восстание урамында, ә без Кызыл Байрак урамында яши идек. Рөстәм чаңгыда йөрергә ярата иде, берничә мәртәбә мин, хатыным Мәрьям һәм Рөстәм белән Аккош күленә чаңгы шуарга баруыбыз истә калган, соңрак ул походларны көлеп искә ала идек. Рөстәмнәргә килгәндә безне аның әнисе Мәрьям апа бик җылы каршылый иде. Аш-суга оста, бик пөхтә, ифрат кечелекле, өендә дә чисталык һәм пөхтәлек яратучы ханым иде Мәрьям апа. Мин аңа: «Мәрьям апа, сез минем әниемә бик охшагансыз, ул да шундый ук аш-суга оста, бик уңган, чын татар хатыны, исеме дә Мәрьям», — дигәч, «Айрат, алай булгач, әниеңне сагынган саен безгә кер, аны күргән кебек булырсың, ә мин сезне пәрәмәч белән сыйлармын. Синең үзеңнең хатының да Мәрьям исемле бик мөлаем ханым бит», — дия торган иде. Мәрьям апа шаян сүзле, хөр күңелле, ифрат ягымлы кеше иде. Аның шундый кешелек сыйфатлары улы Рөстәмгә дә күчкәндер...

...Рәсемнәр актарып утырганда, ерак еллар томаны артында калган менә шундый аерым мизгелләр хәтергә килә. Һәм шул мизгелләр күз алдына халкыбызның яраткан композиторы Рөстәм Яхинның якты образын китереп бастыра. Рөстәм безнең арабызда юк инде. Әмма аның үлемсез иҗаты, матур җырлары халкыбыз күңелендә мәңге яшәр, сәхнәдәш дусларына нечкә күңелле гүзәл кешене, олы шәхесне искә төшереп торыр.

*1997*

## Йөрәкләрдә калды моңнары

Рәшит Ваһапов белән беренче танышуым читтән торып, әле үзен күрмичә, аның гүзәл җырлары, моңы белән сихерләнеп радио аша тыңлаганда булды.

Безнең гаиләдә иң яраткан җырчыларыбыз Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова һәм Фәхри Насретдинов иде, атаклы гармун остасы Фәйзулла Туишев концертларын да көтеп ала торган идек. Минем үземә Рәшит Ваһаповның «Нурия»се, «Әлфия»се, «Фирдәвескәй», «Урман»ы бик ошый иде. Ул безне, тыңлаучыларны, йөрәкләргә кереп кала торган тирән моңы, гаҗәеп үзенчәлекле тавышы белән сихерли торган иде. Безгә, әле яшүсмерләргә, ул җырларны Рәшит ага кебек беркем дә башкара алмыйдыр кебек тоела иде.

Инде күп еллар үтте, үз гомеремдә күп җырчыларны тыңлаганым булды, әмма яшьлек елларымда шул инанган уйларымны тормыш раслады кебек. Р.Ваһапов кебек талантларны табигать саранланып кына бирә шул, ул башкарган җырларны, аның кебек тирән моң белән, аның үзенә генә хас башкару осталыгы белән башкаручылар юк дәрәҗәсендә бит.

Дөрес, ул җырларны башкаручылар хәзер дә бар, ләкин аларны тыңлаганда, колакта барыбер Рәшит аганың моңы ишетелеп торган кебек тоела.

1946 елда мин Казанга укырга килдем һәм тора-бара ул вакыттагы сәнгать дөньясы белән таныша башладым. Без Камал театрында бара торган спектакльләр һәм концертларның күбесенә ничек кенә булса да керү ягын карый идек.

Менә шул концертларның берсендә, ниһаять, мин Рәшит Ваһаповның үзен сәхнәдә күрдем. Озын буйлы, мәһабәт сынлы мөлаем кеше сәхнәдә күренү белән залдагылар дәррәү кул чаба башладылар.

Менә нинди ягымлы кеше икән ул без моңа кадәр тавышы белән генә таныш булган Рәшит агабыз! Аның матур тембрлы тавышы, үзенә генә хас иркен җырлау манерасы беренче җырлаган җырыннан ук безне әсир иткәндәй булды.

Мин аның белән радиода һәм соңрак филармониядә бик күп очрашуларым вакытында кешеләр белән илтифатлы җылы мөгамәләдә булуын күрә идем, ул бигрәк тә үзенең концерт бригадасында эшләгән коллегалары турында чын кайгыртучанлык күрсәтүче җитәкче дә иде. Аның тормышы күбрәк гастрольләрдә, юлда үтте. Юлда йөрү җиңел түгел, юл кешене арыта, алҗыта, кайбер кешеләрне бер дә юктан гына чыгырыннан чыгара. Нинди генә авыр вакытларда да Рәшит ага кешеләр белән ачуланышмый, аларга авыр сүз әйтми, гәрчә кайбер кешеләрдән үзенә карата гадел булмаган сүзләр ишетсә дә... Үзенә карата аз гына яхшылык, изгелек эшләүчеләргә ул рәхмәтле зат була белде.

50 нче еллар башы, сугыштан соң тормыш яхшы якка аз гына үзгәрә башлаган вакыт. Мин өйләндем, торырга фатирыбыз юк. Шул вакытларда Татарстан урамында (хәзерге Г.Тукай һәйкәле артындагы) яңа өлгергән йортта күп кенә сәнгать кешеләренә фатирлар бирделәр.

Миңа да шәһәр Советында: «Шул йортта Р.Ваһаповка зур фатир бирәбез, шул фатирның бер бүлмәсен сиңа бирергә булдык, барып карагыз», — диделәр. Башка вариант булмагач, нишлисең, без ул фатирны барып карадык. Мин Рәшит аганың гаиләсе белән бер бүлмәдә яшәгәнен ишетеп белә идем, шундый мәшһүр кешенең аерым фатирда яшәргә хакы юкмыни дип уйлап, мин бу бүлмәдән баш тарттым. Рәшит ага үзенә тиешле фатирның бер бүлмәсен миңа бирергә теләүләрен белеп, бик хафаланып мине эзләп тапты, аның борчылуы йөзенә чыккан иде.

— Рәшит ага, бер дә борчылмагыз, мин ул бүлмәдән баш тарттым, рәхәтләнеп яшәгез, мин көтәрмен, — дигәч, ул, чын йөрәктән елмаеп, мине кочаклап алды, рәхмәтләрен әйтте.

1962 елның августында Рәшит ага белән Кольцода (хәзерге Тукай мәйданында) очрашып, озак сөйләшеп торган идек. Шул очрашу вакытында ул миңа үзе белән бергә Союз буенча зур гастрольгә чыгарга тәкъдим ясады. Мин ул гастрольне түземсезлек белән көттем. Ләкин, ни кызганыч, бу сөйләшүебез тормышка ашмый калды. Рәшит ага 1962 елның 14 декабрендә каты авырудан соң дөнья куйды. Татарстан сәнгате, мәдәнияте зур югалту кичерде.

Рәшит Ваһап улы Ваһаповны без барыбыз да, аны яхшы белгән, аның белән бергә эшләгән коллегалары, бик сагынып яшибез.

*2004*

## Илаһи моң иясе

Дулап узды канлы, данлы чорлар,
Җыр барыбер җирне тетрәтте!
Ходай үзе якын күргәненә
Бирә җиркәйнең җыр куәтен.

*Зөлфәт*

Быел матур, кояшлы май уртасында, әгәр үзе безнең арабызда булса, халкыбызның яраткан җырчысы, илаһи моң иясе, Татарстанның атказанган артисты Таһир Якуповка алтмыш яшь тулган булыр иде. Ни кызганыч, аның гүр иясе булып бакый дөньяга күчүенә дә октябрь башында җиде ел тула. Безгә, үткән гасырның 70—80 нче елларында бу талантлы, тырыш җырчы белән татар эстрадасында бергә эшләгән кешеләргә, аның арабыздан шулай иртә китүе бөтенләй көтелмәгән, чиксез авыр хәл булды. Татар җыр сөючеләре, моңга гашыйк тамашачылар, аның гүзәл сәнгатен яратучы хезмәттәшләре табигать тарафыннан, бәлки, йөз елга бер бирелә торган талантлы олуг җырчыны сагынып искә алалар, аның иҗатын олылыйлар. Әмма иң аянычлысы шул: җырчының таланты бөтен көченә ачылып, зур тырышлык белән эшләгән вакытында, халкыбыз аңардан иҗатында яңадан-яңа үрләр яулавын өметләнеп көткән мәлендә, тамашачыларның олы мәхәббәтен яулаган бу моң иясе сәнгатебез офыкларыннан акрынлап югалгандай булды. Тыңлаучылары аның яңа җырларын, моңын көттеләр, газета битләрендә аңа багышланган язмалар, ачык хатлар күренә башлады. Әмма җырчы боларга берничек тә җавап бирмәде... Һәм, ниһаять, 1999 елның октябрь ае авыр, кайгылы хәбәр китерде.

Ләкин Таһир халкыбыз күңелендә үзенең гүзәл җырларында калды, алар сирәк кенә булса да башкарылалар, өлкәннәрнең дә, яшьләребезнең дә моңга сусаган күңелләренә шифалы бәлзәм булып яталар. Рәхмәт Татарстан радиосына, Таһирның эстрадада яңгыраган җырларының зур өлешен яхшы сыйфат белән магнитофон тасмасына язып калганнар, моны җыр сәнгатебез мирасын халык хәтерендә озак елларга калдыруның бәяләп бетергесез бер кайгыртучанлыгы дип бәяләргә кирәк. Шул фонограммаларга нигезләнеп, Татарстан телевидениесендә дә бер концерт программасы оештырылды. Шул программа безгә гүзәл моңнар иясенең төскә-биткә дә чибәр, озын буйлы, сөлектәй гәүдәле башкаручының килеш-килбәтен хәтеребездә озак сакларга мөмкинлек бирә. Төсле тасмага төшерелмәгәнгә күрәме, әллә телевидениедәге зур үзгәрештәнме, сәбәбе нәрсәдәдер, бу программа эфирда бик тә сирәк бирелә. Ә бүгенге эстрадабызда моңсыз, мәгънәсез җырлар күбрәк урын ала барган көндә Таһир җырлары яшь башкаручылар өчен үзенең моңы, тел сафлыгы, дикциясе белән бер үрнәк булыр иде бит! 1997 елны Таһирның 18 җыры язылган аудиокассетасы дөнья күрде. Җыр сөючеләргә бүләк булды. Бу кассета чыгу Таһирның үзенә дә зур вакыйга булгандыр. Кемнеңдер матбугатта чыккан язмасында: «Таһир бу аудиокассетасы өчен ике мең сум гонорар акчасына да куанды, бурычларын түләргә теләде», — дигән юллар бар иде.

«Күрешербез әле» дип исемләнгән бу аудиокассетаны мин үзем дә еш кына тыңлыйм, анда халык җырлары, композиторларыбыз әсәрләре белән аралашып, бик матур музыкаль букет хасил итәләр кебек. Алар тыңлаучының зәвыгына тәңгәл килерлек итеп сайлап алынган: «Олы юлның тузаны», «Аккошлар», «Наласа авылы көе», «Моңлы гармун», «Күрешербез әле», «Серле күзләр», «Хафизәләм иркәм», «Гөлнарым», «Юлчы җыры» һәм башка тыңлаучыларга якын булган, күңелгә үтеп керә торган моңнар тезмәсе булып яңгырый. Бу җырлар арасында озынрак яңгырашлы, тирән мәгънәле әсәрләр дә, «Чибәр кызга», «О-

ренбург яшьләре көе» кебек ритмик, төзелеше ягыннан үзгәрәк мәхәббәт җырлары да бар. Әмма һәрберсе җыр башкаручының җан авазына — моңына төрелеп яңгырый сыман.

Җырчының һәрбер башкарган әсәренең шулай яратып тыңланылуының сәбәбе нәрсәдә соң дигән сорау туа. Минемчә, башкаручының үз вокаль мөмкинлегеннән чыгып, үзенә ошаган репертуар сайлавында, һәрбер башкарыла торган әсәрнең сүзләренә зур әһәмият бирүендәдер.

Сөйләү техникасында «сүз белән сурәт ясау» дигән гыйбарә бар, ә җырчының моңы сурәт тудырадыр, миңа калса. Таһирның Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле солисты буларак хор белән һәм үзе солист буларак башкарган күпме җырлары бар иде! Фин татарларының «Туган ил» җырын тамашачылар дулкынланмыйча, тыныч кына тыңлый алмады. Хор белән бергә башкарылган казакъ халкының шаян җыры «Уналты кыз», «Нәфисә — ялкау бичә», «Миләүшә» һәм башка күп җырларны тамашачылар ничек яратып тыңлый торганнар иде. Халкыбыз арасында киң таралган «Идел» җыры шулай ук Т.Якупов башкаруында аеруча аһәңле, моңлы яңгырады. Аның башкаруында үлемсез «Туган тел» җыры яңа яңгыраш алды сыман. Үтә дә кыен чорларда тамашачы шушы җырны яраткан җырчысы белән аягүрә басып җырлый, аны тагын кабатлауны сорый торган иде.

Менә Таһир башкарган гүзәл җырлар турында язам, ә үземнең күз алдымда сәхнәдә, аның буй-сынына бик тә килешеп торган татар егете киеме, башына чигелгән кара кәләпүш кигән сөлектәй милләтебез егете басып торгандай, аның ямьле йөзеннән матур елмаюы сүнми сыман. Кайдан килгән соң аңарга матур, аһәңле вокаль осталык, шундый төгәл сәхнә хәрәкәтләре, гомумән, сәхнә осталыгы. Әлбәттә, бернинди музыкаль мәктәпләрдә укымаган, табигать тарафыннан бирелгән сәләт, Ходай Тәгалә бүләк иткән моң, ансамбльдә эшләү чорында күренекле хормейстерлар, балетмейстерлар, вокал укытучылары биргән олы хезмәт мәктәбе Таһирга үз һөнәренең остасы булырга зур ярдәм итә.

Соңгы елларда Таһир Якуповның филармониядән китеп, авыр тормыш шартларында яшәве һәм аның сәбәпләре, ниһаять, гомеренең аянычлы рәвештә өзелүе турында матбугатта күп язылды. Әмма моңа кадәр бу сәнгать хезмәткәренең иҗаты турында музыка белгечләребезнең бер генә саллы язылган мәкаләсе дә күренмәде. Аның алтмыш еллыгында булса да мондый язма күренер дип уйлаган идек. Хәзер кемнәр генә үзләренең компакт-дискларын чыгармыйлар, берәр иганәче табылып, Таһирның да күп җырларын сыйдырган диск чыгарылса, җыр сөючеләр өчен зур куаныч булыр иде. Ул дискка җырчының радиода язылган башка җырлары да, Р.Яхинның бер цикл романс һәм җырлары да бергә тупланыр иде. Бирсен Ходай, бәлки, берәр мәрхәмәтле химаяче табылып, бу халкыбыз өчен кирәк булган изге гамәлне дә башкарып чыгар дигән өметтә калыйк.

Бу сәнгатькәрнең гомер ахырында әйтеп аңлаталмаслык аянычлы хәлгә төшүенең сәбәбен күпләрнең беләсе килә. Таһир Якупов белән Җыр һәм бию ансамблендә бергә эшләгән күренекле шагыйрәбез Лена Шагыйрьҗан үзенең «Таһир белән бергә үткән юллар» дигән язмасында шундый юлларны яза: *«Күп вакыт уйланам: әллә соң Таһирның язмышын ул үзе түгел, ә аның Ходай биргән тавыш-моңы хәл иттеме? Шуннан килгән дан-шөһрәт, популярлык аркасында уңышлардан башы әйләндеме? Бәлки, көнче бәндәләрнең хөсетлеге, ялгыш юлга өстерәве дә тәэсир иткәндер? Әллә инде йомшак холкы сәбәп булдымы?*

*Шулай да заманаларның кискен үзгәреп китүе кире тәэсир итми калмагандыр дим. Нихәл итәсең бит, бөтен кеше дә нык ихтыярлы, оста дипломат булып бетми шул! Талант ияләре аеруча йомшак холыклы кешеләр. Дөресен генә әйткәндә, заманында Җыр һәм бию ансамбленнән аерылып китмичә, һаман шунда күренекле солист булып җырлап йөргән булса, язмышы өчен отышлырак булыр иде дип тә уйлыйм. Ни әйтсәң дә, коллектив ышанычлы чыгыр да, ныклы терәк тә ул.*

*Шулай да без төшенкелек рухыннан арынып, бөегрәк төшенчәләргә әйләнеп кайтыйк әле. Таһир Якупов барыбер дә бәхетсез гомер кичермәде! Ник дигәндә, аны халкы нык яратты, йөрәгенең түренә салып куйды. Ул җыр тарихында халкыбызның иң мәшһүр осталары арасында үзенә тиешле урынны тапты».*

Шагыйрәнең бик матур әйтелгән фикерләренә барыбыз да кушылабыз. Сәхнәдәшләре һәм тамашачылары күңелендә Таһир Якупов татар җыр сәнгате тарихында үзенең онытылмаслык урынын алган, кабатланмас моң иясе булып калды.

*2006*

## Рухи матурлык җырчысы

Быел татар әдәбиятының мәшһүр художнигы, Татарстанның халык язучысы, республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, әдип, прозаик Әмирхан Еникинең тууына 95 ел тулды, һәм аны җәмәгатьчелек киң билгеләп үтә.

Гомер дигәнең бик тиз уза шул. Әле кайчан гына Г.Камал исемендәге театр бинасында язучының 90 яшьлек юбилеен үткәрүгә тырышып әзерләнеп йөргән чаклар бүгенгедәй истә. Һәм ул олуг юбилей кичәсе Казан һәм республикабыз халкы өчен генә түгел, ә Әмирхан аганы укып белгән бик күп төбәкләрдә, шулай ук чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез өчен зур бәйрәм төсендә үткәрелгән иде.

Чыннан да, Әмирхан ага Еники әсәрләре укучылар тарафыннан яратып укыла торган татар психологик прозасының матур үрнәкләре булып саналырга хаклылар. Әсәрләрендәге геройларның күңел серләренә тирән үтеп керә белү осталыгы, фикернең фәлсәфи үткенлеге һәм киеренкелеге, тел-сурәтләү чараларының байлыгы — болар зур талант иясе булган Ә.Еники иҗатының төп сыйфатларын тәшкил итәләр.

Әдипнең искиткеч бай иҗаты турында аның коллегалары — әдипләр һәм тәнкыйтьчеләр, журналистлар күп яздылар һәм киләчәктә дә язарлар. Язылганнары арасында шәхсән минем үземә бигрәк тә ошаганы — Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеевның «Күңел карурманнарының тургае» дип исемләнгән матур язмасы. Шул язмадан кайбер өземтәләрне дә укучыма җиткерүне кирәк дип таптым: *«Ә.Еникинең үзенчәлекле хикәяләү алымы халыктан килә,* — дип яза И.Юзеев. — *Әйтерсең син якын дустың белән чәй эчеп утырасың, ул сиңа бер дә кабаланмыйча гына, күңелдәге йөгәнсез дәртне тыштан яшерә-яшерә, күзенә бәреп чыгарга торган яшь бөртеген эчкә йота-йота сөйли. Сөйли генә түгел, көйли дияр идем мин. Прозасының шагыйранә үз ритмы бар. Иренгә тидерүгә көй уйный башлаган ялан курае сыман, сөйләме табигый, иркен ага. Ул сөйли, ул сиңа халыкның катлаулы язмышын, тугрылыгын, вөҗданын, мәхәббәтен тасвирлый.*

*Син тыңлыйсың һәм татар халкына гына хас булган кабатланмас милли характерларны, ерак бабаларыбыздан килгән гореф-гадәтләрне, этнографияне күзаллыйсың. Әйе, менә 70 елдан артык инде Ә.Еники хикәя һәм повесть дигән авыр йөкне сыгылмыйча җилкәсендә күтәреп бара. Ашыкмыйча гына, җитди уйлана-уйлана, заман юлларыннан халык белән бергә бара да бара ул. «Юл капчыгы»нда кирпеч калынлыгы романнар да, китап киштәләре сыгылырлык томнар да юк. Нәрсә бар? «Рәхмәт, иптәшләр!», «Саз чәчәге», «Рәшә», «Гөләндәм туташ хатирәсе» повестьлары бар. «Вөҗдан» бар. «Матурлык» бар. Барлык хикәяләренә җылы сулыш өреп торучы «Туган туфрак» бар. «Ялгызлык» та бар, «Әйтелмәгән васыять» тә бар аның күңелендә. Язучы үзе күргән вакыйгаларның эченнән бара, шул катлаулы вакыйгаларның герое булып бара, борчыла, яна, катлаулы заманыбызның тоташ гөрелтесенә кушылып, үзе дә шул барышта зур таланты белән катнашып бара да бара, «Тауларга карап» бара».*

И.Юзеевның бу язмасы Әмирхан аганың үзе исән вакытта язылган иде. Шушы китерелгән өзектән күренгәнчә, классик язучы дәрәҗәсенә күтәрелгән авторның заман рухын оста тасвирлый белүе, көндәлек тормыш вакыйгалары, детальләре аша үз геройларының эчке дөньясын, характер үзенчәлекләрен психологик төгәллек белән тәэсирле итеп ачуга ирешә алуы күзаллана. Ә.Еники иҗатында юмор-сатира, публицистика, әдәби тәнкыйть, мемуар жанры әсәрләре, шулай ук әдәби тәрҗемәләр дә зур урын алып торалар иде. Болар барысы да зур әдипнең иҗат офыкларының никадәр киң булуын күрсәтеп торучы фактор иде.

Шәхсән минем үземә иҗат итү елларында Әмирхан аганың кайбер әсәрләрен сәхнәдән булсын, радио, телевидение тапшыруларында укып, аның персонажларының бай эчке дөньясын ачуда зур тырышлык куйганым, авторның тел байлыгына сокланып, ләззәтләнеп эшләгәнем хәтеремдә саклана. Шундый әсәрләрдән бигрәк тә «Курай», «Туган туфрак», «Бала», юмор-сатира жанрында язылганнарыннан «Күңелсез мәҗлес», «Кунакта» һ.б. хикәяләр. «Гөләндәм туташ хатирәсе», «Төнге тамчылар» әсәрләреннән өзекләр башкарганым гүзәл мизгелләр булып хәтеремдә уелып калганнар. Ул әсәрләрнең кайберләре радио фондында сакланалар, сирәк булса да эфирда яңгырыйлар. Әмирхан ага ул язмаларны тыңлаганнан соң, зур канәгатьлек алганын белдереп, башкаручыга рәхмәт хисләрен әйтеп телефоннан шылтырата, очрашкач тагын да гәпләшергә ярата торган ифрат кечелекле, рәхмәтле зат иде. Әсәрләрен радио аша күп яңгыраткан кайбер авторлар турында мондый сүзләрне әйтеп булмый. Әмирхан ага андыйларга, башкаручы артистларның эшенә зур ихтирам белән карарга кирәклеген тәкрарлап торучы гүзәл бер үрнәк сыман тоела миңа.

«Курай» хикәясен радиога язуыбыз турында Әмирхан агага хәбәр иткәч, ул мине фатирына чакырды (без аның белән Чехов урамында бер йортта яшәдек), аның белән язманы тыңладык, ул, бик бирелеп, хикәяләүнең осталыгына соклангандай тыңлаганнан соң: *«Шәп язылган, башкаручыга да, режиссерга да рәхмәттән башка сүз әйтерлек түгел, музыкаль бизәлеше дә әсәрнең эчтәлегенә бик туры килә. Мин тиздән башкалада яшәүче галим дусларымның чакыруы буенча Мәскәүгә барырга җыенам, шушы язманы аларга да тыңлатасы иде»,* — дигәч, мин ул кассетаны аңа бүләк иттем. Мәскәүдән кайткач, Әмирхан ага язманың Мәскәүдәге дусларына бик ошаганын хәбәр иткән иде. Әмирхан ага белән очрашулар вакытында, аның фатирында булганда әдәбият, сәнгать турында кызыклы сөйләшүләр була торган иде: ул үзе дә бүгенге сәнгатьтәге яңалыклар турында сораша, аны, әлбәттә, язучы буларак, театр, эстрада, телевидение, радиодагы яңалыклар да кызыксындыра иде. Мин үз чиратымда аның театр һәм эстрада сәнгатен ихлас яратучы кеше булганын белгәнгә, Казанда озак еллар яшәве чорында аңа якын булган актерлар, режиссерлар, җырчылар турында күбрәк сөйләвен сорый идем. Мине бигрәк тә театрыбызның бөек трагик актеры булган Мохтар Мутинның иҗаты кызыксындыра иде. Бер сөйләвендә Әмирхан ага Мохтар Мутинның Бөре шәһәрендә яңа артист кыз тапканын бәян иткән иде. Ул болай була: М.Мутин спектакльдә уйнар өчен хатын-кыз таба алмыйча йөри. Аңа: «Бездә бер Лиза исемле рус кызы бар, татарча бик оста сөйләшә, шул уйнамасмы икән?» — диләр. Лиза бу тәкъдимгә бик куанып риза була. Спектакль уңышлы уйнала. Кызда артист булу теләге туа, һәм ул М.Мутинга ияреп китеп тә бара. Шулай итеп, яшь кенә кыз Лиза Шляхтина гаять кыю адым ясый һәм үзенең тормышын, киләчәген татар сәхнәсе белән бәйли: озак еллар дәвамында

татар театрында фидакарьләрчә хезмәт итә һәм Сыртланова фамилиясе белән күренекле артист хатын-кызларыбызның берсе булып таныла.

Әмирхан ага бик мавыктыргыч итеп артистлар Шакир Шамильский, Барый Тарханов, Нәфига Арапова, Фатыйма Ильская, Нәгыймә Таҗдарова, Әшрәф Синяева һ.б. турында кызыклы мәгълүматлар белән уртаклаша иде. Аның истәлекләр китапларында да татар сәнгатенә бирелеп хезмәт иткән күп сәнгатькәрләр турында язылган мәкаләләр белән танышабыз.

Әле күптән түгел Әмирхан Еникинең тууына 95 ел тулу уңае белән Башкортстанда, аның туган якларында татар һәм башкорт язучыларының һәм хакимият вәкилләренең әдипне искә алу очрашулары булды. Бу очрашуларга Казаннан Язучылар берлеге рәисе урынбасары Галимҗан Гыйльманов, Бөтендөнья татар конгрессы рәисе урынбасары Фәрит Уразаев, Әмирхан аганың кызы Флера ханым, күренекле музыкант Рамил Курамшин барганнар иде. Благовар районында, әдипнең туган авылы Яңа Каргалыда, Дәүләкәндә кызыклы очрашулар булган, язучы укыган мәктәпкә, ул торган йортка истәлек такталары куелган.

*2004*

## Фәнгә тугрылык

Әгәр үзе исән булса, зур галимә, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы, Татарстанның һәм Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе Диләрә Гариф кызы Тумашевага шушы елның 19 июлендә 80 яшь тулган булыр иде.

Ни кызганыч, озакка сузылган каты авыру моннан бер ай элек бу мөхтәрәм затны безнең арабыздан алып, бакый дөньяга күчерде. Бу үлем, әлбәттә, беренче нәүбәттә аның якыннарының һәм дусларының, күп еллар буе бергә эшләгән Казан дәүләт университеты галимнәре һәм студентларының, гомумән, Татарстан фән эшлеклеләренең тетрәндергеч зур югалтуы булды.

Тумашевлар гаиләсе белән без күп еллар дәвамында шатлык-сөенечләрне бергә бүлешеп, фән һәм сәнгать дөньясында булган яңалыклар турында фикерләшеп, балаларның уңышларына куанып, дусларча яшәдек. Диләрә ханымның тормышта гадилеге һәм күркәмлеге, кешеләргә мәрхәмәтле булуы һәм киң күңеллелеге бу олуг фән эшлеклесенең зур дәрәҗәләре турында уйлауны оныттыра иде.

Без аның фәндәге зур уңышлары турында хәбәрдар булып, аны һәр уңышы белән котлап, яңа үрләр яулавын теләп яшәдек.

Диләрә ханымның фән өлкәсендәге эшчәнлеге турында галимнәр, фән эшлеклеләре күп яздылар.

*«Себердә туып Мәскәү дәүләт университетында югары белем алган Диләрә Гариф кызы бөтен гомерен туган халкына хезмәт итүгә багышлады. Казан дәүләт университетында ул үзенең күренекле укытучыларының традицияләрен уңышлы дәвам итте,* — дип язды Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе президенты Мансур Хәсәнов. — *Берничә дистә ел дәвамында ул, Көнбатыш Себердәге татар диалектларын тикшереп, татар диалектология фәненең зур бер катламын өйрәнде, диалектолог галимнәрнең зур төркемен тәрбияләде. Д.Г.Тумашеваның хәзерге әдәби тел грамматикасын өйрәнүдәге хезмәтләре дә киң танылу алды. «Татар грамматикасы»н төзүгә керткән өлеше өчен ул Татарстан Республикасының фән һәм техника өлкәсендәге бүләгенә ия булды. Өч дистә елга якын татар теле кафедрасын һәм көнчыгыш телләре кафедрасын җитәкләү, тарих-филология факультеты деканы булып эшләү дәверендә Диләрә Гариф кызы Казан дәүләт университетында гуманитар белемне үстерүгә зур өлеш кертте. Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе оешуның беренче көннәреннән үк Д.Г.Тумашева аның эшендә актив катнаша. Академиябезнең хакыйкый әгъзасы буларак, тел белеме өлкәсендәге фәнни эзләнүләргә уңышлы җитәкчелек итә».*

Д.Г.Тумашева үзенең киеренке фәнни хезмәте белән бергә күп кенә җәмәгать эшләре дә башкара. Ул күп тапкырлар төрле дәрәҗәдәге советларның депутаты булып сайлана, тюркологлар комитетында, Россия Федерациясе Президенты каршындагы рус теле советында актив эшчәнлек алып бара. Татарстан Республикасының «Телләр турындагы» законын тормышка ашыру комитеты әгъзасы буларак, республикабызда ике теллелекне пропагандалау юнәлешендә эзлекле эш алып бара. Д.Г.Тумашева — фән дөньясына бик күп яшьләрне җитәкләп диярлек алып кергән шәхес ул.

*«Остаз-галимнең фундаменталь фәнгә нигезләнгән үз мәктәбе, фәндә үз концепциясе булу шәкертләр өчен зур табыш ул,* — дип яза филология фәннәре докторы Фәһимә Хисамова «Мәдәни җомга» газетасының 1996 елда басылган «Академик, укытучы, остаз» дигән мәкаләсендә. —*Дөньякүләм атаклы тюркология мәктәбен үткән Диләрә ханым Тумашеваның шәкертләре фәнни-тикшерену эшендә булсынмы, укыту-методик эштә булсынмы, һәрчак саллы фәнни нигезгә таянып эш итәләр. Бу шәкертләр (21 кандидат, алар арасында 7 се фән докторы һәм профессорлар) күбесе инде хәзер кафедра мөдирләре, декан вазифасын башкаручылар.*

*Тумашевлар гаиләсендә фән белән сәнгать бергә үрелеп барды. Диләрә ханымның гомере буена ныклы таянычы булган сабыр һәм зыялы Равил Рәхим улы Тумашев үзе дә — татар театр сәнгатендә зур хезмәт күрсәткән, башта Татар дәүләт академия театры режиссеры, ә аннан соң күп еллар буена К.Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театрының баш режиссеры булып эшләгән олуг шәхесләребезнең берсе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, атказанган сәнгать эшлеклесе».*

Диләрә ханым белән Равил Мәскәүдә укыган елларында ук өйләнешеп, 1952 елда Казанга кайталар. Шул елларда безнең гаилә беренче фатир алып, Казанның ул вакыттагы Ленин районы Кызыл Байрак урамында яши башладык. Нәкъ шул урамда берничә йорт аркылы Тумашевлар да фатир алдылар. Безнең гаиләләр белән танышып китүебез нәкъ шул вакытларда булды, һәм бу танышу, чын гаилә дуслыгына әверелеп, бүгенге көнгә кадәр дәвам итә. Шул елларда безнең гаиләләребездә икенче балаларыбыз — кечкенә Ләйсән Тумашева белән Алсу Арсланова тудылар. Диләрә ханымның Ләйсәнне күтәреп безгә килүе, безнең Алсу белән аларга баруларыбыз — барысы да матур истәлек булып саклана. Тумашевлар менә дигән балалар үстерделәр. Уллары Айдар, кызлары Ләйсән икесе дә фән кандидатлары, Ләйсән ханымның уллары Сәйяр белән Аяз фән юлыннан китте. Диләрә белән Равил Тумашевлар балаларын гына түгел, оныкларын тәрбияләп үстерүдә дә бик күпләргә үрнәк булып торалар. Диләрә ханым сөйләшкәндә еш кына: «Мине сөендергәне һәм киләчәктә дә сөендерәчәге — балаларымның, оныкларымның намуслы хезмәттә булуларын күрү», — дия торган иде. Һәм ул үзенең бу теләгенең тормышка ашуын исән чагында күреп, шатлыклы хисләр кичергән ана һәм дәү әни булды. Бу хакта язучы Гази Кашшаф 1973 елда «Казан утлары»на язган бер мәкаләсендә түбәндәге юлларны китерә: *«Мин Диләрә Тумашевада идеалга якын торган хатын образын түгел, бәлки бүгенге алдынгы актив хатын-кыз образын күрәм. Ул — гаиләне, фәнне, иҗтимагый хезмәтне һәм җәмәгать эшен бергә гармоник куша белгән хатын. Ул — социаль актив, зур һәм кыю омтылышлы галимә, тәрбияче һәм ана, гаиләне цементлаучы көч, үзенең тышкы кыяфәте белән матурмөлаем, теләсә нинди югарылыкта, теләсә нинди темага әңгәмә алып бара белүче идеаль хатын!»*

Әйе, Диләрә Гариф кызы Тумашева, чыннан да, хезмәттә дә, тормышында да идеаль карашлы зур галимә, җәмәгать эшлеклесе, гаиләсендә олы йөрәкле ир хатыны һәм ана иде.

*2006*

## Гавай гитарасын «йөгәнләгән» бердәнбер егет

Радио аша татар музыкасының гавай гитарасында яңгыравын кайсыбыз гына яратып тыңламый икән? Бер караганда бу уен коралы милли музыкабызны башкару өчен бөтенләй ят та төсле.

Үзенең бөтен иҗат гомерен татар музыкасын пропагандалауга багышлаган күренекле музыкантыбыз Сәгыйть Алиев Татар дәүләт филармониясендә эшләгән елларында шушы музыка коралы белән кызыксынып, татар көйләрен башкару өчен аның киң мөмкинлекләренә инанып, гавай гитарасында уйный башлый. Күп кенә татар композиторларының әсәрләрен әлеге музыка коралында башкару өчен яраклаштыра. Үз чиратында композиторларыбыз С.Алиевның башкару осталыгына зур бәя биреләр, аның репертуарын яңа әсәрләр белән баеталар. Бу музыка коралында уйнаучылар С.Алиевка кадәр дә булмаган, музыкант безнең арабыздан киткәч тә, яшь музыкантлар арасында гавай гитарасы яңгыравын дәвам иттерүчеләр күренми. Кыскасы, Сәгыйть ага Алиев ягымлы, колакларны иркәләүче тавышлы бу уен коралында уйнаган, татар эстрадасында аның данын тараткан бердәнбер музыкант иде.

Сәгыйть ага Алиев зур тормыш һәм хезмәт юлын үткән сәнгать хезмәткәре иде. Ул укытучы да, Новосибирск радиокомитетында музыка редакциясе мөхәррире дә булып эшләгән. Казанга күчеп килгәч тә, ул радиода шул ук хезмәтне башкара, ә соңрак Татар дәүләт филармониясендә музыкант булып эшли башлый. Баштагы елларда ул скрипкада уйный, ә гавай гитарасы белән танышкач, үз иҗатын шушы музыка коралына багышлый. Сәгыйть ага тормышта ифрат гади, тыныч, кешеләр белән аралашучан, коллегаларына тугрылыклы иде. Юморны, шаяртуны яратты, үзе дә төрле кызыклы хәлләрне сөйләргә һәвәс булды. Тормышка оптимистларча караучы, киң күңелле кеше иде. Шуңадырмы эстрададагы кайбер сәләтсез, дан артыннан куучы кешеләрне өнәп бетермәде, кирәк чакта андыйларга үзенең чәнечкеле сүзләрен дә әйтеп куйгалый иде.

1968 елның кышында Питрәч, Лаеш якларына концертлар белән чыктык. Мин фатирга Сәгыйть ага белән бергә кереп йөрим. Ул вакытларда колхозларда кунакханәләр бик сирәк, килгән артистларны төрле хуҗаларга фатирга кертәләр иде. Бу, әлбәттә, бик уңайсыз булды. Көн дә яңа хуҗада торырга туры килә, аларның төрлесе була, кайберләре килгән «кунаклар»ны бик өнәп тә бетерми. Ләкин, нишләмәк кирәк, бу уңайсызлыклар — эстрадада эшләгән барлык артистларның башыннан үткән хәл...

Көннәрдән бер көнне буран чыкты, бик күп кар яуды, юлларны чистартып өлгерә алмадылар. Авыллар арасында колхоз автобуслары йөри алмады. Безгә исә икенче авылга барырга кирәк иде. Көч-хәл белән безнең бригаданы, трактор тарткан чанага утыртып, кичкә таба күрше авылга озаттылар. Кырда салкын,

чанага җәелгән саламга ятып барабыз, туңа башласак, Сәгыйть ага белән чана артыннан җәяүлибез. Сәгыйть ага авылларда күп йөргән, шуңа күрә аның өстендә очучылар өчен махсус тегелгән кием, аягында да унты була иде. Минем өстәге җил үткәрә торган пальтога һәм аякларымдагы ботинкаларга карап, Сәгыйть ага әйтеп куя:

— Кышкы юлда йөрүләр өчен синең «амуниция» ярап бетми бит, малай. Мондый кием белән җылы автобусларда гына йөреп була. Ә андый автобусларны безнең буын артистлар күрмәде һәм киләчәктә дә күрмәс дип уйлыйм. Чөнки безнең филармониядә татар артистлары, аларның сәламәтлеге турында кайгыртучы башлыклар юк. Алар үзләре әнә «Волга» машиналарында гына йөриләр, ә без менә шушы тракторларда әче салкыннарда кар ерабыз. Син мондый кышкы сәяхәтләргә, зинһар, җылырак киенеп чыгарга тырыш инде...

Ниһаять, без күрше авылга барып җитәбез. Трактор безне туп-туры клуб бинасына алып бара. Клубта, салкыннан кергәч, ярыйсы гына җылы күренә, яккан мичләре дә суынмаган. Мич янына сырышып бераз җылынып алгач, концертка әзерләнә башлыйбыз. Безнең төркемдә халкыбызның яраткан җырчысы Габдулла Рәхимкулов та, күренекле җырчы Наҗия Теркулова да бар. Концертлар уңышлы үтә, Сәгыйть ага да халыкны гүзәл көйләре белән моңландыра. Клуб халык белән шыгрым тулы, концертны бик яратып тыңлыйлар, башкаручыларга алкышлар күп яңгырый. Тамашачыларның сәнгать белән очрашудан алган тәэсирләрен, җылы карашларын, көләч йөзләрен күргәч, карга бата-бата юлда туңып йөргән чаклар да онытыла.

Концерт тәмамлангач, клуб мөдире артистларны фатирларга урнаштырып йөри башлый. Сәгыйть ага белән миңа: «Ә сезне үземә алып кайтам, бераз гына көтеп утырыгыз», — ди.

Менә, ниһаять, без клуб мөдире өендә утырабыз. Бире дә клубтагыдан салкынрак, ә салкын өйнең нуры булмый. Хуҗа мичне яга, хәзер җылытам сезне, дип йөгереп йөри. Сәгыйть абый: «Энекәш, без иртәнгә чаклы клубта гына калган булсак, яхшырак буласы икән», — дип тә куя. Хуҗа уңайсызлана, ул бит безгә яхшырак булсын дип үзенә чакырган иде.

Шулай итеп, без шактый салкынча фатирда пальто һәм бүрекләребезне киеп (Сәгыйть ага салкыннан бармакларын саклар өчен җылы бияләйләр киеп йөри иде, аларны да салмыйча) йокларга яттык. Мин Сәгыйть агага әкрен генә: «Киноларда Антарктида бозлыкларында кунучы экспедицияләрне күргәнем бар. Ләкин алар свитердан булалар һәм башларына кимичә йоклыйлар иде», — дип көлеп куям. Сәгыйт ага да, көлемсерәп: «Минем өйдә спальный мешок бар иде, шуны алып киләсе калган», — дип куйды.

Сәяхәтебез дәвам итте. Менә бер авылда безне бик җылы, пөхтә генә җыештырылган фатирга урнаштырдылар. Г.Рәхимкулов, безнең фатирны күрергә кергәч: «Сездә бик җылы икән, теге завклуб фатирында туңганыгызның үчен алып, чишенеп йоклагыз», — дип шаяртып чыгып китте. Фатир җылы, әмма ләкин хуҗабикә апабыз гына бераз төксерәк. Йөзендә бу кешеләрне нигә фатирга керттем соң әле дигәнрәк уйлар чаткысы күренә. Мәрхүм дустыбыз Рәфкать Гомәров гастрольләрдән кайткач болай дип сөйләп көлдерә торган иде:

— Фатир хуҗасының һич кенә көенә төшеп булмый. «Апа, чәй эчеп аласы иде. Самовар куймассыз микән?» дигәч, «куйсам куярмын инде» дип, чәй куеп эчерә, ә үз-үзен тотышы чәй эчәсең килүне бөтенләй бетерә, егетләр.

Сәгыйть ага үз өендәге кебек хуҗаларча карана, тик кенә утырмый, начар эшләүче радиоалгычны төзәтергә керешә, бераз маташа торгач, радиоалгыч ачык сөйли башлый. «Апасы, бу стена сәгатегез нишләп йөрми?» — дип сорый. Апа: «Ул күптән туктаган инде. Авылга килгән мачтырларга күрсәтеп караган идек, алар да булдыра алмадылар. Чоланга чыгарып эләсе бар үзен», — ди. Сәгыйть ага, елмаеп кына: «Кая, алып карыйм әле, нинди төзәтеп булмаслык сәгать икән ул?» — дип, сәгатьне актара башлый. «Машина маегыз бармы, апасы?» — дип тә сорап куя. Хуҗабикә каядыр чоланга чыгып машина мае алып керә. Сәгыйть ага бер сәгатькә якын маташып, сәгатьне яхшылап майлап, тузаннарын сөртеп кире урынына элеп куя. Ходайның хикмәте, сәгать келт-келт итеп йөреп китә. Ә мин читтән карап, булдыра алыр микән дип куркыбрак торган җиремнән: «Афәрин, Сәгыйть ага, алтын куллы икәнсең!» — дип кычкырып җибәргәнемне сизми дә калам. Ә Сәгыйть ага, мыек астыннан гына елмаеп: «Шулай, энекәш, егет кешегә җитмеш төрле һөнәр дә аз!» — ди.

Хуҗабикә апабыз, шатланып: «Ай, Ходаем, ничә ел йөрмәгән сәгатемне төзәттең. Чын мачтыр икәнсең, бу эшеңә күпме түлим соң...» — дия башлагач, Сәгыйть ага: «Мин акча алып эшли торган мастер түгел, апасы, менә буш вакытны бераз үткәрдем, сезне шатландырдым, миңа шул җиткән...» — ди. Апабызны алыштырып куйдылармыни, йөгереп кенә йөри. Бераздан өстәлдә самавыр гөжләп утыра, өстәл өстендә төрле сый. Хуҗабикәбез нинди ризыгы бар, барысын да өстәленә чыгарып тезгән. «Әйдәгез, хөрмәтле кунаклар, өстәл янына рәхим итегез, барыннан авыз итегез», — ди. «Менә бит яхшылык кылу кешене ничек үзгәртә, һәр ике як та нинди күңелле мизгел кичерә», — дип уйлап куям мин.

Кичен яхшы кәеф белән клубка концертка киттек, концертыбызга, әлбәттә, хуҗаларыбызны да чакырдык. Икенче бер авылда Сәгыйть ага хуҗаларның күптән эшләмәгән тегү машинасын төзәтеп бирде. Безне тагын якын туганнары кебек хөрмәт иттеләр. Шулай кунак өстәле артында сыйланып утырганда, мин, Сәгыйть ага гына ишетерлек итеп: «Агаем, моннан соң мин гастрольләр вакытында гел синең белән генә фа-

тирга керәчәкмен, яме?» — дим. Ә ул башын бераз артка ташлап хихылдап ала да: «Ярый, энекәш, шулай һаман бергә булыйк!» — ди.

Менә шундый кулыннан һәр эш килә торган уңган кеше, оста музыкант, кешелекле шәхес иде безнең Сәгыйть агабыз!

*2004*

## Татар сәхнәсенең былбылы

Әгәр дә миннән: «Син татар сәнгатендә озак еллар эшләдең, иҗат гомереңдә бик күп сәнгать әһелләре белән аралаштың, таныш булдың, җырчыларыбыз арасыннан олы талантлы булу өстенә кешелекле, киң күңелле, нурлы кешене күрсәтә аласыңмы?» — дип сорасалар, бик рәхәтләнеп андый кешеләрнең беренчесе Галия ханым Кайбицкая дияр идем. Минем бу фикеремә Галия ханым белән татар сәнгатендә күп еллар бергә эшләгән хезмәттәшләре, аның күпләгән тамашачылары, аны белгән һәм хөрмәт иткән һәркем дә кушылыр иде.

Галия ханым белән мин 50 нче еллар башында Татарстан радиосында эшләгән вакытта таныштым. Радиотыңлаучылар концертларны, музыкаль очеркларны, радиоспектакльләрне күтәп ала, яратып тыңлый торган иде, күпсанлы хатлар аша үзләренең яраткан җырчыларын, музыкантларын ешрак тыңлыйсылары килүен белдерәләр иде. Безгә, микрофон алдында эшләүчеләргә, ул хатлар буенча төзелгән концертларда, лекция-концертларда үзебезнең дә яраткан җырчыларыбыз белән еш очрашырга туры килде.

Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая барыбызның да яраткан сәхнә былбылына әверелде. Аның концертка килүе, репетицияләр вакытында безнең белән дустанә аралашуы, көлә-көлә сөйләшүе һәм микрофон алдында искиткеч матур җырлавы бүгенгедәй күңелебездә саклана. Радиокомитет еш кына тыңлаучыларның соравы буенча Г.Камал исемендәге театр бинасында микрофон алдында җырлаучы популяр башкаручылар, музыкантлар һәм композиторлар катнашында зур концертлар оештырды. Тамашачылар үзләренең яраткан җырчылары Г.Сөләйманова, Г.Кайбицкая, Р.Ваһапов, М.Рахманкулова, Ф.Насретдинов, Ш.Котдусова, У.Әлмиев, Г.Камаева һәм башкаларның чыгышларын бик яратып тыңлыйлар иде. Әлбәттә, ул концертларда һәрвакыт халык көйләрен оста башкаручы композиторларыбыз З.Хәбибуллин һәм А.Ключарев та катнаша торган иделәр.

Галия Кайбицкаяның зур уңыш белән С.Сәйдәшевнең «Сандугач»ын, Гөлйөзем ариясен, «Зәңгәр шәл»дән Мәйсәрә җырын башкаруы хәтердә уелып калган. Тыңлаучылар аны сәхнәдән чыгармый иделәр. К.С.Станиславский, сәхнәдә актер мөлаемлыгы — уңышның яртысы, дигән. Гүзәл сынлы, үзенә килешеп тора торган озын күлмәктән, һәрвакыттагыча елмаеп, сәхнәнең ямен арттырып, балкып торучы Галия ханымны күргән тамашачы, әлбәттә, ул сүзләрне ишетмәгән булса да, үз-үзенә шундый ук фикерне тәкрарлагандыр.

Еллар үтеп, Галия ханым белән яхшы танышып киткәч, мин бу концертларны исенә төшереп, аның программаларында төп урынны Сәйдәш әсәрләре алып торганлыгын әйткәч, ул җанланып китеп сөйли башлый торган иде:

— Салих Сәйдәшев мине татар сәхнәсенә чыгарган беренче остазым бит. 1923 елны, Казан театр техникумында укый башлаган көннәремдә, мине Салих ага эзләп тапты да: «Безнең театрдагы спектакльдә сәхнә артында җырларга бер кыз кирәк иде. Сез җырламассызмы дип килгән идем», — диде. Мин, әлбәттә, уңайсызланып, каушап калдым. Бераздан телгә килеп: «Салих абый, мин җырлый белмим бит», — дип җавап бирдем. Ләкин ул, минем сүзләремә әһәмият бирмичә, үгетли башлады: «Сезне үзем өйрәтәм, аннары минем янда җырларсыз», — диде.

Театр спектакльләренең берсендә Салих Сәйдәшев белән сәхнә артында Г.Тукай сүзләренә «Зиләйлүк» көен башкардык, ул уйнады, мин җырладым. Бу минем театрда беренче чыгышым иде. Менә шул көннәрдән бирле мин Сәйдәш моңнарына гашыйк.

Галия ханым Татар драма театрында эшли башлавы турында бик мавыктыргыч итеп сөйли иде.

...1923 елдан 1933 елга кадәр Татар дәүләт академия театрында актриса күп рольләр башкара, тамашачылар аның һәр яңа эшен яратып каршы алалар. Галиябану, Мәйсәрә, Гөлйөзем, Сәрвәр, Гөләндәм — менә милли классик әсәрләрдә башкарган берничә генә персонаж, шул образларга сәхнә тормышы бирү актрисага моңа кадәр күрелмәгән уңыш китерә. Галия ханым драма театрында эшләгән елларында үзенең моңга, җырга булган сәләтен күреп, театрда барган күп музыкаль драмаларда төп рольләрне ышанып тапшырган җитәкчеләргә, беренче чиратта драматург һәм режиссер Кәрим Тинчуринга һәм театрның музыкаль бүлеге җитәкчесе Салих Сәйдәшевкә тирән хөрмәтен һәм рәхмәт хисләрен гомере буена саклый килде. Г.Кайбицкаяның театрда эшли башлавы бу ике зур шәхес өчен табыш була — алар үзләре күптән эзләгән төп башкаручысын табалар.

Театрда куелган «Таһир-Зөһрә» спектакленә бик матур музыканы композитор Солтан Габәши яза. Шул спектакльдә ханның кече кызы җырын уңышлы башкарган Галиягә композитор музыка техникумына

укырга кирәкле киңәш бирә. Яшь актриса, бер дә икеләнеп тормыйча, драма сәнгатенә өйрәнү белән бергә Шәрык музыка техникумында җыр сәнгатенең серләрен үзләштерә башлый. Әлбәттә, бу ике сәнгатьнең дә үсеп килүче актриса өчен файдасы әйтеп бетергесез зур була. Театрның мәшһүр осталары С.Айдаров, Р.Кушловская белән бергә эшләп, Г.Кайбицкая сәхнәдә берсеннән-берсе матур образлар тудыра, тамашачыларның мәхәббәтен казана.

Камиллекнең чиге юк, диләр бит. Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе каршында ачылган Татар опера студиясендә укып кайтып, Казанда ачылган Опера театрының беренче солистлары арасында эшли башлау Галия Кайбицкаяның иҗат биографиясендә яңа сәхифә булып бәяләнә. Татар дәүләт опера һәм балет театры Н.Җиһановның «Качкын» операсы белән ачыла. Г.Кайбицкая операның төп партиясе — Рәйхананы башкара. Ул үзенең гүзәл колоратур сопрано тавышы, сәхнә мөлаемлыгы, ышандыргыч уены белән беренче спектакльләрдә үк тамашачының мәхәббәтен казана.

...Галия ханым Актерлар йортында яшьләр белән очрашулары вакытында опера сәхнәсендә эшләгән елларында нинди партияләр башкаруын, партнерлары турында бик мавыктыргыч итеп сөйли торган иде. «Иң яратып башкарган опера партиягез кайсы иде?» дигән сорауга: «Алтынчәч һәм Виолетта», — дип җавап бирде. Хәтердә. М.Мозаффаровның «Галиябану» операсында башкарган Галиябану ролен дә сагынып исенә төшерә иде ул. Җ.Фәйзинең «Башмагым» музыкаль комедиясенең Опера театрында беренче башкарылуына да 60 елдан артык вакыт үткән. Бу спектакльдә төп партия — Сәрвәр партиясен — Г.Кайбицкая башкарды. «Башмагым»да шулай ук төп рольне — Галимҗанны башкарган Татарстанның халык артисты Усман Әлмиев Г.Кайбицкаяның гүзәл тавышы, драма артистлары югарылыгындагы уены, сәхнә пластикасы турында истәлекләре белән уртаклашкан иде.

Шәхсән минем үземә опера сәхнәсендә Галия ханымның «Алтынчәч» операсында — Алтынчәч, Вердиның «Риголетто» һәм «Травиата» операларында Джильда һәм Виолетта партияләрен тыңларга насыйп булды.

...Галия ханымның үзенә бу партияләрне тыңлаганда алган тәэсирләрем турында әйткәч, ул, елмаеп: «Айрат, мин опера сәхнәсен бик яратып эшләдем шул, менә хәзер ул елларны сагынып сөйләргә генә калды...» — дия торган иде. Мәскәүнең күренекле режиссеры Л.В.Баратов артистканың иҗади уңышын: *«Кайбицкая башкарган Виолетта — табигатьнең үзе тарафыннан җибәрелгән бүләк. Гүзәл һәм тирән кичерешләргә бай, ышандыргыч, эмоциональ көчкә ия. Ул роль, мөгаен, аның опера сәхнәсендәге иҗатының иң югары казанышыдыр»,* — дип бәяли.

Бөек Ватан сугышы елларында Г.Кайбицкая фронт бригадалары белән зур юл үтә. Бу хакта аның юльязмалары бар. Тормышта Галия ханымның гадилеген, кешеләрне яратучы, аларга һәрвакыт ярдәмгә килергә әзер торучы олы йөрәкле шәхес булуын ассызыклап үтәсе килә. Гыйбрәтле тормыш һәм иҗат юлы узган, дөньяның ачысын да, төчесен дә күп күргән кеше буларак, аның безгә, яшьрәк буын кешеләренә, сөйлисе сүзләре күп иде. Үзенең соңгы елларына кадәр ул иҗат кешеләре белән еш очрашып, аралашып яшәде. Ул, гадәтенчә, самими елмаеп, шаян сүзләр табып безне сәламли, хәл-әхвәлләребез турында сораша торган иде. Галия ханымның сәнгатькәрләр арасында дуслары күп иде. Без — аны яхшы белгән сәнгать әһелләре, аның яраткан тамашачылары — һәрдаим сагынып искә алабыз.

*2005*

## Сәнгатькә багышланган гомер

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының 100 еллыгына аз вакыт калып бара. «Театр — милләт язмышының һич тутыкмас көзгесе» дибез. Чыннан да, бер гасырга якын тарихы булган милли театрыбыз илебезнең төрле дәвер вакыйгаларын чагылдырган әсәрләр аша, бөек Тукаебыз әйткәнчә, халыкка дәрсе гыйбрәт өләшеп, яктылыкка, нурга илтүче олы мәктәп буларак зур хезмәт күрсәтеп килә.

Шушы гасырга якын вакыт эчендә театрыбыз сәхнәсендә татар, рус, Көнбатыш илләр драматургиясеннән нинди генә жанрларда әсәрләр куелмаган да, аларны берничә буын нинди генә талантлы актерлар һәм режиссерлар башкармаган! Куанычлысы шул: бүгенге көндә өлкән яшьтәге сәнгатькәрләр булып саналучы без фәкыйрегезгә дә 40 нчы еллар ахырыннан бүгенге көнгә кадәр театрыбыз сәхнәсендә олпат драматургларыбыз әсәрләрендә бөек режиссерлар һәм актерлар тудырган бихисап гүзәл эшләрне күреп соклану бәхете насыйп булды. Театрыбызның йөзьеллык олуг юбилее уңае белән бу гүзәл иҗат оешмасының үткәндәге һәм бүгенге көндә эшләүче сәхнә осталары аларның эшчәнлеге турында күп язарлар дип уйлыйм.

Ә бүген минем каләм тибрәтергә алынуыма озак еллар буена бергә аралашып яшәгән, берникадәр вакыт театрда бергә эшләгән дустыбыз, театрыбыз тарихында үзенең фидакарьләрчә хезмәте белән тирән эз калдырган олуг талант иясе, гүзәл актер һәм режиссер, Татарстанның халык артисты, Россиянең атказанган сәнгать эшлеклесе Празат Нәкый улы Исәнбәтне сагынып искә алу, аның сәнгатебезгә керткән зур эшчәнлегенә кыскача гына тукталу, гүзәл шәхеснең кешелек сыйфатлары алдында уебызда гына булса да тагын бер тапкыр баш ию теләге сәбәпче булгандыр. Бик кызганыч, Празат дустыбыз безнең арабыздан ир-

тәрәк китте. Ул үзенең соңгы көннәренә кадәр театрына тугрылыклы булып хезмәт итеп дөнья куйды. Хәзер театрга барсам, беренче эшем итеп театр корифейларының портретлары элengән галереяга борылам. Анда Празат Исәнбәтнең дә рәсеме куелган. Рәсемгә карагач, театрда һәр күрешү вакытында мәгълүм бер позада, башын бераз гына кыегайта төшеп, мөлаем елмаеп, сиңа ерактан ук сәлам биреп торучы, хәзер синең белән гәп корырга әзер булган Празат дустыбызны күргәндәй буласың, әнә ул, тәмләп сөйләшергә әзерләнгәндәй, кулына папиросын да алган... Менә хәзер ул көлә-көлә нindидер кызык хәл турында сөйләр, үзе сөйләгәне әңгәмәдәшенә нинди тәэсир уятканын хәйләкәр генә күзәтеп алыр...

Гаҗәеп кызык була торган иде аның белән сөйләшүләр, ул гаҗәп күп белә, күп укыган, күпне күргән, дөнья әдәбияты белән яхшы таныш иде. Театрда режиссер нәкъ шундый булырга тиеш дигән уй туа иде һәркемдә.

Язучы Рабит Батулла «Мәдәни җомга»ның 2002 елгы 7 июнь санында басылган «Театрның өч субае» дигән мәрсиясендә Празат Исәнбәт турында мондый юллар язган иде: *«Атаклы галим, шагыйрь, мәшһүр драматург, татар әдәбиятының, татар сәнгатенең, татар мәгърифәтенең алып каһарманы Нәкый ага тәрбиясен алган актер һәм режиссер Празат Исәнбәтнең хезмәте тарихта җуелмаслык эз калдырды.*

*Празат Исәнбәт татар театрларының барысында да диярлек спектакльләр куйды, һәм, әйтергә кирәк, ул үз ысулына, тәрбияви ысулына хыянәт итмәде. Шуңа күрә Празат ага белән эшләгән актерлар аңа мәңге рәхмәтле булып калды».* Талантлы кеше ул һәрьяклап уңган була бит. Празат та яшьлек елларында рәсем ясау сәнгате белән кызыксына, бераз сәнгать мәктәбендә укып та ала. Ләкин әдәбият һәм сәнгатьне яратуы тора-бара аны театр дөньясына якынайта, һәм ул 1944 елда Мәскәүнең театр сәнгате институты (ГИТИС) каршында ачылган Татар студиясенә укырга китә. Минем беренче мәртәбә Празат белән танышуым 1948 елны Мәскәүдә булды. Безне Казан театр мәктәбенең диплом спектаклен — А.Арбузовның «Яшьлек белән очрашу» исемле лирик комедиясен күрсәтү һәм башкала театрлары спектакльләре белән таныштыру нияте белән бөтен курсыбыз белән Мәскәүгә алып барганнар иде. Әлбәттә, ГИТИСта укучы татар яшьләре белән очрашу да булды. Алар да, без дә үзебезнең кайбер иҗади эшләребез белән таныштырдык. Шунда без К.Гоцциның «Болан-Патша» спектакленнән күрсәтелгән өзектә Дерамо ролендә Празат Исәнбәтне беренче тапкыр күрдек. Озын буйлы, матур кыяфәтле, пластик хәрәкәт итүе белән аерылып торган бу егет барыбызның да игътибарын җәлеп итте. Шуның өстенә бик оста итеп грим салуы да күзгә ташланды. Бу егет киләчәктә Казан сәхнәсендә үзенең лаеклы урынын табар дигән уй килде. Педагоглары — мәшһүр режиссер О.И.Пыжованың да Празатның эшенә хәерхаһ булуы күренеп тора иде.

ГИТИСны тәмамлап кайткач, 1950 елда П.Исәнбәт Татар дәүләт академия театрында актер булып эшли башлый. Ул елларда башкарган рольләрдән: Кодар — «Козы-Көрпеш һәм Баян Сылу» (Г.Мусрепов), Васильков — «Котырган акчалар» (А.Островский), Рендич — «Бер көн элек» (И.Тургенев), алда телгә алынган «Болан-Патша» спектакленнән Дерамо һ.б. исебездә калган. Театрда эшләү вакытында Празат режиссерлык һөнәре белән дә бик кызыксына башлый. Театрда берничә ел эшләгәннән соң, ул яңадан Мәскәүгә — ГИТИСка укырга китә, бик тырышып режиссерлык һөнәренең серләренә төшенә. Ул илебезнең мәшһүр режиссеры А.Попов классында укый. Укуын тәмамлагач, П.Исәнбәт 1962 елдан Академия театрында режиссер булып эшли башлый. Театрда диплом эше итеп ул Н.Исәнбәтнең «Муса Җәлил» спектаклен куя. Бу спектакльдә миңа А.Алиш ролен башкарырга туры килде, ә Празат үзе Идриси ролен бик оста башкарган иде. Шул спектакльне эшләү процессында без Празатның башка режиссерлардан бераз аермалы булган эш алымнарын күрдек. Ул актерга ышана, аның иҗади фантазиясен арттырырга булыша, әмма ләкин коры «диктат» юлы белән түгел, ә актер белән дустанә иҗат итәргә тырыша иде. Әлбәттә, кирәк чакта ул таләпчән дә була белә иде. Гомумән, театр актерлары Празат белән эшләү елларын сагынып сөйләргә яраталар.

П.Исәнбәтне республикабызның башка драма театрлары да спектакльләр куярга чакыралар иде. Театрда 40 елга якын эшләү дәверендә режиссер йөзгә якын спектакль куйган. Бик зур хезмәт бит ул! Никадәр персонажлар турында уйлану, төрле характердагы бихисап актерлар белән театр рәссамнары, ут кую осталары, костюмерлар, гримерлар, шулай ук композиторлар, ә иң мөһиме, драматурглар белән уртак тел таба белү режиссердан осталык, зур интеллект, кирәк чакта таләпчәнлек вә түземлелек сорый торган авыр, шул ук вакытта нечкә психологик эш алымнарын таләп иткәндер. П.Исәнбәт куйган кайбер спектакльләрне күрсәтеп китик: «Мулланур Вахитов», «Һиҗрәт», «Гөлҗамал» (Н.Исәнбәт), «Җырланмаган җыр» (М.Кәрим), «Татар хатыны ниләр күрми» (Г.Ибраһимов), «Туй алдыннан» (Х.Вахит), «Чамасына күрә чарасы» (В.Шекспир), «Суган суфые» (Мольер), «Кол» (Г.Фигерейдо), «Юләр кыз» (Лопе де Вега), «Банкрот» (Г.Камал), «Ике фикер» (Г.Коләхмәтов), «Яшь йөрәкләр» (Ф.Бурнаш), «Зөләйха», «Алдым-бирдем» (Г.Исхакый) һ.б. Болар режиссерның зур иҗат активында булган спектакльләрнең кайберләре генә. Никадәр иҗат фантазиясен, белем, актерлар белән оста эш итү алымнарын таләп иткән тынгысыз хезмәт җимешләре бит ул тудырган спектакльләр. Тамашачылар һәрвакыт П.Исәнбәтнең иҗади хезмәтен олы бәяләделәр, аны хөрмәт иттеләр, яраттылар.

Празат Нәкый улының театрдагы хезмәтләрен Татарстан һәм Россия Федерациясе хөкүмәтләре югары бәяләделәр, ул мактаулы исемнәргә лаек булды. Әмма театр җитәкчелеге тарафыннан аның иҗаты тулы бәһане алып бетермәде дип әйтәсе килә. Театр сәнгатебезгә шулкадәр зур хезмәт куйган режиссерның

иҗаты республикабызның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек түгел идемени? Ничек кенә лаек иде, аның татар сәхнәсенә бөек Г.Исхакыйның берничә әсәрен иң беренче булып кайтаруы, аның «Зөләйха»сын кую гына да бу мәртәбәле бүләккә лаек икәнен кычкырып әйтеп торалар иде. Празатның рухи тәрәге, хатыны Әлфия ханым белән сөйләшкәндә, аның Г.Исхакый исемендәге премиясе дә юклыгын ишетеп шаклар каттым. Инде кемнәргә генә бирмәделәр ул премияне, ә Г.Исхакый әсәрләренең эчендә кайнап, аларны матур итеп сәхнәләштереп, халыкка җиткергән режиссер гел читтә калып килде. Болар барысы да театрның художество җитәкчелегенең талантлы режиссер иҗатына тиешле бәяне бирмәүнең аянычлы бер нәтиҗәсе инде.

Олы җанлы сәнгатькәр дустыбыз турында язганда мондый негатив күренешләрне күрсәтү күңелсез хәл, әлбәттә. Әмма әйтмәү дә ярамый торган гамәл. Празат дустыбыз оптимист кеше иде, горур һәм туры сүзле шәхес иде, бәлки, аның күңеленең кайсыдыр почмагында бу гаделсезлек күренешләренә рәнҗү чаткылары да тугандыр. Әмма ул үзенең борчылуларын кешегә күрсәтмәде, ул боларның барысыннан да өстен иде...

Театрны үзенең рухи дөньясы иткән хезмәт сөюче олы сәнгатькәр, актерларның якын дусты Празат Нәкый улы Исәнбәт коллегаларын, дусларын, тамашачыларын бик озак сагындырып торыр әле... Аның гүрдә рухы тыныч, урыны җәннәттә булсын! Амин!

*2004*

## «Игътибар, микрофонны ачам!»

Бу сүзләр радиода эшләгән һәркемнең күңелендә тылсым булып гомергә саклана. Чөнки диктор микрофонны ачып эфирга чыккач, тапшыруларны әзерләүдә катнашучыларның һәм тыңлаучыларның игътибары беренче нәүбәттә дикторның осталыгына юнәлтелә.

Диктор өчен тагын бер тылсымлы гыйбарә: «Тыңлагыз, Казан сөйли!»

Казаннан еракта яшәүче милләттәшләребезне дә республикабыз башкаласы белән бер дулкында булырга чакырган бу сүзләр белән инде 75 ел эшләп килүче Татарстан радиосы студияләрендә берничә буын дикторларыбыз, микрофоннарны ачып, эфир киңлекләренә чыктылар.

Бүгенге язмамда сүзем шул сүз тылсымы иясе, радиотыңлаучыларның яраткан дикторы, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Васфикамал Мәгъсүм кызы Саттарова турында. Кайда һәм кайчан ишеттем соң мин беренче тапкыр Камал Саттарова тавышын? 40 нчы елларның урталарында Башкортстанның Балтач районында без Казан тапшыруларын көтеп ала торган идек; Камал ханымның гади дә, шул ук вакытта үзенең ягымлылыгы белән тыңлаучыны сихерли торган тавышын, гаҗәеп матур аһәң белән яңгырый торган Казан арты сөйләмен тыңлап туя алмый идек... Шушы сүзләрне яздым да бераз көлемсерәп куйдым. Төрле елларда Камал ханым белән бергә эшләгән дикторлар да үзләренең истәлек язмаларында аның тавышын беренче ишетүләрен минем кебегрәк язганнар лабаса.

Күренекле дикторыбыз, бүгенге көндә фән докторы, профессор Фоат Галимуллин ул мизгелләрне болай тасвирлый: *«Миңа 14 яшьләр чамасы булгандыр. Безнең авылда гаҗәеп бер вакыйга булды. Урамның буеннан-буена баганалар утыртып чыктылар һәм һәр өйгә шулардан чыбыклар суздылар. Әни Нократ Аланына базарга барган җиреннән кара эшләпәле «радиу» алып кайтып куйды. Өйгә әллә нинди колакка ятышсыз музыка тавышы таралды. Шулай бөтенләй өмет өзелгәч, берзаман «Казан сөйли!» дигән сүз яңгырамасынмы! Минем колакларым үрә торды, кара тәлинкә янына барып басканымны сизми дә калдым. Аннан исә бик матур хатын-кыз тавышы ишетелә иде. Һәр сүзен йотып баруымны әни дә күзәтеп торган икән. Теге апа сөйләп бетергәч «укыды Камал Саттарова» дип куюга: «Сөбханалла, шулкадәр матур, ягымлы сөйли. Бу гади генә кеше түгелдер, остабикәдер бу. Китап сүзләрен ничек килешле итеп әйтә», — дип, әни тел шартлатты».*

Шулай ук К.Саттарова белән күп еллар бергә эшләгән, радиотыңлаучыларның яраткан дикторы Эльс Гадел дә үз язмасында болай дип искә ала: *«Ничәнче ел булгандыр инде, шул елны гына бөтен авылны яңгыратып тора торган радио керткәннәр иде. Минә танышым Сания белән Салагыш урамнарыннан атлыйбыз. Ә урамда радио яңгырый. «Казан сөйли!» Шундый да матур, күркәм авазлар. Әйтте шунда бер тавыш: «укыдылар Айрат Арсланов һәм Камал Саттарова», — диде.*

Минә шуннан бирле Камал апа Саттарова бер хыял сыман минем бәгъремә кереп ятты, һәм һаман да искә төшкән саен үзәкләр өзелеп китә. «Укыды Камал Саттарова». Әйтергә генә җиңел ул, ә укуы?! Ул хәзерге кебек микрофон янына кердең дә быкылдап чыктың түгел иде шул. Таләпләр каты иде. Унсигез ел бергә, бер микрофон янында эшләгән кешеләр булгач, әйтә алам: Камал Саттарова мәшһүр диктор иде. Шушында әлеге дә баягы бер сорау куясың инде: «Каян чыга соң ул андый талант ияләре?!»

Язылганнардан күренгәнчә, безнең һәркайсыбыз, әле Казанга килгәнче, радиода дикторлык хезмәтен башлаганчы ук, Камал Саттарованың мавыктыргыч сөйләвен, табигать тарафыннан куелган (радио хез-

мәткәрләре әйтүенчә, махсус радио өчен яратылган) тавышын, күпләр өчен эталон буларак яңгыраган әдәби телдә сөйләвен ишетеп, аның дикторлык осталыгы, таланты алдында баш игәнбез.

Казан арты авыллары төрле елларда әдәбиятыбызга һәм мәдәниятебезгә бик күп атаклы шәхесләр — язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, җырчылар биргәнен беләбез. Шулай ук безнең Татарстан радиосында да Казан артыннан чыккан күренекле шәхесләр төрле елларда эшләделәр. Шундыйларның берсе — элекке Дөбъяз районының (хәзер Биектау) Торнаяз авылыннан сугыш елларында Казанга килеп радиога диктор булып эшкә урнашкан Васфикамал Саттарова була. Ул татар радиосында микрофон алдында эшләвен гомеренең соңгы елларына кадәр — 40 елдан артык дәвам итте.

Ул конкурста җиңеп эшкә килгәндә, радиода диктор булып Зәйнәп Шәйхулла кызы Хәйруллина эшли. Зәйнәп апа радиога килгән яшьләргә бик игътибарлы була, аларга дикторлык осталыкларын чарлауда зур ярдәм итә. Еллар үткәч, үзенең истәлекләрендә К.Саттарованың радиода эш башлавы турында болай дип искә ала: *«Һәр көнне аның белән күнегүләр алып бару, аны дикторлыкка өйрәтү миңа йөкләтелде. Васфикамал бик тырыш иде. Күп тә үтми, тапшыруларны үзе алып бара башлады. Иртәнге тапшыруларга әзерләнү өчен ул эшкә иртән сәгать бишенче яртыга килеп җитә иде. К.Саттарованың эш күнегүләре авыр сугыш елларында башланды».*

Ә сугыштан соң татар радиосына без эшкә килгәндә, Камал Саттарова инде үзе яшьләргә һәрьяклап ярдәмгә килүче, үз эшенең остасы, тыңлаучыларның яраткан дикторы иде. Мин аның белән микрофон алдында 10 елга якын эшләдем. Эшләү дәверендә аның дикторлык һөнәренең нечкәлекләренә тирәнрәк төшенергә тырышуын күреп гаҗәпләнә дә, соклана да идем. Радиода дикторга укырга туры килә торган материаллар күптөрле: болар — информацияләр, публицистик мәкаләләр, галимнәрнең лекцияләре, әңгәмәләр, гәзит мәкаләләре, сәнгати проза, шигырьләр һ.б. Дикторга һәртөрле эчтәлекле, төрле авырлыклар очрый торган материалларга тиз һәм дөрес төшенергә, таныш булмаган сүзләр, атамаларны дөрес әйтә белергә, чит ил терминнарын үзләштерергә кирәк. Диктордан шулай ук бер материалдан икенчесенә бик тиз күчә белү осталыгы да таләп ителә. Аның тавышы җиңел, сыгылма, хәрәкәтчән булырга тиеш. Бу сыйфатлар аңа сөйләмдә булган көйле борылышлар һәм тембрдан оста файдалану мөмкинлеге бирә. Диктор тавышының тагын бер үзенчәлеге — аның киң диапазонлы булуында. Тавышның бөтен көчкә яңгырый алуы, диапазонының киңлеге, кирәк чакта тавышның югары, түбән һәм урта регистрларда эшли алуы интонацияне төрлеләндерү, тавыш палитрасын баету мөмкинлеген бирә. Әлбәттә, диктор сөйләменең иң мөһим сыйфатларыннан тагын берсе — яхшы дикция һәм төгәл артикуляция.

Дикторның төп вазифасы — уку. Моның өчен аңа төгәл логик уку күнегүләре үтү таләп ителә. Укыла торган текстның эчтәлегенә керә белү, интонация, темп, ритмның автор уйлаганнар белән катгый тәңгәллеге кирәк. Сүз уңаеннан әйтеп үтәсем килә, бүгенге көндә Казанда күп радиоларның дикторлары үз тапшыруларында дөрес булмаган темпоритмда эшләү белән интонацион дөреслеккә ирешә алмый. Бу, әлбәттә, аларның осталыгына зур хилафлык китерә. Югарыда язылганнар диктор хезмәтенең кайбер үзенчәлекле якларын гына чагылдыра. Диктордан үз хезмәтенә таләпчәнлек сорала, радиотыңлаучылар, диктор эшенә карап, һәрбер радио коллективы хезмәтенә бәя бирәләр. Камал Саттарова осталыгын даими камилләштерә иде. Бөтенсоюз радиосының мәшһүр дикторлары Ю.Левитан, Н.Толстова, О.Высоцкая һ.б. аңа үрнәк булып тора иде. Ул Бөтенсоюз радиосы оештырган курсларда укыды, гел дикторлык һөнәренең нечкәлекләрен өйрәнә, осталыгын һәрдаим чарлый иде. Ә Казанда исә берничә дистә ел эшләү дәверендә күп дикторлар: М.Хәбибуллина, Ф.Колбарисов, А.Арсланов, Ә.Сафиуллина, И.Ихсанов, Н.Черкашина, Н.Иртуганов, Н.Савельев, И.Латыйпов, Э.Гаделев, Г.Земенкова, Ф.Галимуллин, М.Арсланова һ.б. белән бергә тәҗрибә алмашып, дикторлык осталыгын күтәрү өлкәсендә зур тырышлык куеп Татарстан радиосына хезмәт итте.

Камал Саттаровага 50 яше тулган көнне, ягъни 1973 елның 30 июлендә, радиодагы хезмәттәшләре котлау яздылар: *«Кадерлебез Камал! Нурлы Казан, моңлы Казаныбыз сезнең тел белән сөйли. Сезнең тавышыгыз — Татарстан кырларына, Идел—Кама буйларына сузылган могҗизалы күпер ул. Шул күпер аша күпме хәбәр, тормышыбызны бизәүче яңалыклар, шатлык аһәңнәре узган. Без сезне ничә дистә еллар тыңлыйбыз — туймыйбыз. Рәхмәт хисләре белән кулыгызны кысып, баш иеп сезгә әйтәбез: сез сөйләгез әле, Камал апа, сөйләгез әле...»*

Бу котлаулардан соң әле тагын 12 ел Васфикамал Мәгъсүм кызы Саттарова радиотыңлаучыларны сөендереп сөйләвен дәвам иттерде...

*2003*

## Шагыйрь белән соңгы очрашу

Заманында Башкортстан шагыйрьләре белән еш очраша, аралаша торган идек. Татар-башкорт язучыларының һәм шагыйрьләренең дуслыгы күп еллар аша сыналган, нык, чын иҗатчылар дуслыгы булды. 50—70 нче елларда Казанның Тукай клубы шагыйрьләр, язучылар, әдәбият сөючеләр белән гөрләп торды.

Әлбәттә, Уфа кунаклары, нинди генә эш яки йомыш белән килсәләр дә, Тукай клубында очрашуларда катнашырга вакыт табалар иде.

Безнең үзебезгә дә филармония концертлары белән Уфада һәм Башкортстанның күп шәһәр-районнарында бик еш булырга туры килде. Башкортстанның халык шагыйре Сәйфи ага Кудаш белән минем беренче очрашуым һәм танышуым да Башкорт дәүләт опера һәм балет театрында үткән концертларыбызның берсендә булды.

Концертта мин Мостай Кәрим белән Сәйфи Кудашның да берничә әсәрен укыдым. Тәнәфес вакытында безнең янга җырчылар — башкорт дусларыбыз керделәр. Шулардан берсе мине эзләп йөрүче мөлаем бер агай белән таныштырды. «Мин шагыйрь Сәйфи Кудаш булам, — дип сүз башлады ул, — бүген минем әсәремне дә башкарганыгыз өчен рәхмәт әйтергә дип кердем. Бик матур укыдыгыз. Сезне Казан радиосы аша да бик яратып тыңлыйбыз. Сезнең иҗади эшегездә уңышлар телим. Уфага килгәндә менә шушы телефон белән миңа шылтыратыгыз, өемә кунак булып килсәгез, тагын да яхшырак булыр», — дип, ул миңа телефонын язып бирде һәм саубуллашты. Әлбәттә, бу очрашудан соң мин Уфада филармония концертлары, телевидение фестивальләрендә, сәнгать бәйрәмнәрендә күп тапкырлар катнаштым. Сәйфи ага белән берничә тапкыр телефоннан сөйләштек, ул безнең сәнгатьтәге яңалыклар белән кызыксынды.

Уфага концерт бригадасы белән тагын бер барганда мин «Агыйдел» кунакханәсеннән Сәйфи агага шылтыратып, хәл-әхвәлен сораштым, сүз арасында ул: «Синең укуыңда Өфе радиосыннан М.Кәрим һәм Н.Нәҗми әсәрләрен тыңладым, алар татар телендә шундый матур яңгырадылар, яраттык укуыңны. Безнең Өфедә татарлар бихисап бит ул, безгә килгән чакларыңда син башкорт шагыйрьләрен күбрәк укып калдыр, тыңлаучыларның күңеленә хуш килер», — дип куйды. Үз чиратымда мин дә: «Сәйфи ага, хәзер сезнең әсәрләргә чират җитте, кайсы әсәрләрегезне радио аша ишетәсегез килә, шуларның исемнәрен язып бирегез әле, мин китапханәдән китабыгызны сорап торып, радиога язылып китәр идем...» — дидем. «Нигә китапханәгә барып, вакытыңны әрәм итеп йөрергә, китапны мин үзем бирермен, иртәгә иртәнге якта вакытың бармы, безгә кереп чык, шунда барысын да сөйләшербез», — диде.

Икенче көнне мин аларга бардым. Сәйфи ага һәм аның бик мөлаем хатыны Мәгъфүрә ханым мине бик җылы каршыладылар. Чәй өстәле янында күңелле генә сөйләшеп утырдык, алар Казан яңалыклары белән кызыксындылар, минем кайсы якныкы икәнемне сораштырдылар. «Мин Балтач районында үстем, шунда укыдым», — дигәч, Сәйфи ага: «Ямьле Танып суы буенда үскәнсең икән», — дип куйды. Сүз арасында Сәйфи ага минем яраткан шагыйрьләрем белән кызыксынды. «Балтач мәктәбендә барыбыз да Тукташ әсәрләре белән «җенләнә» идек. Тукайны яратуда татар телен укыткан укытучыларыбызның да өлеше бардыр. Мәҗит Гафури әсәрләрен концертларда укыдым. Сәйфи ага, мин укып беләм, сез Гафуриның якын дусты булгансыз, тормышта нинди иде ул?» — дип сорап куйдым. «Бик тыйнак, мөлаем, кешеләргә үтә мәрхәмәтле, шул ук вакытта туры Тукай кебек, турысын әйтергә, дөреслекне ярата иде», — диде Сәйфи ага һәм кыскача гына кызыклы бер вакыйганы сөйләп алды: «Мәҗит Гафуриның иҗади эшчәнлегенә егерме ел тулуны хөкүмәт күләмендә «Комклуб» (элекке Дворянское собрание) бинасында бик зурлап үткәрделәр.

Бик күп котлаулар, кыйммәтле бүләкләр тапшырылды, бүләкләр арасында чылбырлы зур алтын сәгать аерылып тора иде. Икенче көн мин авылга китәргә тиеш идем, Гафури янына хушлашырга бардым. Гафури тәбрик хатларын, котлау телеграммаларын карап утыра иде. Бүләкләр арасында алтын сәгать кенә юк иде.

Гафури ул кыйммәтле бүләкнең Уфа нэпманнары тарафыннан бирелүен белгән дә: «Юк, шагыйрьләр алтынга сатылмыйлар», — дип, аны тәрбиячесез калган ятим балаларга ярдәм итү комиссиясенә тапшырган. Менә шундый иде ул безнең дә туры Гафури», — дип тәмамлады сүзен Сәйфи ага. Тагын бераз сөйләшеп утыргач, мин китәргә ашыктым. Сәйфи ага миңа үзенең китабын бүләк итте һәм радиодан ишетәсе килгән 10—15 әсәрнең исемлеген бирде.

Күп еллар үтте. 1980 елның июль ахырында миңа кызым Гөлнар белән яңадан Уфага барып чыгарга туры килде. «Агыйдел» кунакханәсенең вестибюлендә дус шагыйребез (хәзер инде мәрхүм) Рафаэль Сафин белән очраштым. «1 август көнне Мәҗит Гафурига Башкорт академия театры каршында һәйкәл ачу була, сине шул тантанага чакырам, чыгыш та ясарсың», — диде ул, үзе каядыр ашыга төшеп.

Икенче көнне театр каршындагы мәйданга халык күп җыелган иде. Халкыбыз тарафыннан яратып укыла торган татар-башкорт шагыйре Мәҗит Гафуриның йөзьеллыгы көнендә аңа матур һәйкәл ачылды. Башкортстан язучылары һәм шагыйрьләре белән бергә мин дә чыгыш ясап М.Гафури әсәрен укыдым. Чыгыш ясаучылар төркеменең читендәрәк таныш гәүдә күземә чалынды. Янымда торучы иптәштән сорадым, ул: «Сәйфи ага Кудаш үзе була инде», — диде. Мин әкренләп кенә аның янына бара башладым. Пөхтә итеп киенгән Сәйфи ага өстендә үзенә килешеп торучы соры плащ, башында эшләпә. (Сәйфи ага гомере буена чибәр кеше булды!) Аның янында күбрәк яшьләр, студентлар булса кирәк. Мин Сәйфи ага янына килеп исәнләшкәч, тавыштан таныды. Ул минем кулымнан һәм беләгемнән кысып тотты: «Минем күзләрем начарайды бит, бер әйбер дә күрмим», — диде.

Аның белән бераз сөйләшеп торгач:

— Ә мин бирегә килергә чыккач, китап кибетенә кереп чыктым, киштәдә бик матур китабыгызны күреп сатып алдым. Сезнең үзегезне очратуым билгесе кебек булды, — дип куйдым.

— Нәрсә, автограф язарга кирәктер инде, авторны очраткач, — диде ул.

Сәйфи ага кесәсеннән каләмен чыгарды да китапка имзасын куйды.

— Менә булды, дустым, бүгенге бәйрәмнең истәлеге булсын! Миңа 86 тулды бит, Айрат, инде күзләргә дә ял кирәктер.

Шунда без озак кына кул кысышып хушлаштык. Бу минем яраткан шагыйрем Сәйфи ага Кудаш белән соңгы очрашуым булган икән. Тагын ун ел үткәч, Казанда «Шәһри Казан» гәзитендә аның «Күзләрем» исемле зур гына шигырен укыдым. Шигырьдә шундый юллар бар иде:

Көтмәгәндә бердәй икесе дә
Сафтан чыкты минем күзләрем,
Мин аларны саклый алмадыммы,
Сакламадыларммы үзләрен...

*2003*

## Театрыбызның олпат заты

Казанда Бөек Ватан сугышы тәмамланган 1945 елны дәүләт консерваториясе һәм сугыш афәте башлангач берничә ел үзенең эшен туктатып торган театр училищесында да укулар башлана, татар сәнгате өчен яшь кадрлар әзерләү эшенә зур игътибар бирелә. Театр училищесына укырга төрле төбәкләрдән — Татарстан районнарыннан, Башкортстаннан, хәтта Казакъстаннан да килгән укучылар була, күбрәге, әлбәттә, Казаннан, шәһәрнекеләр булалар.

Мин Казанга укырга 1946 елны килдем. Сугыштан соңгы авыр еллар иде, ләкин сәнгатькә мәхәббәт, бернинди авырлыкларга карамастан, мине актерлар әзерли торган татар театр мәктәбенә китерде. Режиссерлар Сәет Булатов, Кәшифә Тумашева һәм Шарияздан Сарымсаков алдында имтихан тотканнан соң, мине училищеның икенче курсына, шушы уку йортының директоры Сәет ага Булатов классына укырга алдылар. Курсташларым белән таныша башладым. Көннәрдән бер көнне: «Ә менә бу егет Сабадан килгән сабакташыбыз Шәүкәт Биктимеров була инде», — дип, Ренат Сакаев мине кабарып торган җирән чәчле бер егет белән таныштырды. «Ә син үзең кайсы яктан килдең?» — дип сорады Шәүкәт. Башкортстанның Балтач районыннан булуымны белгәч: «Анда да Балтач бармыни?» — дип кызыксынды. Шәүкәт Биктимеров белән беренче танышуым шулай башланды. Безгә, авылдан килгән егетләргә, шәһәр тормышы, театрда эшләүче укытучыларыбыз белән сөйләшүләр, гомумән, театр, сәнгать мохите — барысы да яңа, кызыклы иде. Училищены тәмамлап күп еллар үткәч, бергә укыган дустыбыз Госман Әхмәтҗанов үзенең һәм Шәүкәтнең училищега керү имтиханнары бирү вакытында булган кызыклы маҗаралары турында көлеп сөйләргә ярата иде. Шәүкәтнең беренче имтиханы турында ул болай дип сөйли торган иде:

«Шәүкәттән өч педагог имтихан алган: Шарияздан Сарымсаков, Сәет Булатов һәм Кәшифә апа Тумашева. Шарияздан ага белән Сәет ага ни турындадыр кызып-кызып сөйләшәләр икән.

Сәет ага Шәүкәткә күз атып ала да:

— Бар, бас әнә шунда, сөйләрсең, — дип, класс тактасы ягына ымлый.

Шәүкәт, сөйлисе булгач, монысы сәхнәдер инде дип уйлый да шунда торган рояль өстенә менеп китә. «Әтәч һәм энҗе бөртеге» мәсәлен сөйли. Тик аңа игътибар итүче генә юк. Шәүкәт мәсәлне яңабаштан сөйли. Ниһаять, укытучыларның берсе борылып карый моңа. «Нишләвең бу, төш аннан, ничек менеп бастың анда, хәзер үк төш!»— дигәч, Шәүкәт чак егылып төшми. «Сөйлә!» — дип боергач, Шәүкәт каушый-каушый гына тагын сөйли.

Сәет ага ирония белән: «Син үзеңнең тирестә актарынган шул әтәч хәлендә калуыңны белдеңме инде хәзер?» — ди. Шәүкәт каушап кала, димәк, бар да бетте дигән сүз.

Шулчак Кәшифә апа кычкырып җибәрә:

— Алам мин бу баланы, үз группама алам! Аның күзләрендә очкын бар. Мин аны әтисе белән дә күрдем. Аның әтисе дә кайгыртучан кеше күренә. Бу бала әле үсәчәк!

Шулай итеп, Шәүкәт театр мәктәбенә укырга керә».

Менә хәзер уйланып утырам да, Шәүкәтнең әтисе Хәсән ага нинди мәдәни күңелле кеше булган, улының киләчәктә татар театры күгендә кабыначак яңа йолдыз булачагы турында да хыялланагандыр әле ул. Ул бит Шәүкәтне, авылда укулар тәмамлангач, колхозда эшләп йөргән җиреннән Казанга алып килгән. Биредә, әлбәттә, Шәүкәтнең туганнан туган апасы, Академия театрының күренекле актрисасы Галимә ханым Ибраһимованың да үз туганын киләчәктә театр сәхнәсендә күрергә теләве булышлык иткәндер...

Татар дәүләт театр училищесында сугыштан соңгы ифрат авыр елларда укып йөрүебезне без курсташлар хәзер дә бергә очрашкан вакытларда сагынып искә алабыз. Алтмыш елдан артык вакыт үткән. Кызганыч, педагогларыбызның күбесе арабызда юк инде, урыннары җәннәтнең түрендә булсын. Училищены тә-

мамлаучыларның байтагы милли сәнгатебезнең төрле тармакларында уңышлы хезмәт итеп, хөкүмәтебез бүләкләренә һәм мактаулы исемнәргә лаек булдылар.

Без барыбыз да, театр училищесының беренче чыгарылыш артистлары арасыннан халкыбызның яраткан сәхнә остасы, республикабызда гына түгел, Россия театр җәмәгатьчелеге арасында, шулай ук чит илләрдә дә үзенең гүзәл сәхнә образлары белән яхшы билгеле булган Шәүкәт Хәсән улы Биктимеров иҗаты белән хаклы горурланабыз. Аның тарафыннан Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә татар, рус, Европа драматургиясе әсәрләре буенча куелган спектакльләрдә бихисап образлар иҗат ителгән. Алар психологик тирәнлекләре, тормышчан, киң масштаблы булулары белән игътибарны җәлеп итәләр. Артист — үз каһарманнарының эчке тойгыларын бөтен тирәнлеге белән күрсәтә ала торган зур сәхнә остасы. Аның иҗатына хас гадилек, тормышчанлык, гаҗәеп сәхнә дөреслеге татар театрында актерлык сәнгатенең иң яхшы традицияләрен дәвам итү булып тора. Актерның төрле образларда уйнау һәм сөйләү манерасы тамашачыны таң калдыра. Сөйләү манерасы дигәннән, драма артистының сүзгә зур әһәмият бирүе көн кебек ачык. Бу нисбәттән немец философы Ф.Ницше болай дигән: *«Телдә сүзгә караганда да мәкам, шул сүзләрне әйткән энергия, модуляция, темп әһәмиятлерәк. Кыскасы, сүз белән көй, шул көй артында торучы тойгы-ялкын, әлеге тойгыны тудыручы шәхес — болар каләм белән генә аңлатып булырлык түгел».*

Ш.Биктимеровның ярты гасырдан артык иҗат итү чорында театрда, радио һәм телевидениедә, кинода тудырган рольләрен санап чыгар өчен дә күп вакыт кирәк булыр иде. Ә бит актер — драматург һәм язучыларның кәгазьгә язган текстларына күңел һәм йөрәк җылысын биреп җан өргән олуг шәхес ул. Дистәләрчә образларны тудыру өчен сәхнә остасыннан күпме уйлану, күпме йокысыз төннәр, күпме эзләнү, материаллар актару сорала. Шәүкәт үзе болай ди: «Иҗат кешесе иҗаттан туймый, аңа һәрвакыт эш кирәк. Мин бервакытта да эшсез калмадым, рольләр мәсьәләсендә каршылыклар очрамады. Боларның барысы өчен дә мин театрыма рәхмәтле». Шәүкәт — бәхетле артист, аның яраткан тамашачысы һәм олы иҗатын хөрмәт иткән, яраткан коллегалары бар. Театрның кайсы гына цехына керсәң дә, Ш.Биктимеровка карата булган зур хөрмәтне тоясың. Аның белән бүген дә сәхнәдә бергә уйнаучы яшьрәк буын артистларыннан: *«Аллага шөкер, без Шәүкәт абый кебек зыялы, даһи артист белән эшләдек һәм киләчәктә дә эшләргә насыйп булсын! Яшә, исән бул, хөрмәтлебез Шәүкәт абый!»* — дигән мактау сүзләрен ишетәсең. Бу изге теләкләргә без дә, аның сабакташлары һәм сәнгатьтәшләре, бик теләп кушылабыз.

*2006*

## ТӨП БИОГРАФИК ДАТАЛАР

1928 елның 10 апрелендә Башкортстанның Бүздәк районы Ахун авылында туа.

1935—1945 — Башкортстанның Балтач урта мәктәбендә укый.

1946—1949 — Казан дәүләт театр училищесында укый.

1948—1956 — Татарстан радиосында диктор һәм нәфис сүз жанры буенча актер булып эшли.

1956—1960 — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында драма артисты.

1957 — Татарстан АССРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә.

1957 — Мәскәүдә Бөек Октябрь социалистик революциясенең 40 еллыгына багышлап үткәрелгән нәфис сүз жанрында эшләүче артистларның Бөтенроссия конкурсы лауреаты.

1960—1967 — Казан телевидение студиясе дикторы.

1962—1967 — Мәскәүнең А.В.Луначарский исемендәге Дәүләт театр сәнгате институтында укый.

1967—1989 — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә сүз жанры артисты.

1969 — Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

1969 — В.И.Ленинның тууына 100 ел тулуга багышланган нәфис сүз өлкәсендә эшләүче артистларның Бөтенроссия конкурсы дипломанты.

1971 — СССР Югары Советы президиумы указы белән Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнә.

1974 — ТАССРның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә.

1974 — А.С.Пушкинның тууына 175 ел тулуга багышланган «Пушкин укулары» Бөтенроссия конкурсы лауреаты.

1975—1980 — Казан дәүләт культура институтында сәхнә теле буенча өлкән укытучы.

1978 — РСФСРның атказанган артисты дигән мактаулы исем бирелә.

1981 — РСФСРның халык артисты дигән мактаулы исем бирелә.

1985 — Бөтенсоюз радиосы һәм телевидениесе отличнигы.

1989—1996 — Г.Тукай исемендәге Дәүләт филармониясендә халык коллективлары бүлеге режиссеры.

1998 — Татарстан Республикасы Президенты указы нигезендә Татарстан Республикасының Мактау грамотасы белән бүләкләнә.

2002 — Татарстан Халыкара информатизация академиясенең шәрәфле академигы итеп сайлана.

**АВТОРЛАР ТУРЫНДА БЕЛЕШМӘ**

***Минтимер Шәймиев*** (1937) — Татарстан Республикасы Президенты.

***Хәсән Туфан*** (1900—1981) — шагыйрь, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Мансур Хәсәнов*** (1930) — әдәбият галиме, академик, дәүләт эшлеклесе, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

***Гомәр Бәширов*** (1901—1999) — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Әмирхан Еники*** (1909—2000) — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Илдар Юзеев*** (1933—2004) — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Мөхәммәт Мәһдиев*** (1930—1995) — әдәбият галиме, Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Гариф Ахунов*** (1925—2000) — Татарстанның халык язучысы, җәмәгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Шәүкәт Галиев*** (1928) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе.

***Роберт Миңнуллин*** (1948) — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты, дәүләт эшлеклесе, Г.-Х.Андерсен исемендәге халыкара Почетлы диплом иясе.

***Марсель Галиев*** (1946) — язучы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Фәнзаман Баттал*** (1939) — язучы, журналист.

***Харрас Әюп*** (1946) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Рамил Исламов*** (1958) — әдәбият белгече, филология фәннәре докторы.

***Рәдиф Гаташ*** (1941) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Мөдәррис Әгъләмов*** (1946—2006) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Роберт Әхмәтҗанов*** (1935) — шагыйрь, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Миркасыйм Госманов*** (1934) — галим һәм язучы, тарих фәннәре докторы, академик, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйкый әгъзасы.

***Гамил Афзал*** (1921—2003) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Нурмөхәммәт Хисамов*** (1937) — әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе.

***Кыям Миңлебаев*** (1929—2005) — язучы, тәрҗемәче, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Шамил Маннапов*** (1938) — язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Айдар Хәлим*** (1942) — язучы, публицист, җәмәгать эшлеклесе.

***Зилә Сөнгатуллина*** (1949) — җырчы, педагог. ТАССР, Каракалпакстан һәм Россиянең халык артисткасы, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Фоат Галимуллин*** (1941) — әдәбият галиме, тәнкыйтьче, филология фәннәре докторы, профессор. Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Фәнис Яруллин*** (1938) — Татарстанның халык язучысы, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Рафаэль Сибат*** (1946—2003) — язучы.

***Ренат Еникеев*** (1937) — композитор, Татарстанның һәм РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Әхсән Баян*** (1927) — Татарстанның халык шагыйре, Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Наҗар Нәҗми*** (1918—1999) — Башкортстанның халык шагыйре, БАССРның С.Юлаев исемендәге Республика һәм РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты.

***Флера Сафиуллина*** (1938) — тел галиме, филология фәннәре докторы, профессор. Татарстанның атказанган мәктәп укытучысы.

***Госман Әхмәтҗанов*** (1925—2005) — актер, режиссер, тәрҗемәче. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

***Җәүдәт Сөләйманов*** (1955) — техник фәннәр докторы, профессор, шагыйрь.

***Ләбиб Лерон*** (1961) — язучы.

***Разил Вәлиев*** (1947) — язучы, дәүләт эшлеклесе. Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләге лауреаты.

***Гүзәл Подольская*** (1962) — журналист.

***Эдуард Трескин*** (1946) — җырчы, Татарстанның халык артисты.

***Петр Шаграй*** (1942) — журналист, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

***Марат Шакирҗанов*** (1963) — журналист.
***Наилә Шәрифуллина*** (1952) — журналист.
***Татьяна Мамаева —*** журналист.
***Сибгат Хәким*** (1911—1986) — ТАССРның халык шагыйре, Татарстанның Г.Тукай исемендәге, РСФСРның М.Горький исемендәге Дәүләт бүләкләре лауреаты.

## ЭЧТӘЛЕК


*Шәймиев.* Татарстан Республикасы Президентының рәхмәт хаты

Заманнарның иң кирәкле сүзе
Ирләр йөрәгендә нигәдер... *(Х.Әюп)*

*Х. ТуФан.*Туган тел
*М.Хәсәнов.* Айрат Арслан — халкыбызның илчесе
*Г.Бәширов.* Тылсымлы сүз остасы
*Ә.ЕниКи.* Сүз турында сүз
*И.Юзеев.* Нәфис сүз остасы Айрат Арсланга
*М.Мәһдиев.* Бәхетле артист
*Г.Ахунов.* Сәхнәдә — Айрат Арсланов
*Ш.Галиев* . «Татар улы...»
*Р.Миңнуллин.* Татар арысланы!
*М.Галиев.* Могтәбәр замандашыбыз
*Ф.Баттал.* Тукай илчесе
*Х.Әюп* . «Юкка гына ук атыламыни?..»
*Р.Исламов.* Ике районның улы — барыбызның горурлыгы
*Р.Гаташ.* Олуг остаз, чын санигъ...
*М.Әгъләмов.* Җырлар калка
*Р.Әхмәтҗан.* Затлы сүз иясе
*М.Госманов.* Камиллекнең көче
*Г.Афзал* . «Сүз әйтергә тәвәккәллек кирәк...»
*Н.Хисамов.* Халыкның ул үз сынына охшаган
*К.Миңлебаев.* Сүз остасы
*Ш.Маннапов.* Мәкам
*А.Хәлим* . «Тумыштан ук коеп куелган ул...»
*З.Сөнгатуллина.* Рухландырып, дәрт биреп торучы
*Ф.Галимуллин.* Шагыйрь түгел — шигырь
*Ф.Яруллин.* Гүзәл гамь
*Р.Сибат.* Сөйлисе сүзе бар әле...
*Р.Еникеев.* Музыкаль зәвыклы шәхес
*Ә.БаЯн.* Рәхмәт!
*Н.Нәҗми.* Осталык көче
*Ф.Сафиуллина.* Телебезнең бөеклеген, гүзәллеген тоеп...
*Г.Әхмәтҗанов.* Сабакташым һәм хезмәттәшем
*Ж.Сөләйман* . «Ак битләрне каурый-каләм бизәсә дә...»
*Л.Лерон* . «Без бәхетле идек, без хәзер дә бәхетле!»
*Р.Вәлиев.* Мәгънәле сүз моңлы, көйле була
*Г.Подольская.* Золотая пора
*Э.Трескин.* Призвание, ставшее судьбой
*П.Шаграй.* Слово, освобожденное из плена
*М.Шакирзянов* . «Судьба — это слепок с эпохи, точнее, судьба — это мы!»
*Н.Шарифуллина.* Автограф артиста
*Т.Мамаева.* На эстраду он вышел с Джалилем
*С.ХаКим.* Владеющий искусством звучащего слова

Сүз гаме
Истәлекләр алар күптөрле,

Истәлекләр алар күп кала... *(М.Әгъләм)*

*А.Арсланов.* Сәнгать-әдәбият әһелләрен сагынып...
Сәнгать әһелләрен үз күрде
Моң тулы язмыш

Татар моңының кәккүге
Шагыйрьне сагыну
Бакый Урманче
Уйландыра торган бәйрәм
Сәхнәбезнең йөзек кашы
Операбызның сүнмәс йолдызы
Күренекле балерина, режиссер һәм педагог
Зәңгәр томаннар артында калган мизгелләр
Йөрәкләрдә калды моңнары
Илаһи моң иясе
Рухи матурлык җырчысы
Фәнгә тугрылык
Гавай гитарасын «йөгәнләгән» бердәнбер егет
Татар сәхнәсенең былбылы
Сәнгатькә багышланган гомер
«Игътибар, микрофонны ачам!»
Шагыйрь белән соңгы очрашу
Театрыбызның олпат заты

**Төп биографик даталар**
*Р.Заһидуллина.* **Авторлар турында белешмә**

*Китапта А.Арсланов архивындагы фотолар файдаланылды.*

Литературно-художественное издание

Составитель **Загидуллина** Роза Ахметовна

Айрат Арсланов

*Воспоминания*

Казань. Татарское книжное издательство. 2007

На татарском и русском языках

Әдәби-нәфис басма

Төзүчесе **Заһидуллина** Роза Әхмәт кызы

Айрат Арсланов

*Истәлекләр*

Татар һәм рус телләрендә

Мөхәррирләре *Р.Ә.Заһидуллина, Г.М.Хәсәнова*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучысы *Т.В.Гредюшко, А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Р.Н.Шакирова, Н.И.Максимова, Г.Х.Сундукова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 2.07.2007. Форматы 70г100 1/16.
Офсет кәгазе. «School Book» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 19,5 + форз. 0,33.
Шартлы буяу-оттиск 79,95. Нәшер-хисап табагы 20,0 + форз. 0,48.
Тиражы 3000 д. Заказ С-735.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
http://tatkniga.ru e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет JahatTM программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.